Министерство образования и науки РФ
ФГАОУ ВПО «Казанский (Приволжский) федеральный университет»
Филологии и межкультурной коммуникации
Отделение татарской филологии и межкультурной коммуникаци им. Г.Тукая
Кафедра татарского языка и методики преподаванияи

А.Ф. ЮСУПОВ

СТИЛИСТИКА И КУЛЬТУРА РЕЧИ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

Конспект лекций

Казань – 2014

Направление подготовки: 032700.62 «Филология» (профиль подготовки «Отечественная филология (татарский язык и литература): бакалавр»)

Учебный план: «Филология» (татарский язык и литература) (очное, 2011).

Дисциплина: Б3+.Б.2 «Стилистика и культура речи татарского языка», (3-4 курсы, очное).

Количество часов: 144 (в том числе: лекции – 60, практические занятия – 14 , самостоятельная работа – 70), форма контроля – зачет, экзамен.

Аннотация: главной целью курса является формирование у студентов целостное представление о стилистике и культуре речи как раздела языкознания, об этапах ее исторического развития и современном состоянии, об особенностях синтаксической стилистики и культуры речи татарского языка. В данном пособии даются краткие теоретические сведения, отражаются новейшие научные достижения в области стилистики и культуры речи. Синтаксическая стилистика изучает использование различных синтаксических конструкций для стилистических целей, синонимию словосочетаний, отдельных типов простого и сложного предложения, стилистическую роль однородных членов предложения, стилистические функции порядка слов в предложении и т.д.

Темы: 1. Стилистика и культура речи татарского языка. Методологические и теоретические основы курса. 2. Основные этапы становления стилистики татарского языка. 3. Изучение стилистики татарского языка как науки. 4. Функциональные стили татарского литературного языка: функционирование, композиционные и лингвистические особенности, жанровое разнообразие. 5. О понятиях язык, речь, стиль в современном татарском языке. 6. Разделы стилистики: лингвистическая стилистика (синтаксическая стилистика). Объект и предмет, задачи синтаксической стилистики. История изучения вопросов синтаксической стилистики. 7. Синтаксические синонимы, параллели и варианты. Синтаксические синонимы: структурные и функциональные. 8. Стилистические фигуры: стилистические обороты, порядок предложения. Синтаксические омонимы и их разновидности. 9. О понятии культура речи: нормы, стилистические ошибки и отклонения от языковых норм в различных синтаксических конструкциях.

Ключевые слова: татарский язык, стилистика, культура речи, стиль, функциональные стили, синонимы, синтаксические синонимы, синтаксические варианты, синтаксические параллели, синтаксические омонимы.

Дата начала использования: 1 сентября 2014 г.

Автор: Юсупов Айрат Фаикович, кандидат филологических наук, доцент кафедры татарского языка и методики преподавания КФУ, тел.:(843) 2-21-33-51, e-mail: faikovich@mail.ru, Ayrat.Jusupov@ kpfu.ru

URL электронного курса в MOODLE: http://tulpar.kpfu.ru/course/view.php?id=1872

Доступность: записанные на курс пользователи

Язык интерфейса: татарский

Эчтәлек

Тема 1. Кереш лекция. Курсның методологик һәм теоретик нигезләре......4

Тема 2. Татар теле стилистикасының төп үсеш этаплары............................7

Тема 3. Татар стилистикасының фән буларак укытыла башлавы.............17

Тема 4. Хәзерге татар телендә “тел”, “сөйләм”, “стиль” терминнары белән белдерелә торган төшенчәләр: аларның уртак-гомуми һәм хосусый-аермалы яклары...24

Тема 5. Татар әдәби телендә функциональ стильләр: аларның кулланылышы, төзелеш һәм лингвистик үзенчәлекләре, жанр төрләре.............33

Тема 6. Лингвистик стилистика (синтаксик стилистика): синтаксик стилистиканың төп предметы, максат-бурычлары. Синтаксик стилистика һәм синтаксик синонимнарның өйрәнелеш тарихы...47

Тема 7. Синтаксик синонимнар, тәңгәлләр һәм синтаксик вариантлар. Синтаксик синонимнар: структур һәм функциональ төрләре……………………..52

Тема 8. Стилистик фигурлар: стиль әйләнмәләре. Синтаксик омонимнар һәм аларның төрләре...79

Фәнни хезмәтләр, уку-укыту әсбаплары, методик кулланмалар һәм информацион чыганаклар...87

Терминологик сүзлекчә..90

Тема 1. Кереш лекция. Курсның методологик һәм теоретик нигезләре

Лекция 1

Аннотация. Татар теле стилистикасы һәм сөйләм культурасы турында гомуми мәгълүмат бирелә. Курсның өйрәнү предметы һәм максат-бурычлары, тикшерү объекты билгеләнә. Стилистика фәненең термин-категорияләре, төп проблемалары, метод-ысуллары, теоретик-практик әһәмияте күрсәтелә. Телдәге синтаксик берәмлекләрне сөйләмдә стилистик куллану юлларын өйрәнүнең фәнни һәм гамәли максатлары.

Ачкыч сүзләр: стилистика, функциональ стилистика, сөйләм культурасы, стиль, функциональ стиль.

Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр. Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

Лекциянең планы:

1. Татар теле стилистикасы һәм сөйләм культурасы: билгеләмә, өйрәнү предметы һәм максат-бурычлары, тикшерү объекты.
2. Стилистика фәненең термин-категорияләре, төп проблемалары, метод-ысуллары, теоретик-практик әһәмияте.
3. Стилистика фәне өчен тел һәм сөйләмне аерым карау.
4. Функциональ стильләрнең төрен билгеләүдә төрлечә карашлар. (Х.Р.Курбатов, В.Х.Хаков, С.М.Ибраһимов һ.б.).
5. Телдәге синтаксик берәмлекләрне сөйләмдә стилистик куллану юлларын өйрәнүнең фәнни һәм гамәли максатлары.

Тел белеменең бер бүлеме булган стилистика тармагында:

1) сөйләм стильләре, шул исәптән индивидуаль стильләр;

2) тел берәмлекләренә хас булган стиль үзенчәлекләре өйрәнелә. Әлеге нигездә функциональ стилистика һәм лингвистик стилистика дигән ике тармак аерымлана.

Аерым фән буларак стилистика рус тел белемендә дә, тюркологиядә дә XX гасырның 40-50 елларында гына формалашып җитә. Димәк, тел белеменең фонетика, диалектология, лексикология, морфология, синтаксис кебек бүлекләреннән яшь булуы белән аерыла.

Стилистиканың үзенә хас булган өйрәнү объекты, термин категорияләр бар. Стилистика – кешеләрнең үзара аралашуында һәм иҗтимагый эшчәнлек алып бару процессында тел белән файдаланудагы кануннарны өйрәнә торган фән ул. Бу юнәлештә тел һәм сөйләмне аерып карый белү, әдәби норма һәм аны кулланган вакытта төрле вариантларның хасил булуын аңларга кирәк була.

Стилистика фәненең максат-бурычы дигәндә, гомумән алып сөйләмне өйрәнү, сөйләм типларын өйрәнү һәм тел берәмлекләрнең, лексиканың мәгънә эчтәлеге төрле экспрессив-эмоциональ төслелеген бәяли белү дә күздә тотыла.

Әлеге фәннең хосусый термин һәм категорияләре бар:

- стиль;

- функциональ стиль;

- индивидуаль стиль;

- стилистик төсмер (чара, норма, мәгънә);

- сөйләм стильләре системасы;

- аерым стильләрне хасил итә торган тел факторлары;

- экстралингвистик факторлар һ.б.

Түбәндәге мәсьәләләр стилистиканың төп проблемалары:

- әлеге фәннең үзенә хас булган төшенчә-категорияләренең табигатен билгеләү;

- тел стильләре һәм сөйләм стильләренең уртак һәм аермалы якларын аңлау, һәрберсенең үзенчә системага ия булуын күзаллау;

- җанлы сөйләмә һәм язма-китабый сөйләм төрләренең үзара мөнәсәбәтен күзәтү, төрле чорда төрлечә булганлыгын аңлау;

- стилистикада лингвистик һәм экстралингвистик факторларның үзара тәэсир итешүен билгеләү;

- стилистикада объектив (тел) һәм субъектив (сөйләм) факторларының үзара тәэсир итешүен аңлау;

- матур әдәбият стилендә файдаланыла торган телнең башка функциональ стильләрдә кулланыла торган телдән аермасын белү;

- стилистикада диахрония (телнең тарихи хәле) һәм синхрония (хәзерге хәле) проблемаларын аңлау;

- язма, әдәби һәм стилистик нормаларның тарихи үсеш-үзгәрештә булуын аңлау;

- әдәби стиль һәм функциональ стильләр мәсьәләсенең уртак һәм хосусый якларын күрә белү.

Стилистик аспекттагы тикшеренүләр түбәндәге метод-ысулларга нигезләнә:

1) семантик-стилистик метод ярдәмендә һәр стильнең үз табигатенә хас булган аңа кирәкле тел берәмлекләрен таләп итүе күзәтелә; стилистик мәгънә һәм аның нечкә төсмерләре барлана һәм аңлатыла.

2) төрле стильдәге үзенчәлекләрне стилистик чагыштырма метод ярдәмендә өйрәнү.

3) сәнгатьле сөйләм стилен өйрәнгән вакытта “сүз” – “сүз-сурәт” методы кирәк булуына игътибар ителә.

4) әлеге методлар ярдәмендә эш алып барганда, тел һәм сөйләм күренешләрен хасил итә торган берәмлекләрне санаганда стилистик-статистик метод файдаланыла.

Стилистика фәнен укытуның теоретик-практик әһәмияте:

Теоретик әһәмияте – әлеге фәннең проблемаларын, категорияләрен белү һәм аңлау.

Практик әһәмияте – фикерне дөрес һәм төгәл итеп әйтеп һәм язып бирә белү күнекмәләрен булдыру күздә тотыла. Бу гамәли стилистикага карый. Ул лингвистик һәм функциональ стилистика кебек аерым бер махсус тармак

буларак өйрәнелә. Сөйләм һәм язу әдәбенә караган күптөрле мөһим мәсьәләләрне хәл итү өлкәсендә зур эш алып бара.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Стилистика һәм сөйләм культурасына билгеләмә бирергә.

2. Татар теле стилистикасы һәм сөйләм культурасының төп методологик нигезләре: өйрәнү предметы һәм максат-бурычлары, тикшерү объекты.

3. Стилистика фәненең термин-категорияләре, төп проблемалары, метод-ысуллары, теоретик-практик әһәмияте.

4. Тел белемендә “стиль” терминына билгеләмә бирү мәсьәләсе.

5. Телдәге синтаксик берәмлекләрне сөйләмдә стилистик куллану юлларын өйрәнүнең фәнни һәм гамәли максатларын күрсәтегез.

Әдәбият исемлеге.

1. Бәширова И.Б. Татар стилистикасының теоретик нигезләре. Татар филологиясе һәм тарихы факультеты студентлары өчен программа / И.Б.Бәширова. – Казан: Казан дәүләт ун-ты, 2005. – 29 б.

2. Ибраһимов С.М. Сандугач теле кирәк: Синтаксик стилистика: Уку-укыту ярдәмлеге / С.М.Ибраһимов. – Казан: Мәгариф, 2008. – 159 б.

3. Курбатов Х.Р. Сүз сәнгате: Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы. – Казан: Мәгариф, 2002. – 199 б.

4. Хаков В.Х. Татар әдәби теле (стилистика). – Казан: Тат. кит. нәшр, 1999. – 304 б.

Тема 2. Татар теле стилистикасының төп үсеш этаплары

Лекция 2

Аннотация. Лекциядә татар стилистикасы һәм сөйләм культурасының төп үсеш этаплары билгеләнә (XIX гасыр – XX йөзнең I яртысы), аларга хронологик күзәтү ясалып, аерым галимнәрнең стилистика һәм сөйләм культурасы өлкәсендәге эшчәнлеге өйрәнелә.

Ачкыч сүзләр: стилистика, функциональ стилистика, сөйләм культурасы, стиль, функциональ стиль.

Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр. Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

Лекциянең планы:

1. Татар теленең сөйләм буларак өйрәнелә башлавы: сөйләмә һәм язма китаби "тел" (М.Иванов, С.Кукляшев, К.Насыйри эшчәнлеге).

2. XIX гасырның II яртысында татар язма теленең әдәби нормасы үсеше: "Стиль" терминының кулланыла башлавы, "Өч стиль" теориясенең үсеш алуы (Н.Ф.Катанов эшчәнлеге).

3. XX гасыр башында татар язма теленең әдәби нормасы үсеше: иске татар язма теленең төрле вариантлары ("Нур" газетасында, "Шура" журналында барган бәхәс).

4. 1920-30 нчы елларда татар язма теленең әдәби нормасы үсеше: татар язма теленең әдәби нормасын, үсеше-дәвамчанлыгын сәясәткә бәйләп, төрлечә аңлау һәм аңлату (Х.Бәдигый, Г.Сәгъди, Ш.Рамазанов эшчәнлеге).

1. Татар теленең сөйләм буларак өйрәнелә башлавы: сөйләмә һәм язма китаби "тел" (М.Иванов, С.Кукляшев, К.Насыйри эшчәнлеге).

Татар стилистикасы аерым фән буларак XX гасыр урталарында формалашып җитә. Төп категорияләре XIX гасыр урталарында ук тикшерелә башлый. Ул вакытта сөйләм, стиль дигән терминнар файдаланылмый һәм бер гасырдан соң шушы терминнар белән исемләнәчәк күренешләр билгеләнә. Татар теленең ике төрле формада эш башкаруына игътибар ителә:

1) телдән сөйләп;

2) язма текслар белән эшләп.

М.Иванов "Татарская хрестоматия" дигән китап бастыра (1842). Кереш өлешендә болай дип яза: "Оренбург краенда кулланыла торган татар теле ике төп төргә бүленә: сөйләм теле һәм язу/китап теле. Шуңа күрә дә мин

хрестоматияне ике өлештән төзәргә кирәк дип таптым: 1) сөйләм теле үрнәкләре, 2) китап теле. (1842, 3 бит).

Татар телен укытучы М.Иванов Оренбург краендагы татар теленең кулланылышын ике төргә бүлеп караган вакытта теоретик яктан ачык итеп фикер әйтә ала. Практик яктан шушы эзлеклелек саклана алмаган. Димәк, автор, нигездә, язма текстларны халык сөйләменә якынрак яисә ераграк булып язылуына игътибар иткән.

Шунда татар теле һәм гарәп-фарсы телләре укытучы С.Кукляшев әлеге мәсьәләгә ачыклык кертә. Ул да “Татар хрестоматиясе” (1859) дигән хезмәт яза. Керештә максатын күрсәтә: татарлар сөйләшә торган тел – төрки тел дип ассызыклый. Аның өч төркемен күрсәтә:

- төрки
- чыгытай
- татар.

“Язма татар теле өч төргә:

- гади (простой)
- эш (деловой)
- гыйльми (ученый) телгә бүленә.

Татар тел белемендә беренче булып С.Кукляшев татарча текстларны өч төрле телгә бүлеп карарга мөмкин булуын теоретик нигезли. Хезмәтнең гамәли ягы, текстларны сайлау һәм урнаштыруда төгәл тәртип сакланмый. Бу турыда ул үзе болай яза: “Хрестоматиянең башында үзем җыйган мәкаль-әйтемнәрне урнаштырдым, аннан хикәяләр (повесть) кайберләрен кульязма китаплардан алдым, кайберләрен көнчыгыш теллшәреннән тәрҗемә иттем. Аннан соң үрнәк буларак үзем язган хатлар бирелде, эш кәгазьләре, расписскалар, кечкенә шигырьләр, “Искәндәрнамә”дән өзекләр бирдем”.

Каюм Насыйри (1825-1902).

1. Халык арасыннан чыккан, халыкка хезмәткә бил баглаган галим буларак иң башта сөйләм теле һәм язу теле дигән төшенчәләрне аерымлап куя. К.Насыйри сөйләм теле дигәндә табигый җанлы сөйләшүне күз алдында тота.

2. К.Насыйри “Әбүгалисина” кыйссасын гарәп теленнән тәрҗемә итә. К.Насыйри аңлы рәвештә халык укысын дип язылган матур әдәбият әсәрләрен шул халыкның җанлы сөйләм теле белән язарга тиешлеген белеп эш итә. (1889).

3. К.Насыйри күптөрле фәннәр өйрәнә (тел, әдәбият, тарих, этнография, математика, география, геометрия, ботаника, медицина, календарьлар һ.б.). Күп фәннәрне өйрәнгән галим буларак һәр фәннең үз теле, терминнары булырга тиешлегенә инана.

4. К.Насыйри киң тармаклы теоретик һәм практик эшчәнлегенә нигезләнеп сөйләм теле, язу теле, әдәби әсәрләр теле, фәнни хезмәтләр теле турында беренче башлап яңа фикер әйткән галим, ул җанлы-сөйләмә тел белән язма-китабый тел арасындагы аерманы гади итеп аңлатып бирә: “Мәдәниятле һәрбер мадәмнең ике төрле теле булып, берсе – аннасыннан сөт имгән мөдәттә үгрәнгән теле, икенчесе дәхи остазга тәгълимгә бирелгән гыйлем вә фән лөгатьләре белән ачылган теледер”. (К.Н., 1892).

К.Насыйри үзенең чордашлары һәм Казан лингвистика мәктәбенең күренекле вәкилләре Б. де Куртен (1845-1929), Н.В.Крушевский (1851-1887), В.А.Богородицкий (1857-1941), белән бер үк вакытта диярлек җанлы сөйләмә телнең язуда чагылыш тапкан язма тел белән бер үк күренеш түгеллеген аңлаганлыгын күрсәтә.

2. XIX гасырның II яртысында татар язма теленең әдәби нормасы үсеше: “Стиль” терминының кулланыла башлавы, “Өч стиль” теориясенең үсеш алуы (Н.Ф.Катанов эшчәнлеге).

XIX гасыр ахырында татар тел белемендә стилистика фәненең төп термины булган “стиль” термины кулланыла башлый. Казан университетының төрки-татар кафедрасы профессоры Н.Ф.Катанов (1862-1922) “Материалы к изучению казанско-татарского наречия” дигән хезмәтенең керешендә “Казанда соңгы вакытта үзенә дүрт төрле (особый) стиль эшләнә башлады...”, дип күрсәтә. Галим Казан татарлары телендә языла торган барлык әдәбиятны урта, югары һәм халык дип атала торган төрләргә бүлеп карарга мөмкин дип саный. Урта һәм югары стильләрнең бер-берсеннән бик үк аерымланмавын әйтә, ике

юнәлештә дә татар сүзләре кулланылган очракта да гарәп-фарсы сүзләре кулланыла.” Халык стиле дип аталган өченче төргә Катанов Г.Фәезхановның “Хикәят вә мәкаләт” җыентыгыннан хикәятләр, “Өч туган” исемле татар халык әкиятен, мәкальләр, табышмаклар, җырлар, солдатка китү турында хикәят бәет (стихотворный рассказ) бирелә.

Өч стильгә үрнәк итеп китерелгән күп кенә текстлар татар халык авыз иҗатыннан һәм керәшен татарлары телле әдәбияттан сайлана. Шулай итеп, халык стилен автор “народная словестность” дип атый (1898) хезмәттә дә шулай атала.

Н.Ф.Катанов теотерик яктан өч стиль дип фикер йөртсә дә, мисаллары ике стильгә мөнәсәбәтле генә бирелә:

1. Казан татарларының гарәп-фарсы алынмаларын файдаланып язылган язма әдәбияты;

2. Гарәп-фарсы алынмалары файдаланмыйча язылган халык авыз иҗаты әсәрләре һәм керәшен татарларына караган әдәбият.

Катанов татар телендә язылган текстларны теоретик формаль яктан өч төргә бүлгәндә татар филологиясендә аңа кадәр 50-55 ел элек М.Иванов, С.Кукляшев, К.Насыйри тарафыннан күзәтелгән һәм “тел” дип аталган күренешне “стиль” дип яңа термин белән кабатлап әйткән.

Татар тел белемендә стилистика фәненең төп категориясе булган стиль термины XIX гасырның ахырында кулланыла башлый. Татар филологиясендә өч стиль теориясе яшәеш ала. Гарәп-фарсы алынмаларын күп файдаланып язылган текстлар югары стиль, татар теленең җанлы сөйләмә сүзләре белән язылганнары – түбән стиль һәм урта стиль. XX гасырның 10 нчы елларына кадәр аерым татар әдипләре иҗат иткән әсәрләрне шушы стильләргә бүлеп карарга мөмкин.

XX гасыр башы татар филологиясендә ике стильгә бүлеп карарга мөмкин булган әдәби әсәрләр иҗат ителә.

3. XX гасыр башында татар язма теленең әдәби нормасы үсеше: иске татар язма теленең төрле вариантлары (“Нур” газетасында, “Шура” журналында барган бәхәс).

1905 нче елгы революцияне татарлар хуплап каршы ала, безнең халыкка азатлык килде. 1905 нче елда С.Петербургта беренче татарча газета чыга – “Нур” (Ахун хәзрәт Габдулла Баязитов җитәкчелегендә) Мөхәррирне бер генә сорау борчый – мәкаләләр нинди телдә язылачак.

Татар зыялылары җавап итеп хат язалар. Беренче хат Хәсәнгата Габәшидән була. “Нур” газетасының 7 нче санында “нәрсә ул әдәби тел?” дигән сорау күтәрелә.

“Нур” № 8 Г.Исхакый җавап яза: “Газетаның нинди телдә язылуы бик әһәмиятле мәсьәлә. Мәкаләдә күренгәнчә, язучылар әдәби тел һәм гавами телне бүлеп карый башладылар. Әдәби дигән мәгънәсен ап-ачык итеп аңлата торган һәр гыйбарәгә әйтелә. Бер мәкалә әдәби булыр өчен ни хакында язылганлыгы һәр укый белә торган кешегә тәмам аңлашылырдай булырга тиеш. Шуның өчен әдәби телне үз телемез дим. Үзебез сөйли торган телдә язарга тиешбез. Китаплар халык арасында күп таралачак”. Димәк, әдәби тел һәм гавами тел дип бүленү булырга тиеш түгел. Баязитов: “Иске татар теле белән язучы нишләр?” – ди.

“Нур” № 13 Һ.Максуди “Казан теле” дигән мәкалә яза: “Русиядә яшәүче төркиләр өчен “Тәрҗеман” газетасы чыга. Аны аңлыйлар. Алар сөйләшкәндә дә тылмач кирәкми. Казан шивәсен файдаланалар. Казан халкының үз теле бар. Шуңа күрә госманлы шивәсендә язу мөмкин түгел”.

Газетада тел бәхәсе уңаеннан басылган мәкаләләрдә халык, милләт һәм аның атамаларына игътибар ителә. Г.Баязитов “Без татармыз. Телебез – татар теле”.

“Урта лисан” белән язарга дигән карарга киләләр. Бу терминны беренче мәртәбә Исмәгыйл бәй Гаспралы куллана. Барлык төрки халыклар аңласын дигән сүзне күздә тота. Г.Баязитов башкача уйлый: “Татар халкы өчен уртадарак булган тел. Урта стиль белән бер дәрәҗәдә яшәеш ала”.

“Нур”дагы әлеге эшчәнлек соңрак басыла башлаган башка басмаларда дәвам ителә: “Фикер” (1905-07), “Казан мөхбире” (1905-1911), “Өлфәт” (6-7), “Йолдыз” (6-18), “Тавыш” (7-11), “Идел” (8-14) журналлары, “Әл-гасрел-җәдид” (6-7), “Әл-Ислах” (7-8), “Шура” (8-18), “Ялт-Йолт” (10-18), “Аң” (12-18). Әлеге басмалардагы күп кенә мәкаләләр “Нур” битләрендә күтәрелгән сорауларга җавап рәвешендә языла. Иске татар теленең гамәлдә булган 3 варианты булу аңлашыла:

1) Классик иске татар теле (80 % - гарәп-фарсы һәм гомумтөрки формалар, фигыльләр – татар телендә).

2) Җәдиди-госманлы (угыз формалары күп, төрек).

3) гавами тел.

1909 нчы елда Оренбургта “Шура” журналының мөхәррире Р.Фәхретдинов әлеге басманың тел бәхәсе башлануын белдерә. Максаты өч вариант: 20 юлдан аз, 40 юлдан күп булмасын, ни турында булса да, саф төрки телдә языгыз, ди. Һәр мәкаләдә г/ф алынмаларын күрсәтү башлана. Г.Тукай шуны “Тиле ярыш” дип атый.

Беренче урын “Болгар кызы – Айсылу” әсәре өчен М.Гафурига бирелә.

XX гасырда хат язу үрнәкләре бирелә. Бөтенесе дә җанлы сөйләмә формаларда. Аналарга, балаларга язылган мәкаләләр җанлы сөйләмдә. Әлеге юнәлеш XX гасырның 30 елларына кадәр килеп җитә.

4. 1920-30 нчы елларда татар язма теленең әдәби нормасы үсеше: татар язма теленең әдәби нормасын, үсеше-дәвамчанлыгын сәясәткә бәйләп, төрлечә аңлау һәм аңлату (Х.Бәдигый, Г.Сәгъди, Ш.Рамазанов эшчәнлеге).

Татар теле дәүләт теле булып яшәеш ала. Иң беренче чиратта татар теленең укытылуы күздә тотыла. Татар теленең фәнни өйрәнелүе үсә. Шушы еллардан башлап татар язма әдәбиятның тарихы өйрәнелә башлый. Татар язма әдәбиятның тарихын өйрәнү юнәлешендә яңа темалар күтәрелә.

XIX гасыр уртасыннан тикшерә башлап, XX гасыр башы тел ярышында күтәрелгән проблемалар XX гасыр уртасында Л.Җәләй тарафыннан теоретик

нигезгә куела. Фәнни өйрәнү ягыннан дәлилләнә, әмма бу эш билгеле бер тигез юлга төшкәнче татар теле, язма әдәби тел, элеге телнең кулланылышы һәм төзелеше турындагы мәсьәләләр махсус корылган сәяси киртәне үтәргә тиеш булалар.

Татар теленең 20-30 нчы елларда тарихи-прогматив үсеш-үзгәреше 40-50 нче елларда рус дәүләте сәясәтенең каты кысасы эченә алына. Әдәби телне яңача өйрәнү башлана. 30 нчы еллар ахыры – 40 нчы еллар башында татар әдәби теле аерым бер класс теле булырга тиеш дигән караштан чыгып өйрәнәләр.

Әлеге теория нигез итеп алынгач, иң беренче чиратта гарәп-фарсы алынмаларына каршы көрәш башлана.

“Мәктәпләрдә тел өйрәнү, белүдән төп максаты – аның тышкы әйтелеш якларын формаль ягын, фонетикасын өйрәнү генә түгел, барыннан да элек телнең социаль, сыйнфый көрәш, үзара аңлашу өчен әһәмиятле якларын өйрәнү. Кыскасы, телне сыйнфый көрәшнең үткен коралы итеп файдалана белергә хәзерләнү булырга тиеш”, - дип яза Алпаров (1933, 1945).

Шушы максатка ирешүгә төп юнәлеш буларак ерак гасырлардан килүче гомумтөрки традицион сүз һәм тәкъбирләргә һәм гарәп-фарсы алынмаларына каршы көрәш ачыла. Алар “корама”, халыкка аңлашылмый, алардан котылырга кирәк дигән эш башлана (Г.Сәгъди, 1939, 108 б.).

Әлеге фикер Ш.Рамазановның “Совет чорында татар әдәби теленең үсеше” дигән мәкаләсендә ачык әйтелә: “Сүзлек составындагы үзгәрешләр һәм үсеш процессы түбәндәге юллар белән барды:

1) әдәби телебезне гарәп-фарсы, госманлы-төрек телләре элементларыннан тазарту;

2) татар теленең үз лексик фондын һәм грамматик чараларын активлаштыру;

3) сүзләрнең мәгънәләрен үзгәртү, элекке сүзләргә яңа мәгънәләр салу;

4) сүзлек составын советизм һәм интернационализм белән баету. Дөрес, әдәби тел – тарихи оешкан һәм чыныккан чара” (Совет әдәбияты, 1945, № 6.).

Шундый эшләр барышында 1951 нче елны Сталинның “Марксизм һәм тел гыйлеме мәсьәләләре” дигән хезмәте басыла һәм анда телләрнең сыйнфый-буржуаз түгеллеге “мәгълүм була”. “Шәһәр теле”, “матбугат теле”, “идарә теле”, “укымышлылар теле”, “культуралы кешеләр теле” дип атала. Әдәби тел төшенчәсенә бу хезмәттә яңача аңлатма бирелә: “әдәби тел - әдәбиятта беркетелгән һәм шушы телдә сөйләшүчеләрнең барысы өчен дә кртак норма итеп эшкәртелгән, шомартылган тел ул”. Әдәби телнең нигезендә гомумхалык теле ята. Бу – гомуми закон. әдәби телнең төп хуҗасы – халык, сыйныфлар түгел. “Әлеге хезмәт басылып чыккач, буржуаз теле безнең тел түгел дип тел культурасы мирасын инкарь итүгә барып җитүләр тәнкыйть утына тотыла башлый”. (Л.Җәләй, 1953, 3 б.).

Күпсанлы мәкалә-хезмәтләрдә әлеге фикер еш кабатлана, телнең сафлыгын сакларга кирәк дигән фикер үстерелә, бу вакытта инде (30-50 нче еллар) татар теле гарәп-фарсы, төрек теле алынмаларыннан чистартылган булганга, телнең сафлыгын саклау дигәндә, хәзер диалекталь үзенчәлекләргә каршы көрәш башлана. Әдәбиятта беркетелгән диалекталь формалардан котылу өчен көрәш игълан ителә. Әдәби тел диалектлардан өстен булырга тиеш дигән фикер шул диалектларны инкарь итү, аларны юкка чыгару дигән фикер белән тәңгәлләшә. Бу эшләрнең барысы да әдәби телне халык аңласын, язма әдәби тел халыкның гомумсөйләмә теленә якын булырга тиеш дигән изге ният белән эшләнә.

Шушы “чистартулардан” соң татар язма әдәби теле:

1) үзенең күп гасырлык язма традицияләрен;

2) гомумхалык теленә һәм сөйләменә хас булган иҗтимагый катламы – структур һәм функциональ вариантларыннан аерыла.

Шулай итеп, татар телен әдәби татар теле дип әйткән вакытта гомумхалык телендәге 6-7 вариантыннан аерылган һәм әдәби норма дип күтәрелгән бер форма игына күз алдында тотыла башлый. Әдәби тел дигән күренеш аның табигатен барлыкка китерә торган бары бер билгесенә - әдәби нормасына гына тиңләштерелә. Шулай итеп, татар теленең барлык

тармакларында да аңа фәкать берлек – единичность хас булырга тиеш дигән караш ныгытыла. Әлеге тәгълимат нигез итеп алынгач, аерым төбәкләрдә кулланыла торган сүз һәм сүз формалары, шулай ук иске татар әдәби теленең бер компоненты булган гарәп-фарсы, төрек теле алынмалары да әдәби телнең берәмлекләре дип санала алмый, ягъни язма телнең үсеше, эволюциясе юкка чыгарыла. Ләкин болай барып булмый һәм 50 нче еллар ахыры 60 нчы еллар башында татар язма әдәби теленең тарихын төзәтү, кайтару эше башлана. Үз вакытында Г.Рәхим (1923), Н.Хәким (1928), Х.Бәдигый (1930) тарафыннан күтәрелүгә омтылыш ясалган һәм әдәби телне чорларга бүлеп карарга кирәк дигән караш гамәлгә күтәрелә башлый.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Татар теленең кулланылышы ягыннан, ягъни сөйләм буларак тикшерелә башлавы: сөйләмә һәм язма-китаби телләр (М.Иванов, С.Кукляшев, К.Насыйри).

2. Татар филологиясендә стиль терминының кулланыла башлавы. Өч стиль теориясенең үсеш алуы (Н.Ф.Катанов).

3. XX гасыр башында татар стилистикасы мәсьәләләренең өйрәнелеше. Иске татар язма теленең төрле вариантлары: "Нур" газетасында һәм "Шура" журналында тел бәхәсе (Хәсән Гата Габәши, Әхмәд Һади Максуди, Гаяз Исхакый фикерләре).

4. 1920-30 нчы елларда татар язма теленең әдәби нормасы үсеше: татар язма теленең әдәби нормасын, үсеше-дәвамчанлыгын сәясәткә бәйләп, төрлечә аңлау һәм аңлату (Х.Бәдигый, Г.Сәгъди, Ш.Рамазанов эшчәнлеге).

Әдәбият исемлеге.

1. Бәширова И.Б. Татар стилистикасының теоретик нигезләре. Татар филологиясе һәм тарихы факультеты студентлары өчен программа / И.Б.Бәширова. – Казан: Казан дәүләт ун-ты, 2005. – 29 б.

2. Насыйри К. Сайланма әсәрләр. 2 томда / К.Насыйри. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1974, т. 1. – 340 б.

3. Рамазанов Ш.А. Татар теле буенча очерклар / Ш.А.Рамазанова. – Казан: Таткнигоиздат, 1954. – 200 б.

4. Хангилдин В.Н. Татар теленең синонимикасы / В.Н.Хангильдин // Совет мәктәбе. – 1940. – № 11-12. – Б. 47-49.

5. Хангилдин В.Н. Татар теле культурасының кайбер мәсьәләләре / В.Н.Хангильдин. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1976. – 94 б.

Тема 3. Татар стилистикасының фән буларак укытыла башлавы

Лекция 3

Аннотация. Лекциядә татар стилистикасы һәм сөйләм культурасының XX гасырның икенче яртысында үсеш эволюциясе өйрәнелә, аерым галимнәрнең стилистика һәм сөйләм культурасы өлкәсендәге эшчәнлегенә хронологик күзәтү ясала, аларның фәнгә алып килгән яңалага һәм төп фикерләре аңлатыла.

Ачкыч сүзләр: стилистика, функциональ стилистика, сөйләм культурасы, стиль, функциональ стиль.

Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр. Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

Лекциянең планы:

1. Татар стилистикасының фән буларак укытыла башлавы: функциональ стильләр хакында мәгълүмат (Л.Җәләй, Ф.С.Фазиев эшчәнлеге).

2. XX гасырның II яртысында татар стилистикасының үсеше (Х.Р.Курбатов, В.Х.Хаков, С.М.Ибраһимов, И.Б.Бәширова, И.М.Низамов эшчәнлеге).

1. Татар стилистикасының фән буларак укытыла башлавы: функциональ стильләр хакында мәгълүмат (Л.Җәләй, Ф.С.Фазиев эшчәнлеге).

Татар стилистиканың өйрәнелә башлавы Л.Җәләй исеме белән бәйле: “Стилистика һәм әсәрләрнең композициясе” (1934), “Стилистика һәм гомуми тел белеме” (1938), “Практик стилистика алдында торган төп бурычлар”. Беренче ике мәкалә басылмаган, өченчесе – “Мәгариф”, 1935, № 11. – Б. 38. Стилистика фән буларак өйрәнелә, укытыла башлый. Л.Җәләй мәкаләләрен тәрҗемәчеләр өчен әзерли.

Беренче тапкыр әлеге мәкаләләрдә стилистика фәне тел берәмлекләренең кулланылышы, сайланышын өйрәнергә тиешле фән буларак күз алдында тотыла.

КДУның татфак студентларына Л.Җәләй “Татар әдәби теле һәм аның стильләре” дигән курс буенча лекцияләр укый, әлеге лекцияләрдә бу теманың фәнни-практик әһәмияте, әдәби телнең иҗтимагый-тарихи урыны һәм аны билгеләүдәге төрле карашлар булуы әдәби тел тарихы белән язу теле арасындагы мөнәсәбәтне бик үтемле итеп аңлата башлый. Әдәби тел дигән күренешнең чорларга бүленергә мөмкинлеге аңлатыла:

1) әлеге тарихны туа башлау чорыннан ук алып өйрәнергә кирәк. 18-19 гасырлардан гына өйрәнәбез;

2) халыкның экономикасы төзелүе белән бергә өйрәнелергә тиеш, телне тормыштан аерырга ярамый;

3) әдәби телнең күрсәткече – язу, шуңа күрә ул язу тарихы белән бергә алып барылырга тиеш;

4) халыкларның гомуми телләре формалашуда диалектлар зур урын алып тора, шул үсешнең тарихы исәпкә алынырга тиеш;

5) әдәби телнең гомумхалык теленнән аермасы стиль булуда, әдәби тел тарихы – стильләр тарихы дигән фикерләр әйтелә.

“Татар әдәби теле тарихы һәм стильләр” дигән лекциядә Л.Җәләй формалашып җиткән әдәби тел биш стильгә бүленә һәм һәрберсенең үз тарихы бар”, - дти. Түбәндәге стильләрне күрсәтә:

- сәнгатьчә әдәбият стиле;

- фәнни һәм фәнни популяр әдәбият стиле (гыйльми әсәрләр теле стиле);

- публицистик, ягъни иҗтимагый-политик темаларга сөйләнә торган стиль;

- эш кәгазьләре стиле;

- хатлар язу стиле”.

Л.Җәләйнең фәнни юнәлешен дәвам итүче шәкертләре хезмәтләрендә шушы стильләр ассызыклана.

Фазыл Салихович Фазиев: төрки тел XI-XII гасырларда үзенең төрле жанрларында, мәсәлән, сәнгати-поэтик, тарихи-хикәяләү, канцелярия-эш, дини-көндәлек, эпитафик-кабер ташларындагы язмалар һ.б. стильләре белән классик әдәби тел булып җитешә (Татарча-русча сүзлек, 1966, 812 б.).

2. XX гасырның II яртысында татар стилистикасының үсеше (Х.Р.Курбатов, В.Х.Хаков, С.М.Ибраһимов, И.Б.Бәширова, И.М.Низамов эшчәнлеге).

Хәлиф Рәхимович Курбатов. Үзенең тикшерүләрендә тел белән сөйләмне бер-берсеннән аерып карарга кирәк булуны күрсәтә. Хезмәтләре: “Татар теленең синтаксис һәм стилистика мәсьәләләре” (1956), “Хәзерге татар әдәби теленең стилистик синтаксисы” (1971), “Татарская линвистическая стилистика и поэтика” (1978) һ.б.

Стилистика фәненең төп категорияләре булган стиль, тел стиле, сөйләм стильләре һ.б. тюркологиядә беренче тапкыр системага сала. Сөйләм стильләренең лексик-грамматик, синтаксик, фонетик үзенчәлекләре тәфсилләп бирелә. Төрки лингвистик стилистикасы мөстәкыйль үсеш ала дигән фикер әйтелгәндә, иң беренче чиратта, Х.Курбатов исеме телгә алына.

Татар әдәби телендәге функциональ стильләргә түбәндәгечә билгеләмә бирә: “Сөйләм эшчәнлегенең ике төрдә: сөйләү рәвешендә, язма рәвештә икәнен искә алганнан соң, сөйләм стильләре, иң элек, өч зур тармакка бүленә:

- функциональ сөйләм;

- экспрессив сөйләм;

- сәнгатьле сөйләм.

Функциональ сөйләмгә сөйләшү стиле, эш кәгазьләре стиле, фәнни иншалау стиле, публицистика стиле карый, тарихи яктан йола стиле.

Экспрессив сөйләм: күтәренке стиль, түбәнәйтелгән стиль, нәзакәтле стиль, дусларча ягымлы сөйләм стиле, рәсми-салкын стиль, юмор стиле, сатира стиле.

Сәнгатьле сөйләм стиле аерым урын тота һәм стильләрнең үзенчәлекләрен билгеле идея-максатлардан чыгып, иркен файдалана.

Сөйләм стильләре бер-берсеннән битараф (нейтраль) стиль дип аталган сөйләм фонында аерылып тора.

Битараф стиль саф килеш үзе генә очрамый, теоретик яктан гына күз алдында тота” (1971, 10-11 б.).

Галим хатлар стилен аерып алып карамый.

Вахит Хөҗҗәт улы Хаков. В.Хаковның берничә хезмәтендә рәсми канцелярия, матур әдәбият стиле, иҗтимагый-публицистика стиле, фәнни стиль, эпистоляр-хатлар стиленең функциональ үзенчәлекләре татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше аспектында тикшерелә.

- телнең язма һәм сөйләмә формалары үзләренә хас стиль үзенчәлекләре белән аерыла;

- әдәби телнең язма һәм сөйләмә формалары арасындагы мөнәсәбәт борынгыдан башланган. Фольклор әсәрләре сөйләмә әдәби форманың башлануы.

Функциональ стильләрне сөйләм стильләре дип белдергән Х.Курбатовтан аермалы буларак, В.Хаков функциональ стильләрне тел стильләре дип саный. “Татар әдәби телендә түбәндәге тел (функциональ) стильләре аерылып чыга:

- иҗтимагый-публицистик тел стиле;

- фәнни-популяр әдәби тел стиле;

- эш кәгазьләре (рәсми-канцелярия) стиле;

- хатлар (эпистоляр) стиль.

Кайбер тел белгечләре матур әдәбият әсәрләрендәге тел үзенчәлекләрен дә функциональ стильләр рәтендә карый, әмма матур әдәбият әсрләренең телен башка стильләр белән бер рәткә куеп булмый. Ул функциональ сөйләм стильләренә караганда, бик киң һәм үзендә телдәге барлык стильләрнең дә үзенчәлекләрен чагылдыра” (1999, 10 б.).

Хезмәтләрендә татар теле фонетикасы, морфологиясенә һәм лексика өлкәләренә караган стилистик үзенчәлекләр тикшерелә. КДУ студентларына укытырга махсус багышлап язылган программалар, күнегүләр җыентыклары чыгара.

Сәгадәт Мөгаллим улы Ибраһимов. “Синтаксик стилистика” (1989) дигән хезмәтендә әдәби сөйләм, стиль, функциональ стиль дигән терминнарны аңлатып үтә. Тел һәм сөйләм стильләрен билгеләүдә күп карашлар яшәвен ассызыклый. Татар тел белемендә функциональ стильләрнең төрен билгеләүдә төрле карашлар яши, ди. “Хәзерге татар әдәби сөйләме түбәндәге стильләргә бүленә:

- матур әдәбият стиле;

- публицистика стиле;

- фәнни стиль;

- рәсим эш кәгазьләре стиле;

- хатилар стиле” (3-20 б.).

С.Ибраһимовның стилистика өлкәсендәге эшчәнлеге “Татар телендә синтаксик синонимнар” (1976) дигән хезмәте белән башлана. Әлеге хезмәттә төрле стильләргә хас үзенчәлекләрнең синтаксиска бәйле ягы тикшерелә: “Сөйләм камил булсын өчен, әйтергә теләгән фикер төгәл аңлаешлы чыксын өчен лексик синонимнар белән генә эш итү җитми, шулай ук синтаксик синонимнарның нәрсә икәнен төшенү, аларның төрләрен күзаллау, урынлы

куллана белү дә бик кирәк. Синтаксик синонимнар ике компонент арасындагы мәгънә мөнәсәбәтен төрле бәйләүче чаралар ярдәмендә бирә алу мөмкинлеге” (3 бит).

“Синтаксик стилистикадан күнегүләр” (1968) исемле кулланмалары да бар.

Илида Басыйр кызы Бәширова. И.Бәшированың “Хәзерге татар стилистикасының уңышлары һәм бурычлары” (1981) мәкаләсендә җанлы сөйләм, сәнгатьле сөйләм сөйләм, публицистик стиль, фәнни һәм фәнни популяр стиль, эпистоляр стильләрнең, матур әдәбият стиленең татар тел белемендә өйрәнелеше һәм алда торган бурычлар турында фикер әйтелә.

“Хәзерге татар телендә фәнни әдәбият стиле. Гомуми мәгълүмат” дигән мәкаләсендә функциональ стильләрнең биш төре санала:

- рәсми эш кәгазьләре;
- иҗтимагый-публицистик;
- матур әдәбият стиле;
- фәнни әдәбият стиле;
- эпистоляр (хатлар) стиле.

“Хәзерге татар филологиясендә функциональ стильләр, үсеш алган башка телләрдәге кебек үк, тел структурсына мөнәсәбәттә дә, җәмгыять һәм аң-акыл системаларына каралып өйрәнелә” ди. Шул нигездә һәр стильнең үзләренә хас булган табигате һәм вазифасы билгеләнә, жанр төрләре, копозицион төзелеше тел берәмлекләренең ни рәвешле сайланып алынуы һәм автор мөнәсәбәтенең ничек чагылышы күзәтелә. Функциональ стильләр – функциональ сөйләм типлары” (Фән һәм тел, 2000, № 3, 12-15 б.).

Стилистика фәненең төп категориясе булган стиль, функциональ стильләр турында мәгълүмат бирү юнәлешендә тел, әдәби тел, җанлы сөйләм, язма сөйләм, сөйләмә стиль, язма стиль, тело стильләре, сөйләм стильләре, сөйләм төрләре, типлары кебек терминнар файдаланыла.

Илдар Малик улы Низамов. Галимнәр хезмәтләрдә “стиль” – телнең кулланылышы дип атыйлар, ә И.Низамов “Уем тел очымда: сөйләм һәм

массакүләм аралашу” (1995) дигән монографиясендә сөйләмне болай аңлата: “сөйләм категориясе шәхси (индивидуаль), күмәк (коллектив) һәм социаль-иҗтимагый планда анализланып сөйләмият дигән яңа тармагы барлыкка килә. Стиль дигәндә:

- образлы тасвирлау;
- журналистик-публицистик;
- фәнни-популяр;
- рәсми;
- эпистоляр;
- телдән сөйләм һ.б.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Татар стилистикасының фән буларак укытыла башлавы. Функциональ стильләр хакында мәгълүмат бирелү (Л.Җәләй эшчәнлеге).
2. Татар телендәге функциональ стильләрнең системага салынып өйрәнелеше (Х.Р.Курбатов эшчәнлеге).
3. Татар телендәге функциональ стильләрнең тарихи аспектта тикшерелүе (В.Х.Хаков эшчәнлеге).
4. Татар теленең аерым тармакларының (фонетика, морфология, синтаксис) стилистик мөмкинлеген күзәтеп язылган хезмәтләр (Х.Р.Курбатов, С.М.Ибраһимов).
5. Татар теленең лексика тармагына хас булган стилистик мөмкинлекләрнең аңлатмалы сүзлектә һәм аерым хезмәтләрдә чагылышы (Ф.С.Сафиуллина, И.Б.Бәширова).
6. Татар филологиясендә сөйләмият фәненең үсеш алуы (И.М.Низамов).

Әдәбият исемлеге.

1. Бәширова И.Б. Сәнгатьле чәчмә әсәрләр теле: Татар прозасында хикәяләү стильләренең үсеше һәм аның әсәр теленә тәэсире. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1979. – 96 б.

2. Бәширова И.Б. Фәнни әдәбият стиле: гомуми мәгълүмат / И.Б.Бәширова / Фән һәм тел. – 2000. – № 3 – Б. 12-15.

3. Ибраһимов С.М. Синтаксик стилистика / С.М.Ибраһимов. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1989. – 150 б.

4. Ибраһимов С.М. Сандугач теле кирәк: Синтаксик стилистика: Уку-укыту ярдәмлеге / С.М.Ибраһимов. – Казан: Мәгариф, 2008. – 159 б.

5. Курбатов Х.Р. Татарская лингвистическая стилистика и поэтика / Х.Р.Куратов. – М.: Наука, 1978. – 218 с.

6. Курбатов Х.Р. Сүз сәнгате: Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы / Х.Р.Курбатов. – Казан: Мәгариф, 2002. – 199 б.

7. Хаков В.Х. Татар әдәби теле (стилистика) / В.Х.Хаков. – Казан: Тат. кит. нәшр, 1999. – 304 б.

Тема 4. Хәзерге татар телендә “тел”, “сөйләм”, “стиль” терминнары белән белдерелә торган төшенчәләр: аларның уртак-гомуми һәм хосусый-аермалы яклары

Лекция 4

Аннотация. Лекциядә хәзерге татар әдәби телендә “тел”, “сөйләм”, “стиль” терминнары белән белдерелә торган төшенчәләрнең бирелеше аңлатыла, әлеге терминнарының тел белеменең аерым өлкәләренә караган хезмәтләрдә уртак-гомуми һәм хосусый-аермалы яклары күрсәтелә.

Ачкыч сүзләр: стиль, функциональ стиль, тел, сөйләм.

Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр. Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

Лекциянең планы:

1. Хәзерге татар телендә “тел”, “сөйләм”, “стиль” терминнары белән белдерелә торган төшенчәләрнең аңлатмалы сүзлекләрдә бирелеше.

2. Тел белеменең аерым тармакларында әлеге терминнар белән бирелә торган төшенчәләрне аңлату.

3. “Тел”, “сөйләм”, “стиль” терминнарының уртак-гомуми һәм хосусый-аермалы яклары.

“Тел” һәм “сөйләм” терминнары көндәлек тормышта да, хезмәтләрдә дә берсе икенчесен алмаштырып килә ала торган синонимнар рәвешендә йөри. Мәсәлән: “Ярлы кешенең теле ачы була”, “Сөйдергән дә тел, биздергән дә тел” дигәндә тел сүзе сөйләм мәгънәсеендә кулланыла. Әдәбият дәреслекләрендә дә автор теле, персонаж теле һ.б. берсе икенчесе белән алмаштырыла.

Г.Алпаров үз вакытында “Сөйләм – кешеләрнең сөйләм әгъзалары аркылы үз ирекләре белән төрле авазлар чыгарып аңлашуларына “тел” диләр, сөйләшү дип әйтәләр” (1945, 24 бит).

“Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә “тел” дигән сүзнең унөч мәгънәсе аңлатыла (3 том, 1981, 69-73 б.). Әлеге аңлатманы өч нигезгә утыртып карарга мөмкин:

1. Җан ияләренең атамасы белән бергә кулланганда шул җан иясенең органын белдерү: *кеше теле, сыер теле*.

2. Аерым бер милләт атамасы белән кулланганда шул милләтнең үзенә хас аралашу чарасы булган системаны һәм шул системаның аерым тармаклары һәм берәмлекләре дигән мәгънәне белдерү. Әлеге нигез төрле вариантларга бүленә: *врачлар теле, әдәбият теле, Тукай теле, тел кату, тел ачу һ.б.*

3. Җансыз предмет атамалары белән кулланылып, шул предметларның бер деталенең исеме: *сәгать теле.*

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә “сүз” дигән тел берәмлегенең ун мәгънәсе теркәлгән. Шуларның сигезе “сөйләм” дигән мәгънәне белдерә: *сөйләшү (әңгәмә), чыгыш, фикер, караш (бәяләмә бирү), тәнкыйть итү, киңәш бирү һ.б.*

“Сүз”нең бу мәгънәләре телнең аралашу чарасы дип аңлата торган парадигмаларына якыная, әмма вазифалар конкретрак күрсәтелә. “Тел”нең аңлатмасыннан аермалы буларак берсе дә күчерелмә мәгънә дип искәртелми. Җанлы сөйләмдә дә, матур әдәбиятта да, халык авыз иҗатында да”сүз” нигездә

шушы мисалар вазифасында файдаланыла. Мәсәлән, “тел”, “сүз”, “сөйләм” дип атала торган күренешләр кулланылышта күп кенә мәгънәләре белән берсе икенчесен алмаштыра ала торган берәмлекләр буларак карала. Әлеге хәл махсус әдәбиятта да чагыла. Мәсәлән, С.Ибраһимов телгә мондый билгеләмә бирә: “тел дигән төшенчә шактый киң мәгънәләрдә алына:

- теге яки бу этник төркемнең, халыкның аралашу чарасы булган бер системасын;

- аралашу өчен кирәк булган аерым берәмлекләрнең билгеле бер тәртибен;

- фикер алышу, тирә-юньдәге күренешләрне хәбәр итеп, кешеләрнең кичереш-тойгыларын тасвирлау өчен шул берәмлекләрдән файдалануны аңлату. (1989, 5 бит).

Соңгы елларда югары уку йортлары өчен язылган дәреслек һәм кулланмаларда “тел” белән “сөйләм”не аерып карарга кирәклек көн тәртибенә куелды.

“Тел белеменә кереш” курсында тел һәм сөйләм дигән аерым бүлекчә бар. Әлеге күренешләрнең уртак һәм аермалы яклары күрсәтелә. Ф.С.Сафиуллина: “Тел дә, сөйләм дә иҗтимагый табигатькә ия, ләкин аралашу процессында сөйләм индивидуаль форма ала. Димәк, тел сөйләмдә индивидуаль формада чагылыш таба. Һәр кеше телнең гомуми системасыннан үзенә кирәкне ала, билгеле бер күләмдә үзгәртә, вариантлар таба. Сөйләм процессы индивидуаль генә түгел, кеше сөйләгәндә дә, язганда да икенче кешене истә тота. Димәк, сөйләмнең индивидуальлеге телнең иҗтимагый характерына каршы куела алмый. Сөйләм – тел шикелле үк системалы күренеш һәм сөйләм берәмлекләреннән тора. Сөйләм берәмлекләре тел берәмлекләре нигезендә барлыкка килә. Нәтиҗә ясап әйтергә мөмкин: тел һәм сөйләм икесе ике күренеш түгел, бер үк күренешнең төрлечә чагылышы гына”. (Сафиулилна, 1987, 1 кисәк, 29-31 бит).

Әмма тел һәм сөйләмнең бер үк күренеш булмавы турында “Синтаксис” дәреслегенең беренче битләрендә үк мәгълүмат бирелә: “Тел – аралашу коралы.

Сөйләм – аралашу ысулы. Димәк, сөйләм телнең хәрәкәттәге формасы. Билгеле бер тел коллективында, бигрәк тә языа аңлашу һәм аралашу өчен, сөйләшүнең уртак нормалары эшләнгән була. Сөйләмне тикшергәндә сөйләүче һәм тыңлаучы төшенчәләре үзәктә тора, чөнки сөйләм туунын төп сәбәбе – сөйләүче һәм тыңлаучы арасында аралашу ихтыяҗы. Аралашу кешеләрнең бер-берсенә нәрсәдер хәбәр итүе аркылы тормышка ашырыла. Димәк, сөйләмнең беренче төп үзенчәлеге – хәбәр итү. Хәбәр итүне сөйләүче чынбарлыктан алып оештыра, тыңлаучыга җиткерә, шуңа күрә хәбәр итү сөйләүченең мөнәсәбәтеннән тыш була алмый. Димәк, сөйләмнең икенче аерылгысыз билгесе – сөйләүченең чынбарлыкка мөнәсәбәтен белдерүе. Моны сөйләмнең модальлеге диләр. Шулай итеп сөйләмнең төп ике үзенчәлеге бар:

- хәбәрлек;
- модальлек.

Хәбәрлек – гомумән хәбәр итү, модальлек – ничек итеп хәбәр итү. Сөйләмнән башка хәбәрлек һәм модальлек була алмый, алардан башка сөйләм оешмый”. (Зәкиев, 1984, 5-8 бит).

Морфология дәреслегендә фигыльнең наклонениесе, зат, заман категорияләре парадигматик мәгънәләре һәм синтагматик мәгънәләре дип карала. Парадигматик мәгънә – фигыльнең тик торган халәте, туры мәгънәсе һәм бу аның тел ягы була. Шуның белән бергә хәзерге заман хикәя фигыльнең формасы сөйләм эчендә хәзерге заманны гына түгел, үткән һәм киләчәк заманны да бердерә ала. Д.Г.Тумашеваның “Татарский глагол” хезмәтендә наклонение акатегориясенең хикәя, шарт, теләк, боерык, кире шарт кебек төрләренең һәрберсе парадигматик һәм синтагматик мәгънә белдерүе ягын үз эченә ала.

Зат һәм заманнар шундый ук тәртиптә анализлана. Мәсәлән, беренче зат берлек сан формасының парадигматик мәгънәсе – сөйләүченең үзенең эш эшләвен белдерүе: мин сөйлим һ.б. Шушы ук форма бер сөйләүчене генә түгел, гомумиләшкән затның эшләвен дә, белдерә ала һ.б Бу – синтагматик мәгънә. Икенче зат берлек сан формасының парадигматик мәгънәсе – тыңлаучының эш

эшләвен белдерә: син язасың. Синтагматик мәгънәсе – әйтем-мәкаль, афоризмнарга хас булган гомумиләшкән затны белдерү (күп белсәң, тиз картаерсың). Функциональ-семантик анализ дип атала. Мондый тикшеренү телнең грамматик төзелешен һәм вазифасын төгәлрәк аңларга булыша (Т.Г.Тумашева, 1986).

Шул рәвешле югары уку йортында белем алучы филологларга тел белән сөйләмне аерып алып карарга һәм өйрәнергә кирәклек турында мәгълүмат бирелә. Лексика тармагы бу рәвешле тикшерелмәгән.

Стилистика тел белеменең бер тармагы буларак тел белән сөйләмне бер-берсеннән аерып караган моменттан мөстәкыйль фән буларак үсеш ала. Х.Р.Курбатов: "Сөйләм белән тел аерылгысыз бәйләнештә булса да, алар бер үк нәрсә түгел. Сөйләм ул – әйтеп бирү күренеше, тел – сүз хәзинәсе, гасырлар дәвамында бер тәртипкә салынган фонетик һәм грамматик төзелеш. Һәрбер сөйләм төре (тибы) да тел чараларын (сүзләрне, җөмләләрне) куллануда үзенә бер система. Стилистика фәне телнең кулланыштагы, хәрәкәттәге чагын өйрәнә: сүз, җөмлә, аваз, интонациянең мәгънә һәм тәэсир көче нечкәлекләренә игътибар бирә. Аларның кайсы кайда, ничек һәм нинди максат белән файдалануын билгели. Һәр төр сөйләм тел чараларын куллануда бер-берсеннән аерыла. Һәр төр сөйләмнең үзенә хас сүз һәм әйтелүе, фонетик һәм грамматик формаларын сайлап алуда үзенчәлекле яклары була. Шуңа күрә дә сөйләмне телнең яшәү, хәрәкәт итү рәвеше дибез". (1971, 3-4 бит).

Шушы ук фикер С.Ибраһимов хезмәтендә дә кабатлана: "Сөйләм тел үзенчәлекләрен эшкә җигү, аны хәрәкәткә китерү, аралашу өчен аннан файдалануны күздә тота. Тел һәм сөйләмне бер үк күренешнең ике ягы итеп карарга кирәк. Иҗтимагый күренеш булган тел һәм сөйләм бер үк берәмлекләр белән эш итә. Сөйләмдә без телнең шул берәмлекләрен сайлап алу юлы белән барабыз" (1989, 5 бит).

Әлеге аңлатудан күренгәнчә, стилистика фәне тел белән сөйләмне аерып алып тикшерү уңаенда сөйләм төрләренең үзләрен дә аерып карарга

кирәклегенә игътибар итә. Тел берәмлекләренең ни рәвешле реальләшүенә карап, сөйләм төп ике төргә бүленә:

- җанлы сөйләм формасы;

- язма текст формасы.

Татар тел белемендә болар барысы бергә функциональ стильләр дип атала. Гомумән, татар филологиясендә теленең ике формасын аңлату һәм бу күренешләрне әдәби телгә мөнәсәбәтле рәвештә куллану берсе икенчесеннән аерылып каралмый. Бу мәсьәлә “Гомуми тел белеме”ндә генә аерымлана.

– Стиль дигән термин әдәби тел дигән күренешкә мөнәсәбәтле рәвештә генә әйтелә. Татар теленең ике формасы бар: җанлы сөйләмә, язма китабый. Татар әдәби теленең ике стиле: сөйләмә, язма.

Шулай итеп, “тел”, “сөйләм”, “стиль” төшенчәләренең билгеле бер уртаклыгы булуга карамастан (сөйләм һәм стиль барлыкка килсен өчен тел төп чыганак) аерымлыклары да бар. Җанлы сөйләм һәм язма сөйләм төрләре гомумхалык теленең ике формасы булып тора, стиль дигән вакытта гомумхалык теленең әдәби нормасына караган категория турында мәгълүмат биргән булабыз. Стилистика дигән фәндә әлеге стильләрнең табигате һәм вазифасы аерып карап билгеләнә һәм аларда тел берәмлекләренең ничек кулланылышы өйрәнелә. Шулай итеп, объектив фәнни дәрәҗәдә сөйләмне өйрәнү әлеге өч компонентны аңлатуга нигезләнә:

- сөйләүче (язучы) үзенең фикерен оештыра, сөйләмнең (текстның) композициясен кора, фикер агышының башламын, дәвам ителешен, ахырын билгели;

- сөйләүче (язучы) фикерен хәбәр итә, сүз сайлый, аларны бәйли, җөмлә төзи, әйтергә, язарга теләгән фикерен мөмкин кадәр дөрес, анык һәм төгәл итеп тыңлаучыга (язучыга) җиткерергә тырыша;

- фикерне оештыру һәм хәбәр итү сөйләүченең (язучының) чынбарлыкка карата булган мөнәсәбәтенбелдерүе кысасынла бара. Сөйләм иясенең максаты, нияте, тыңлаучының кем булуы, сөйләүче белән алар арасында нинди

мөнәсәбәт булуы әлеге модальлекнең характерын билгели. (И.И.Низамовның “Уем – тел очында” дигән хезмәтендә шушы үзенчәлекләр барлана).

Тел белән сөйләмне аерып карарга кирәк дигән фикернең фәнни проблема булып күтәрелүе Швецария галиме, Женева университеты профессоры Фред де Соссюр (1857-1913) исеме белән бәйле. Ул болай ди: “Тел белән сөйләм икесе бер-берсенә охшамаган күренеш, сөйләмне өйрәнеп булмый, телне генә өйрәнеп була”. Бу фикер 100 еллар өйрәнелә.

Лингвистик мәктәпләр: Мәскәү, Казан, Прага, Америка, Амстердам. Шушы мәктәпләр эшчәнлеге нәтиҗәсендә тел белән сөйләмне өйрәнүдә төрле юнәлешләр барлыкка килә.

Тел системасы бар, әлеге системаны аерым элементлар тәшкил итә. Әлеге элементлар мөстәкыйль булып та яши һәм шушы структураның эш башкарган вакыты була (сөйләм төзү функциясе).

XX гасыр уртасыннан язма текстны язма сөйләм дип әйтеп карарга мөмкин дигән фикер карала. Бу мәсьәләләр сөйләмне тулаем алып фәнни-объектив нигездә тикшерергә юл ача. Шушы өйрәтүләргә нигезләнеп, татар стилистикасында да сөйләм өйрәнелә һәм сөйләмнең нәрсә икәнен аңлаткан вакытта беренче чиратта аралашу ысулының нинди формада булуына, тел берәмлекләренең ничек файдалануына карап сөйләмнең сөйләмә һәм язма дигән төрләренә игътибар ителә. Бу формалар татар тел белемендә һәм аның стилистикасында төрлечә атала. Мәсәлән, Л.Җәләй: “Әдәби телнең ике төрле кулланылышы – язма һәм сөйләмә формасы бар. Бу ике төрнең берсе гадәттә язма әдәби тел, икенчесе сөйләмә әдәби тел дип йөртәләр. Әлеге төрләрнең язма һәм сөйләмә формалары билгеле. Бу нормаларны үз урынында куллана белү – тел культурасының нигез моментларыннан берсе”. (Җәләй, 1953, 5-8 бит).

Х.Р.Курбатов хезмәтләрендә әлеге ике сөйләм төренең ничек итеп һәм ни өчен барлыкка килүе һәм аларның нинди вазифа үтәүләре әйтелә: “Кешеләрнең үзара аралашу, сөйләшү, язышуларындагы билгеле бер практик эшчәнлеккә бәйле булган, күп дәверләр кулланылып, шул эшчәнлекне чагылдыруга

җайлашкан һәм нәтиҗәдә үзенчәлекле бер рәвешкә кергән (үзенә хас сүз һәм әйтелмәләре булган), әйтәсе фикерне бер төрле башлау һәм тәмамлау төсен алып теге яки бу дәрәҗәдә калыплашкан сөйләм типлары – функциональ сөйләм стильләре. Хәзерге татар әдәби телендә функциональ сөйләм стильләре иң элек ике төргә бүленә:

- язма сөйләм стиле;

- сөйләшү стиле”. (1971, 12 бит).

Шулай итеп, бу галим татар филологиясендә беренче тапкыр сөйләм тибы дигән төшенчәгә аңлатма бирә һәм аны икенче төрле функциональ сөйләм стиле дип атый. 1) Сөйләм стиль төшенчәләре абсолют синонимнар була дип карый.

2) Л.Җәләй хезмәтендәге язма әдәби тел, сөйләмә әдәби тел дигән тәкъбирләрдәге “тел” сүзе стиль термины белән алмаштырыла. Шулай итеп, гадәти телдә кулланыла торган төшенчәләр “сөйләмә тел”гә күчерелеп стилистик категориянең атамасы буларак файдаланыла. Ләкин, ни гаҗәп, шушы ук автор бер үк стилистик атегоряне төрлечә атый. Мәсәлән, стилистик яктан аерымланган сүзләрнең бер төркемен сөйләшү стиленә хас сүзләр дип атый, икенчесен язма сөйләмгә хас сүзләр дип атый. Шунда ук “стиль” дә, сөйләм дә “тел” белән алмаштырыла: “язма сөйләмгә хас сүзләр бу төркемгә башлыча язма телдә генә кулланылып, сөйләшү теленә хас булмаган сүзләр керә. Язма телгә хас сүзләр хәзинәсе ике өлештән тора:

- терминлашкан, күбесенчә синонимнары булмаган сүзләр;

- терминлашмаган һәм сөйлоәшү телендә / битараф лексикада синонимнары булган сүзләр.

Берүк стилистик атегория төрлечә аңлатыла дигәндә, функциональ стиль дигән төшенчәнең ике галимдә ике төрле бирелүе дә игътибарны җәлеп итә.

Х.Р.Курбатов функциональ стиль – калыплашкан сөйләм тибы дип атый. В.Х.Хаков хезмәтендә функциональ стиль – тел стиле (1999, 10 бит).

Шулай итеп, безнең стилист галимнәребезнең хезмәтләрендә “тел”, “сөйләм”, “стиль” дигән төшенчәләр берсе икенчесен алмаштырып килә ала торган синонимнар буларак кулланыла.

Тел – сөйләмгә әзер булган материал. Сөйләмгә әзер булган чаралар тупланмасы. Сөйләм – тел күренеше генә түгел, лекциядә сөйләм барлыкка килсен өчен нигездә өч төрле шарт үтәлергә тиеш:

1) фикернең оешуы;

2) фикернең хәбәр ителүе;

3) сөйләүченең мөнәсәбәт белдерүе.

Тел стильләре. Татар теле һәм рус теле стилистикасында тел стильләре, сөйләм стильләре кулланыла. Функциональ дигән сүз юк. Аны сөйләм янына гына куеп була.

Тел стильләренең нигездә тарихы зур. Борынгы Грециядә таякчыкны да, аның белән язылган сүзләрне дә стиль дип атаганнар. Шул ук вакытта стиль сүзе үгет-нәсыйхәт бирә торган бер алым дигән мәгънәне дә белдерә. Стилистика бу матур сөйләм сәнгате, ягъни риториканы өйрәнү булып санала.

Димәк, тел стиле – тел берәмлекләренең мәгънә эчтәлеге тотрыклы, эмоциональ бәяләү һәм шул сүзләрнең кулланылыш чиген белдерә торган стилистик төсмерләргә ия булуы аңлашыла. Бу төсмерләр тел күренеше дип атала. Сүзләрдә теркәлә. Бу хәл “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә ачык чагыла.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Хәзерге татар телендә “тел”, “сөйләм”, “стиль” терминнары белән белдерелә торган төшенчәләрнең аңлатмалы сүзлекләрдә бирелеше.

2. “Тел”, “сөйләм”, “стиль” терминнарының уртак-гомуми һәм хосусый-аермалы яклары.

3. Тел белеменең аерым өлкәләрендә әлеге терминнар белән бирелә торган төшенчәләрне аңлату.

4. Татар галимнәре хезмәтләрендә “тел”, “сөйләм”, “стиль” терминнары хакында мәгълүмат бирелү (Л.Җәләй, Х.Р.Курбатов, В.Х.Хаков, С.М.Ибраһимов, Ф.С.Сафиуллина, И.Б.Бәширова, И.М.Низамов).

Әдәбият исемлеге.

1. Бәширова И.Б. Татар стилистикасының теоретик нигезләре. Татар филологиясе һәм тарихы факультеты студентлары өчен программа / И.Б.Бәширова. – Казан: Казан дәүләт ун-ты, 2005. – 29 б.

2. Ибраһимов С.М. Сандугач теле кирәк: Синтаксик стилистика: Уку-укыту ярдәмлеге / С.М.Ибраһимов. – Казан: Мәгариф, 2008. – 159 б.

3. Курбатов Х.Р. Сүз сәнгате: Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы / Х.Р.Курбатов. – Казан: Мәгариф, 2002. – 199 б.

4. Низамов И.М. Уем тел очында... (Сөйләм һәм массакүләм аралашу // – Беренче кисәк. Татар сөйләменең нигезләре) / И.М.Низамов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – 287 б.

5. Сафиуллина Ф.С. Тел белеменә кереш. 1 кисәк. / Ф.С.Сафиуллина – Казан: КДУ нәшр., 1987. – 150 б.

6. Татар грамматикасы. – Т.II. Морфология. – М.: Инсан, Казан: Фикер, 2002. – 448 б.

7. Татар грамматикасы. – Т.III. Синтаксис. – М.: Инсан, Казан: Фикер, 1999. – 512 б.

8. Хаков В.Х. Татар әдәби теле (стилистика) / В.Х.Хаков. – Казан: Тат. кит. нәшр, 1999. – 304 б.

Тема 5. Татар әдәби телендә функциональ стильләр: аларның кулланылышы, төзелеш һәм лингвистик үзенчәлекләре, жанр төрләре

Лекция 5

Аннотация. Лекциядә хәзерге татар әдәби телендә функциональ стильләр, аларны төркемләү мәсьәләсе өйрәнелә. Функциональ стильләрнең табигате һәм вазифасы, төп жанр төрләре, аерым жанрларның композицион һәм лингвистик үзенчәлекләре өйрәнелә.

Ачкыч сүзләр: стиль, функциональ стиль, жанр, функциональ сөйләм типлары, тел стильләре.

Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр. Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

Лекциянең планы:

1. Хәзерге татар әдәби телендә сөйләшү стиле.

2. Хәзерге татар әдәби телендә язма стильләр (рәсми эш кәгазьләре стиле, фәнни-әдәбият стиле, иҗтимагый-публицистика стиле, матур әдәбият стиле, хатлар стиле).

Сөйләм стильләре – җәмгыятьтә бара торган күп төрле иҗтимагый эшләрне алып бару өчен, ягъни билгеле бер вазифа, функция үтәү өчен барлыкка килгән, озак гасырлар ныгыган, калыплашкан, аң тарафыннан кабул ителгән махсус сөйләм типлары.

Функциональ сөйләм типлары – аерым сүз һәм аның мәгънә эчтәлеге генә күзәтелми, ә сөйләм барлыкка китерә торган компонентлар истә тотыла: композицион төзелеш, тел мәсьәләләре, модаль мөнәсәбәтнең чагылышы. Шулай итеп, татар стилистикасында төп ике төрле сөйләмгә игътибар итәбез:

1) татар әдәби теленең җанлы сөйләм стиле;

2) татар әдәби теленең язма сөйләм стиле.

Аралашуның максатын, тел берәмлекләрен файдалануда төрлелек һәм сөйләм агышының шартлары төрле булганга, әлеге сөйләм стильләренең һәр икесенең дә үзләренә генә хас вазифалары төрлечә булып формалаша. Җанлы сөйләмнең төп вазифасы – сөйләүче һәм тыңлаучының турыдан-туры сөйләшеп аңлашуы: бу процесс әйтүгә һәм ишетүгә корылган, әйтергә теләгән фикерен мөмкин кадәр тулырак аңлату өчен сөйләүче тел, лингвистик берәмлекләр

белән бергә, тел булмаган, экстралингвистик факторлардан да файдалана (кул хәрәкәтләре, мимика).

Җанлы сөйләм – шәхси-индивидуаль кулланыла торган тел берәмлекләре уртак булуга карамастан, һәр кешенең сөйләме үзенчә генә була. Кешенең сөйләмендә аның кайсы диалект вәкиле, табигый сәләте, тәрбиясе, белеме, профессиясе, эрудициясе, психофизиологик халәте һ.б. чагылыш таба.

Язма сөйләм – язма текст, күреп, укып кабул ителә. Экстралингвистик факторлар катнаша алмый, язма сөйләм дә индивидуаль була, әмма аның табигатен әдәби язма стильнең системасында яшәеш тапкан, традицион-тарихи җирлектә калыплашкан сөйләм типлары, ягъни функциональ стильләр, аларның үзләренә хас кануннары билгели.

Сөйләмнең бу төрләрен өйрәнү барышында аларның һәр икесе фәкать үзләренә кирәк булган чыганаклар барлауны, фактик материал туплауны һәм объектив-фәнни нигезгә корылган тикшерү методларын таләп итә, әмма боларның һәр икесе дә сөйләм булганга, шушы сөйләмне хасил итүче нигездә тикшерелә (фикер оештырыла, хәбәр ителә, мәнәсәбәт белдерелә).

1. Хәзерге татар әдәби телендә сөйләшү стиле. Табигате. Адәм балаларының тормышларын алып бару өчен барлыкка килгән, озак гасырлар үтеп камилләшкән, ныгыган, аң тарафыннан кабул итепгән махсус сөйләм тибы.

Вазифасы. Сөйләүче һәм тыңлаучының турыдан-туры сөйләшеп аңлашуы, аралашуга булган ихтыяҗы канәгатьләндерүе. Бу төр сөйләм тибының берничә жанр тибы бар:

- кешеләрнең көндәлек тормышта үзара аралашуы, сөйләшүләре. Бу сөйләм, нигездә, диалогик формада. Бу – махсус хәзерлексез. Әйтергә теләгән фикернең катгый композиөион төзелеше юк, фикер агышының башы, ахыры ачык итеп уйланмаган. Сөйләшү билгеле бер ситуациягә нигезләнә. Гомумхалык теле нигезендә караганда җанлы сөйләшүне әдәби һәм әдәби булмаган формаларга бүлеп карарга мөмкин.

Сөйләшү стиле дигән әлеге процессның әдәби тел кысасында гына баруы аңлашыла. Сөйләшү стиле дигән тел үсеш-үзгәрешенең һәр чорында әдәби тел дип атала торган вариантның күренеш булып санала. Әмма бу очракта “әдәби” дигән төшенчәне махсус аңлатырга кирәк.

Гомумхалык теле берничә катламнан тора:

- гомумсөйләмнән + аерым төбәккә хас сөйләм.

- гомумсөйләмнән + аерым профессия белән бәйле сөйләм.

Әлеге катламнар әдәби тел һәм әдәби тел булмаган вариантлар да яши. Аерым төбәктә яшәүчеләргә генә аңлашылучы тел берәмлекләре әдәби телнең диалекталь формалары булып тора. Җанлы сөйләмә стиль:

1) гомумхалык өчен кабул ителгән әдәби нормага нигезләнүе белән бергә диалекталь форма дип аталган аерым төбәк өчен генә аңлашылучы сүз һәм сүз формалары белән дә файдалануы. Шушы төбәктә яшәүчеләр өчен үзләренең ана телләре норма булып санала. Шуңа күрә соңгы елларда аерым галимнәр диалект теле дип өйрәнә башладылар. Диалект теле – аерым диалектларга хас булган фонетик, морфологик, лексик чаралар истә тотыла һәм алар гомум әдәби телне баета торган фактор дип санала. (Юсупов Ф.Ю. “Изучение татарского глагола”, “Морфология татарского диалектного языка. Категория глагола”. – Казан: “Фән”, 2004. – кереш.).

Ф.Ю.Юсупов: “Аерым диалектны тел статусы дип өйрәнелергә тиеш. Гомумәдәби тел ул – барлык милләт өчен язма тел булып та тора. Диалект теле – җанлы сөйләшү. Ләкин алар функциональ, социаль табигатьләре төрле булуга карамастан гомуммилли тел өчен әдәби тел дә, диалект теле дә бер үк дәрәҗәдә әһәмиятле”.

Сөйләшү стиле ике әдәби нормага нигезләнә, ягъни гомумтелнең әдәби формасы, диалект теленең аерым төбәге өчен әдәби булган теле. Әлеге мөнәсәбәт тел белемендә җитәрлек өйрәнелмәгән.

Җанлы сөйләмә стиль – эмоциональ хис-кичерешләр турыдан-туры белдерелә торган сөйләм. Бәяләү төсмеренә бай булган сүзләр кулланыла ала. Сөйләүче фикерен тыңлаучыга төгәлрәк җиткерү өчен әлеге хис-кичерешләрен

аерым сүзләр белән белдерү белән бергә интонация, кул хәрәкәтләрен дә эшкә җигә. Сөйләшү стилендә әдәби һәм мораль нормага сыймаган сүзләр кулланылса, бу стильне җимерү булып санала.

Әлеге стильнең өйрәнелеше. Барлык стилист галимнәрнең хезмәтләрендә дә искә алына, кайбер үзенчәлекләре күрсәтелә, ләкин терминнар аралаштырып кулланыла.

* тәрбияче, укытучы сөйләме. Ул укыту, тәрбияләү процессы өчен кирәк сөйләм. Монологик формада. Диалогик булып китәргә мөмкин. Әйтелешенең әдәби нормасын белү таләп ителә. Кабул ителгән әдәби норма. Әлеге сөйләмдә мөнәсәбәт белдерү

* дикторлар сөйләме. Язылган текстны уку. Монологик формада. Укытучыларга караганда да әдәби әйтелеш катгый таләп ителә. Бөтенлоәй мөнәсәбәт белдермичә мөмкин түгел.

* сәхнә сөйләме. Ул икегә бүленә: спектакльләр, эстрада сөйләме. Катлаулы сөйләм, формасы, ингездә, диалогик. Нәтиҗәсе тамашачыга юнәлдерелгән. Әдәби телгә нигезләнә. Бу – бәхәсле мәсьәлә:

1) кайбер галимнәр ул катгый әдәби әйтелештә булырга тиеш;

2) кайбер диалекталь үзенчәлекләр булырга мөмкин. Персонажларның кайсы төбәктән булуына карап, шул төбәкнең сөйләшү үзенчәлекләрен кулланырга мөмкин. Т.Миңнуллан “Гөргөри кияүләре”, “Йөрәк маем” – мишәрләр сөйләме.

* вәгазь, дини нәсыйхәт, үгетләү теле. Монологик формада. Әдәби нормага нигезләнә. Гарәп телендә текст, татар теленә тәрҗемә ителә. Катгый әдәби әйтелеш таләп итеп булмый.

2. Хәзерге татар әдәби телендә язма стильләр. Язуның барлыкка килүе, язма телнең нормалаша башлавы дәүләтчелек булуга бәйле. Төрки халыкларда язу борынгыдан барлыкка килә. Системалы әдәби тел формалашып җитсен өчен берничә йөз еллар кирәк була. Язуда беркетелә башлаган тел әдәби тел дәрәҗәсенә күтәрелү процессында төрле диалектларның төп үзенчәлекләрен берләштереп, теләсә нинди диалекттан өстенрәк, баерак була, билгеле бер

нормага салына һәм куллану сферасына, максатына карап, стилистик вариантларга ия була башлый. Безнең чорга килеп җиткән беренче язма әдәби тел VI-VIII гасырларда рун язуында сакланган һәм шушы язуларда да стилистик аерымлану күзәтелә. (Татар грамматикасы, 1 том, Казан, 1998, 42-43 бит).

Шулай итеп, язма телнең әдәби булып яшәеше аның стильләрендә чагыла. Әлеге стильләр иҗтимагый эшчәнлекне алып баруга ярашкан, озак гасырлар үтеп камилләшкән һәм калыплашкан була.

Хәзерге татар язма әдәби теленең 7 функциональ стиле бар:

- рәсми эш кәгазьләре стиле;
- фәнни әдәбият стиле;
- матур әдәбият стиле;
- вакытлы матбугат, публицистика стиле;
- дини-дидиактика стиле;
- хатлар стиле;
- көндәлек гамәли стиль.

Бу стильләрнең барысы да үзләренә генә хас табигатьләре нигезендә үзләре генә башкара ала торган вазифа үти. Тикшерү барышында һәр стильнең иҗтимагый тормыш, аң-фикерләү белән бәйләнеше һәм әдәби телгә мөнәсәбәте нинди булуга игътибар ителәчәк.

- **Татар әдәби телендә рәсми эш кәгазьләре стиле.** Күпгасырлык язмачылыгы булган төрки-татар телендә рәсми эш кәгазьләре дип аталган стиль булуы мәгълүм. Татар стилистлары әлеге стильнең булуын таныйлар, тик исемен төрлечә атыйлар: Л.Җәләй, Х.Курбатов – эш кәгазьләре стиле, В.Хаков – эш кәгазьләре теле стиле (1961), рәсми канцелярия стиле (1972, 1999), С.Ибраһимов – рәсми эш кәгазьләре стиле (1989), Ф.Фасиев – канцелярия эш стиле (1966), деловая письменность (1982), И.Бәширова – рәсми эш кәгазьләре (рәсми канцелярия) стиле (Фән һәм тел, 2000, № 3), Ф.Хисамова – старотатарская деловая письменность (1977), татарская деловая письменность, А.Тимерханов – официальный деловой стиль (2002, 53 б.).

Әлеге стильнең төрле исемнәрдә йөртелүе аның табигатенә һәм вазифасына бәйле. Табигате – җәмгыятьтәге рәсми хокукый мөнәсәбәтләрнең чагылышы булып барлыкка килгән һәм аң-акыл тарафыннан кабул ителгән махсус сөйләм тибы. Вазифасы – дәүләт белән дәүләт һәм хөкүмәт белән аерым кешеләрнең аралашуын рәсми рәвештә оештыру, җитәкләү һәм идарә итү. Вазифасы ягыннан өлешчә “рәсми тел” төшенчәсенә туры килә һәм”дәүләт теле”нең төп бер күрсәткече, хәрәкәттәге төп бер тармагы булып тора. Дәүләт теле – закон белән кабул ителгән һәм фактик статуска ия тел. Рәсми тел – закон белән кабул ителмәгән, фактик статуска ия булмаган тел.

Указ белән кабул ителгән тел фактик статуска ия булсын өчен рәсми эш кагәзьләре шул телдә булырга тиеш, чөнки документ власть һәм идарә оешмаларына мөрәҗәгать итәргә мөмкинлек бирә. Ул халыкны дәүләт белән бәйли. Татар теле 1922 һәм 1992 нче елларда закон белән дәүләт теле дип игълан ителә, әмма тулаем фактик статуска ия түгел. Әлеге мәсьәләләр бу стильнең иҗтимагый тормышы белән бәйле ягы.

Жанр төрләре. Иҗтимагый тормышта хокукый мөнәсәбәтләр күпкырлы һәм катлаулы булганга, рәсми эш кәгазьләре үз эчендә дә күп жанрлы. А.Тимерханов “Язык деловых бумаг в современном татарском языке” дигән хезмәтендә аларны ике гә бүлә:

- законодательский (кануный) стиль;

- администрация-канцелярия төре.

Икесе дә хокукый нормага нигезләнә, төзеелшләре ягыннан үзенчәлекләре бар.

1. Кануный эш кәгазьләре дәүләтнең югары хокук органнары тарафыннан языла: *конституция, зокон, указ, норматив актлар, устав, положение-кагыйдәләр.* Бу төрдәге язмалар юридик-хокукый төшәнчәләр киң кулланыла. Лексиканың күбесе абстрак гомимиләштерелгән мәгънәдә һәм күбесе алынма сүзләр.

2. Административ-канцелярия стилендә дәүләт эчендәге хокук хокукый бурычларны үти, идарә итә, әмма болары аерым кешеләр белән хөкүмәт мөнәсәбәтендә була. Үзләре ике формада:

- информация бирү документлар: *игълан, белдерү, телеграмма, доклад*.

- иҗтимагый эшчәнлекне билгеле бер дәрәҗәдә оештыру юнәлешендә: *приказ, гариза, расписка, белешмә, доверенность, характеристика* һ.б.

Бу төр кешеләр һәм аларның тормыш-көнкүреше белән турыдан-туры бәйләнә. Әлеге документларның телендә төрле сфераларга караган лексик берәмлекләр урын ала, гадәти сүзләрнең мәгънәсе специальләшә була, конкретлаша. Тотрыклы тезмәләр актив кулланыла: *эштән азат итү* һ.б. (гадәти телдә тотрыклы түгел).

Бу стильдә язылган документлар официаль һәм аларда махсус этикет саклана. Сүзләрнең күбесе төп атау мәгънәсендә, хис-кичерешләрдән азат, жаргон һәм гади сүзләр кулланылмый. Бу стильнең аерым төрләрендә, мәсәлән, автобиография, гариза, доверенность, аңлатма язуында һ.б. һәр язучының үз йөзе, белеме, характеры, эшкә мөнәсәбәте чагылыш таба. Зат аламашлыклары, затланышлы фигыль формалары кулланыла.

Рәсми эш кәгазьләрендә композицион форма таләп ителә, алар документларның мәгънәви кисәкләре – реквизитлары дип атала. Реквизитларның (лат. “таләп ителә”) бер-бер артлы тезелеп бирелүе – документның формуляры. Формуляр дәүләт стандарты белән билгеләнә, документларның бердәм формасы саклана. Документ язылган вакытта кайсы урыннан яза башларга дип таләп тә белдерелә.

● **Фәнни әдәбият стиле.** Күп гасырлык язмачылыгы булган татар теленең фәнни әдәбият стиле булуы мәгълүм (Курбатов, 1971; Хаков, 1972; Ибраһимов, 1989; Фасиев, Татар телендә терминология, 1969).

<u>Стильнең табигате</u>. Чынбарлыкны, ягъни табигать, җәмгыять, аң-акыл һәм тел-сөйләм системаларын танып белү өчен барлыкка килеп, үсеш алган махсус сөйләм тибы.

Вазифасы. Теге яки бу фән тармагына хас кануннарны барларга, аңларга, аңлатырга ярдәм итүче хосусый төшенчәләр һәм аларның телдә чагылыш тапкан атамалары – терминнар – ярдәмендә фәнни фикерләрне катгый логик эзлеклелектә иншалау. Танып белү – кешенең тормышы, хезмәт процесында табигатьне үз аңында чагылдыруы. Чынбарлыкны күзәтү, тойгылар, күзаллаулар аша аерым төшенчәләр барлыкка килә.

Абстракт фикерләү танып белүне яңа баскычка күтәрә һәм әлеге төшенчәләргә исемнәр бирелә-бирелә тел үзе байый. Тел ярдәмендә кеше дөньяны аерым өлешләргә бүлеп, аерым элементларга таркатып танып белә һәм үзләштерә. Җәмгыять үсешенең билгеле бер баскычында танып белү турыдан-туры хезмәт процессыннан аерыла һәм мөстәкыйль категория булып формалаша. Аерым фәннәр белән шөгыльләнергә вакыты һәм мөмкинлеге булган кешеләр катламы хасил була.

Фән һәм терминология үсеше өчен икенче шарт – язу барлыкка килү. Язудан башка әдәбият юк һәм фәннәрнең үсеше мөмкин түгел, язу культурасын дәвамлы рәвештә кулланганда гына гомумәдәби тел оеша. Бай, төзек, эшкәртелгән әдәби тел булмаганда фәнни танып белү булмый.

Эш кәгазьләреннән аермалы буларак, фәнни әдәбият стиленең ике жанр төре бар:

- саф фәнни әдәбият;

- фәнни-популяр әдәбият.

Соңгы вакытта дәреслек-кулланмаларны өченче төр дип карарга дигән фикер бар.

Саф фәнни әдәбият төрендә аерым фән тармагы махсус өйрәнелә, үзенә генә хас закончалыклар ачыла, алар махсус терминнар белән атала, бу терминнар шул өлкә кешеләренә генә аңлашыла. Саф фәнни әдәбият текстларның төзелеше, әлеге текстларны язганда сүз сайланышы, автор мөнәсәбәтенең чагылышы ничек булырга тиешлек билгеле бер тәртиптә эшкәртелгән һәм калыплашкан була. Аны катгый рәвештә саклау таләп ителә. Саф фәнни әдәбият дип фәнни хезмәтләрне истә тотабыз (курс һәм диплом

эшләре, кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре, гыйльми мәкалә, монографияләр һ.б.).

Курс эшләре һәр фәнни хезмәткә куела торган таләпләргә җавап бирерлек дәрәҗәдә булырга тиеш. (Шартлары: титул бит, кереш (актуальлек, максат-бурычлар, теманың өйрәнелеше һ.б.), бүлекләр, йомгак, әдәбият исемлеге).

Фәнни хезмәт язганда логик эзлеклелектәге фәнни фикер ачылырга тиеш. Терминнарны дөрес итеп куллану, аларның мәгънәләрен аңлау кирәк. Терминнар теге яки бу фән тармагы кайда формалаша башлаган, шул халык телендә. Филологиягә б.э.к. нигез салына, күп терминнар грек һәм латин теленә барып тоташа. (грекча *грамота* – туры сызык, *терма* – граница, чик).

Фәнни хезмәтләрдә автор мөнәсәбәте турыдан-тиуры белдерелми – “Без”. Фәнни стильдә образлы сүзләр кулланыла ала. Мәсәлән, Н.Юзеев “Хәзерге татар поэтикасы” (1973): “Татар поэзиясен бай тарихлы олы дәрья итеп күз алдына китерергә, аның чишмә башын язган гасырлар тирәнлегеннән эзләргә кирәк булыр иде” (13 бит).

• **Татар әдәби теленең матур әдәбият стиле.** Татар әдәби теленең матур әдәбият дип (сәнгатьле сөйләм) атала торган стиле бар. (Курбатов, 1971, 45-54 б.; Хаков, 1972, 117-124 б.; Хаков, 2003; Ибраһимов, 1989, Бәширова).

Эш кәгазьләре һәм фәнни әдәбият стиле белән чагыштырганда матур әдәбият стиле катлаулы һәм үзенчәлекле. Озак еллар буена кайбер стилист галимнәр әлеге сөйләм тибын функциональ стильләрдән үзгә бер күренеш дип бәяләделәр. Курбатов: “Сәнгатьле сөйләм стиле болар арасында үзенә аерым урын тота һәм әлеге стильләрнең үзенчәлекләрен билгеле идея-эстетик максатлардан чыгып бик иркен файдалана дип функциональ сөйләмгә сөйләшү стиле, эш кәгазьләре стиле, фәнни иншалау стиле һәм публицистика стиле керә дип аңлата” (1971). Бу фикернең дөрес булмавы үз вакытда ук күрсәтелә. С.Ибраһимов болай ди: “Матур әдәбият стиле башка төр стильләрнең җыелмасы була алмый, башка функциональ кебек үк бер рәткә куеп каралырга тиеш. Аның иҗтимагый тормышта үзенә йөкләтелгән вазифасы бар”.

С.Ибраһимовның М.Зәкиев белән берлектә язылган IX класс дәреслегендә бу стиль әдәби стиль дип атала һәм әдәби телнең нигезен тәшкил итә торган стиль дип билгеләнә. Матур әдәбият стиленең дә үзенә хас табигате һәм вазифасы бар. Шушы нигездә ул башка стильләр белән бер рәткә куелып карала ала.

Табигате. Татар әдәби теленең алдагы төрдәге функциональ стильләреннән аермалы буларак, чынбарлыкны образлар ярдәмендә чагылдырып тасвирлау өчен формалашкан һәм үсеш алган махсус сөйләм тибы.

Вазифасы. Сәнгатьле сөйләм дип атала торган әлеге стильнең чынбарлыкны образлар ярдәмендә тасвир итеп укучыга эстетик тәэсир ясау, эстетик тәрбия бирү, димәк, кешенең җанын, рухын үстерү һәм камилләштерү вазифасын үтәве истә тотыла.

Бу стиль матурлык, гүзәллекне чагылдыручы сөйләм тибы булып санала. Әлеге төшенчәләр психология, эстетика, фәлсәфә һ.б. өйрәнелә. Һәрвакыт образ, образлылык дигән категория беән бәйләнә. Әлеге стильне өйрәнүдә образлылыкны белү зарур.

Матур әдәбият жанрлары турында төшенчә: лирика, лиро-эпик төркем, проза һ.б.

Әдәби әсәрләрнең композициясе, төзелеше үзенчәлекләре һәр әсәрне аерым алып тикшергәндә шул әдипнең индивидуаль стилен билгели алабыз. Индивидуаль стиль дигәндә, төзелеше белән бергә тел берәмлекләрен ничек файдалану да, автор фикеренең ничек укучыга җиткерелүе дә җентекләп тикшерелә.

- **Публицистика стиле.** Публицистика (лат.“Публикус”, нем. ”публицистик” – җәмгыять) иҗтимагый дигән мәгънәдә иҗтимагый-публицистик дип тә атала.

Бу стиль җәмгыятьтә берөзлексез булып тора торган вакыйга-хәлләр белән тыгыз бәйләнештә яши, табигатен шушы үзенчәлекләр билгели. Табигате – эш-хәлләрне күреп, белеп аңлау һәм бәяләү эшчәнлеген чагылдыру өчен барлыкка килгән сөйләм тибы.

Вазифасы – халыкка информация бирү. Җәмгыятьтә күп вакыйгалар булып тора. аны халыкка җиткерү эше зур осталык, ныклы белем, көч сорый.

Төп иҗат методы, алымы – теге яки бу фикерне укучыга турыдан-туры әйтү, язу юлы белән җиткерү, дөреслекне сөйләү.

Фәнни стильдә фәнни фикер эзлекле языла, матур әдәбиятта әйтелергә тиешле фикер образларны тасвирлау юлы белән бирелә, публицистикада – турыдан-туры язып ышандыру. Җанлы сөйләм рәвешендә булырга мөмкин, ләкин турыдан-туры ышандыруның язма төрләре актив. Әлеге төрләр вакытлы матбугат битләрендә дөнья күрә, “вакытлы матбугат стиле” дип тә атала. Табигатенең үзенчәлекләре, вазифасының киңлеге әлеге төрләрнең төзелешен дә катлауландыра. Эш кәгазьләре кебек үк үз эчендә күп төрләргә бүленә. Әлеге стиль иң башта укучыга җиткерелүче информациянең ничек итеп бирелешенә карап өч төркемгә бүленә:

1. Саф информация бирү:

- гади хәбәр итү;
- хроника хәбәр итү;
- киңәйтелгән (аңлатмалы) хәбәр итү;
- отчет бирү;
- репортаж ясау;
- хат-хәбәр.

2. Билгеле бер дәрәҗәдә укучының акылына һәм хис-кичерешләренә тәэсир итү рәвешендә:

- агитацияләү (баш мәкалә);
- ышандыру-үгетләү өчен язылган мәкаләләр;
- аналитик проблемалы мәкаләләр.

3. Билгеле бер дәрәҗәдә сәнгать кануннары белән язу: парча, очерк, памфлет, фельетон, эссе, нәсер һ.б.

Бу төр язмаларда фикер образлы тасвирлауга нигезләнә, язучының шәхси хисләре зуррак бирелә.

Публицистика стилен барлыкка китерүче төрләрнең һәрберсенең үзенә генә хас төзелеше, тел берәмлекләрен махсус сайлап алуы була, язучының үз мөнәсәбәтен чагылдыруы була.

Хроника-хәбәр – газетаның төп жанры. Мөһим булган бер фактны тиз генә укучыга җиткерү. Композицион яктан җыйнак. “Кече текст”. Төп фикер беренче җөмләдән үк әйтелә. Беренче җөмлә нинди сүз белән тәмамланса, икенчесе шул сүз белән башланырга мөмкин. Язучының мөнәсәбәте чагылмый – “бәясез модальлек”.

Киңәйтелгән хәбәр – композицион яктан да, фикерне әйтү ягыннан да катлаулы. Автор факт турында хәбәр итә, аңлатма бирә, сәбәп-нәтиҗәләрен ачыкларга омтыла. Берничә “кече тесттан” оеша. “Рациональ бәяле модальлек” чагылышы таба, аерым шәхеснең генә түгел, коллектив тәҗрибәсенә нигезләнгән, мәгънә эчтәлегендә бәяләү төсмере булган сүз һәм сүз тезмәләренә мөрәҗәгать ителә - “бәяле газета лексикасы”. Гадәти телдә мәгънә эчтәлегендә бәяләү төсмере булмаган сүзләр дә газета текстында еш кабатланырга, билгеле бер дәрәҗәдә бәяләү төсмерен чагылдыра ала.

Интервью (инг. беседа), репортаж (лат. хәбәр итү) мөһим бер вакыйганы яктырту. Сөйләүче һәм тыңлаучы алгы планга чыга.

- **Татар әдәби телендә хатлар стиле.** Табигате – кешеләр арасында шәхси мөнәсәбәтләрне чагылдыру өчен калыплашкан махсус сөйләм тибы.

Вазифасы. Ул тормышта, җәмгыятьтә аерым кешеләр арасында шәхси мөнәсәбәтләрне, хис-кичерешләрне, хәбәр юллауны чагылдыра һәм җитәкли. Бу мөнәсәбәтләр күптөрле, шуңа күрә хатларның кемнән кемгә язылуына карап төрләре күп.

XX гасырның 10-15 нче елларында хат язарга махсус рәвештә өйрәтү үрнәкләре языла. Хатларның ничек итеп язылырга тиешлеген аңлаткан ысуллар күрсәтелгән хезмәтләр басыла.

Аларда хатларның кемнән-кемгә булуына карап, төрләре бирелә. Хат багышланган кешегә ничек мөрәҗәгать итү, шул эндәш сүзләр янына тагын нинди сүзләр куярга кирәк булу өйрәтелә.

Хат стиле турында Х.Курбатов (1971) хат стиле – "җанлы сөйләмнең бер үрнәге", - ди. Зәкиев һәм Ираһимов үзләренең IX класс дәреслегендә дә шул фикердә.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Хәзерге татар әдәби телендә сөйләшү стиле: табигате, вазифасы, жанр-төрләре, тарихи үсеш-үзгәреше.

2. Хәзерге татар әдәби телендә язма стильләр турында төшенчә.

3. Татар телендә рәсми эш кәгазьләре стиле: табигате, вазифасы, жанр-төрләре, тарихи үсеш-үзгәреше.

4. Татар телендә фәнни-әдәбият стиле: табигате, вазифасы, жанр-төрләре, тарихи үсеш-үзгәреше.

5. Татар телендә иҗтимагый-публицистика стиле: табигате, вазифасы, жанр-төрләре, тарихи үсеш-үзгәреше.

6. Татар телендә матур әдәбият стиле: табигате, вазифасы, жанр-төрләре, тарихи үсеш-үзгәреше.

7. Татар телендә хатлар стиле: табигате, вазифасы, жанр-төрләре, тарихи үсеш-үзгәреше.

8. Татар телендә дини дидактика стиле: табигате, вазифасы, жанр-төрләре, тарихи үсеш-үзгәреше. Стиль буларак өйрәнелмәве.

9. Татар телендә көндәлек-һөнәри стиль: табигате, вазифасы, жанр-төрләре, тарихи үсеш-үзгәреше, өйрәнелешенең җитәрлек булмавы.

Әдәбият исемлеге.

1. Бәширова И.Б. Фәнни әдәбият стиле: гомуми мәгълүмат / И.Б.Бәширова // Фән һәм тел. – 2000. - № 3 – Б. 12-15.

2. Бәширова И.Б. Татар стилистикасының теоретик нигезләре. Татар филологиясе һәм тарихы факультеты студентлары өчен программа / И.Б.Бәширова. – Казан: Казан дәүләт ун-ты, 2005. – 29 б.

3. Гарифуллин В.З. Хәбәри жанрлар: Университетның журналистика факультеты студентлары өчен уку ярдәмлеге / В.З.Гарифуллин. - Казан: КГУ нәшр., 1991. – 42 б.

4. Ибраһимов С.М. Сандугач теле кирәк: Синтаксик стилистика: Уку-укыту ярдәмлеге / С.М.Ибраһимов. – Казан: Мәгариф, 2008. – 159 б.

5. Курбатов Х.Р. Хәзерге татар әдәби теленең стилистик системасы / Х.Р.Курбатов. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1971. – 192 б.

6. Курбатов Х.Р. Сүз сәнгате: Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы / Х.Р.Курбатов. – Казан: Мәгариф, 2002. – 199 б.

7. Низамов И.М. Матбугатның тәэсирле сүзе: Газета лексикасы мәсьәләләре / И.М.Низамов. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1981. – 144 б.

8. Тимерханов А.А. Язык деловых бумаг в современном татарском языке / А.А.Тимерханов. – Казан: Гуманитария, 2002.

9. Хаков В.Х. Татар әдәби теле (стилистика) / В.Х.Хаков. – Казан: Тат. кит. нәшр, 1999. – 304 б.

Тема 6. Лингвистик стилистика (синтаксик стилистика): синтаксик стилистиканың төп предметы, максат-бурычлары. Синтаксик стилистика һәм синтаксик синонимнарның өйрәнелеш тарихы

Лекция 6

Аннотация. Лекциядә лингвистик стилистика һәм аның бер тармагы булган синтаксик стилистика турында фәнни-торетик мәгълүмат бирелә. Синтаксик стилистиканы өйрәнү предметы һәм бурычлары, тикшерү объекты билгеләнә, телдәге синтаксик берәмлекләрне сөйләмдә стилистик куллану юлларын өйрәнүнең фәнни һәм гамәли максатлары күрсәтелә, шулай ук синтаксик стилистика һәм синтаксик синонимнарның өйрәнелеш тарихына күзәтү ясала.

Ачкыч сүзләр: стилистика, лингвистик стилистика, синтаксик синонимнар.

Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр. Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың

үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

Лекциянең планы:

1. Синтаксик стилистиканы өйрәнү предметы һәм бурычлары, тикшерү объекты.

2. Телдәге синтаксик берәмлекләрне сөйләмдә стилистик куллану юлларын өйрәнүнең фәнни һәм гамәли максатлары.

3. Синтаксик стилистика һәм синтаксик синонимнарның өйрәнелеш тарихы.

Синтаксик стилистика, гомуми стилистиканың бер тармагы буларак, хәзерге татар әдәби сөйләмен үзенең төп өйрәнү объекты итеп ала. Татар сөйләме өчен иң әһәмиятле тармак. Стилистика түбәндәге өлешләрне берләштерә: 1) тел һәм сөйләм стильләре турында тәгълимат; 2) тел һәм сөйләмнең тулаем стиль чаралары.

Димәк, стилистика телдәге стильләр һәм аларга хас тел-сурәтләү чараларын өйрәнә торган фән. Стиль (грекча – таякчык) – язу манерасы, чынбарлыкны бирү алымнарын аңлата. Стиль – тел-сөйләм чараларыннан, мөмкинлекләреннән файдалану алымнарының теге яки бу төре, шуңа хас билгеләр.

Тикшерү объекты – хәзерге татар әдәби сөйләменең кулланылышы. Төп предметы – телдәге синтаксик берәмлекләрне сөйләмдә стилистик куллану. Синтаксик стилистика нәкъ шул берәмлекләрне сөйләмдә ничек куллану юлларын өйрәнүне үзенең максаты итеп куя. Шул рәвешле синтаксик берәмлекләрне (сүзтезмә, җөмлә, синтагма, сиктаксик бөтен) стилистик куллану алымнары, шуларны истә тотып, сөйләмдә иң кирәкле төрне сайлап алу мөмкинлекләре бу фәннең үзәгендә ята.

Бурычлары:

1. Сүзтезмә һәм җөмләдә сүзләрнең мәгънә ягыннан сыешуы һәм аңа бәйле күренешләрне өйрәнү;

2. Гади җөмләләрне стилисти ктикшерү;

3. Татар телендә стиль әйләнмәләрен өйрәнү;

4. Синтаксик синонимнарны тикшерү;

5. Синтаксик омонимнарны тикшерү;

6. Кушма җөмләләрне стилистик кулану һ.б.

Синтаксик стилистика һәм синтаксик синонимнарның өйрәнелеш тарихы. Синтаксик стилистиканы җентекләп өйрәнүче һәм төзек бер системага салучы – Сәгадәт Мөгаллимович Ибраһимов.

1. Синтаксик стилистика. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1976. – 150 б.

2. Татар телендә синтаксик синонимнар. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1989. – 168 б.

“Татар телендә синтаксик синонимнар” хезмәтендә автор татар тел белемендә аз тикшерелгән, әмма сөйләм өчен зур әһәмияте булган синтаксик синонимнарны, аларның төрләрен, кулланылышын өйрәнә. Аларның телне баетудагы, сөйләм матурлыгын арттыру һәм стильне камилләштерүдәге урынын күрсәтә. Синтаксик синонимнарны читләтеп, исәпкә алмыйча эш итүнең стильгә, әдәби телебезгә зарар китерү ихтималы да искәртелә.

“Синтаксик стилистика” хезмәтендә исә сөйләм берәмлекләрен стилистик куллану, синтаксик синоним һәм омоним күренешләре кебек мәсьәләләр яктыртыла.

Гомумән, синтаксик стилистиканы өйрәнүнең тамырлары С.Кукляшевтан башлана: “Диване хикәяте татар” (1859) хезмәтендә әдәбиттекстлар, хатлар, халык авыз иҗаты үрнәкләре, эш кәгазьләре өч стильгә бүлеп биргәндә, аларның стилистик үзенчәлекләре дә искә алына. Соңрак өч стиль мәсьәләсенә бәйле фикерләр К.Насыйри, Н.Ф.Катанов хезмәтләрендә дә урын ала.

XX гасырның 30 нчы елларында синтаксик стилистика мәсьәләләрен генә үз эченә алган хезмәтләр дөнья күрә: Л.Җәләй “Сурәтләү чарасы булучылыкта җөмләнең аерымланган кисәкләре” (Сов.әд., 1935, № 12), “Татар телендә аерымлануның стилистик функциясе” (Мәгариф, 1936, №6), Ф.Хәмидулла “Җөмләдә сүз тәртибе һәм инверсия” (Сов.әд., 1936, № 2) исемле мәкаләләр.

Синтаксик стилистиканың аерым мәсьәләләре шулай ук гомумән стиль турындагы язмаларда чагылыш таба. Мәсәлән, С.Атнагулов һәм Г.Алпаров кушымчалар, бәйлекләр ярдәмендә төзелгән җөмләләрнең теркәгечләр, мөнәсәбәтле сүзләр белән бәйләнешкә кергән кушма җөмләләргә синоним рәвешендә кулланылуын билгелиләр (Грамматика. Синтаксис. – Казан, 1934). 1930 нчы елларда басылып чыккан хезмәтләрдә синтаксик стилистиканың күп кенә мәсьәләләре кузгатыла. Мәсәлән:

1. Сүзтезмәләрне стилистик куллану мәсьәләре;
2. Сүзтезмәләрне оештырудагы икенче мәсьәлә – бәйләүче чара;
3. Сөйләмдә инверсия мәсьәләсе;
4. Синтаксик омоним күренеше;
5. Чагыштырулы төзелмәләр стилистик куллану мәсьәләсе һ.б.

1940 нчы елларда фәнгә карата сүлпәнлек күзәтелә. 1940 нчы елда В.Хангилдинның “Татар теленең синонимикасы” исемле мәкаләсе басыла (Сов. мәк., 1940, № 11-12). Бу – татар телендә синонимнарга багышланган беренче фәнни хезмәт булу белән бергә, грамматик синонимнарны билгеләү юлында беренче омтылыш та санала.

1950-60 нчы елларда монографик тикшеренүләр дөнья күрә башлый. Х.Курбатовның “Татар теленең синтаксис һәм стилистика мәсьәләләре” (1956) хезмәтендә уртак сөйләм күренеше фәнни яктыртыла, туры һәм кыек сөйләмнең синонимлыгы мәсьәләрен җентекләп тикшерә.

В.Хаков “Татар теле стилистикасы кереш” (1963) китабында публицистик стильне өйрәнү барышында сүз һәм фразеологик берәмлекләрнең кулланылышын, җөмлә төзелешендәге үзенчәлекләрне һ.б. тикшерүгә зур урын бирә.

М.З.Зәкиев “Синтаксический строй татарского языка” (1963) монографиясендә стилистиканың башка мәсьәләрен тикшергәндә синтаксик синонимнарның аерым төрләренә урын бирә. “Синонимика аналитических и синтетических конструкций” (1971) хезмәтендә синтаксик синонимлыкны турыдан-туры өйрәнә.

1961 нче елда синтаксик синонимнарга аерым билгеләмә бирелеп, алырның кайбер төрләрен тулы яктырткан махсус хезмәт дөнья күрә. Шифа Ханбикова “Татар телендә синонимнар” (1961) китабы ике өлештән тора, икенче өлешендә грамматик синонимнар тикшерелә.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Синтаксик стилистиканы өйрәнү предметы һәм бурычлары, тикшерү объекты билгеләгез?

2. Телдәге синтаксик берәмлекләрне сөйләмдә стилистик куллану юлларын өйрәнүнең фәнни һәм гамәли максатларын күрсәтегез?.

3. XIX гасыр – XX гасырның беренче яртысында синтаксик стилистика мәсьәләләрен өйрәнү тарихы (С.Кукляшев, К.Насыйри, Һ.Максуди, Х.Бәдигый, Л.Җәләй, Ш.Рамазанов эшчәнлеге һ.б.).

4. XX гасырның икенче яртысы – XXI йөз башында синтаксик стилистика һәм синтаксик синонимнарның өйрәнелеш тарихы (Ш.Ханбикова, Х.Р.Курбатов, В.Х.Хаков, М.З.Зәкиев, С.М.Ибраһимов эшчәнлеге).

Әдәбият исемлеге.

1. Ибраһимов С.М. Татар телендә синтаксик синонимнар / С.М.Ибраһимов. – Казан: КДУ нәшр., 1976. – 168 б.

2. Ибраһимов С.М. Синтаксик стилистика / С.М.Ибраһимов. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1989. – 150 б.

3. Ибраһимов С.М. Сандугач теле кирәк: Синтаксик ситилистика: Уку-укыту ярдәмлеге / С.М.Ибраһимов. – Казан: Мәгариф, 2008. – 159 б.

4. Кузьмина Х.Х. Фонетик стилистика / Х.Х. Кузьмина // Милли мәдәният. – 2006. – № 9. - С.44-45.

5. Кузьмина Х.Х. Фонетик стилистика мәсьәләләре / Х.Х.Кузьмина // Milli mədəniət. – 2006. – № 11. – Б. 55-57.

6. Курбатов Х.Р. Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы / Х.Р.Курбатов. – Казан: Мәгариф, 2002. – 199 б.

7. Солганик Г.Я. Синтаксическая стилистика: Сложное целое / Г.Я.Слоганик. – М.: Высш. школа, 2003. – 214 с.

8. Ханбикова Ш.С. Татар телендә синонимнар / Ш.С.Ханбикова. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1961. – 70 б.

9. Ханбикова Ш.С. Татар телендә синонимия һәм сүзлекләр / Ш.С.Ханбикова. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1980. – 208 б.

10. Хангилдин В.Н. Татар теленең синонимикасы / В.Хангилдин // Совет мәктәбе, 1940. – № 11-12. – Б. 47-49.

Тема 7. Синтаксик синонимнар, тәңгәлләр һәм синтаксик вариантлар. Синтаксик синонимнар: структур һәм функциональ төрләре

Лекция 7

Аннотация. Лекциядә синтаксик синонимнар, аларга билгеләмә бирү мәсьәләсе, синтаксик синонимнарның синтаксик тәңгәлләр һәм синтаксик вариантлар белән мөнәсәбәте турында фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Синтаксик тәңгәлләр һәм синтаксик синонимнарның төрләре өйрәнелә. Синтаксик синонимнарның структур һәм функциональ төрләре аерымланып, аларның кулланылыш үзенчәлекләре ачыклана

Ачкыч сүзләр: синтаксик синонимнар, синтаксик тәңгәл, синтаксик вариант, беренче дәрәҗә синоним, икенче дәрәҗә синоним, синтаксик синонимнарның фунциональ төрләре, сүзтезмә, чагыштырулы төзелмә, берсоставлы җөмлә, актив төзелмә, пассив төзелмә, юнәлеш категориясе.

Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр. Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

Лекциянең планы:

1. Татар телендә синтаксик синонимнар: синтаксик синонимнарны өйрәнүнең әһәмияте һәм синтаксик синонимнар мәсьәләләрен өйрәнү тарихы.

2. Синтаксик синонимнарга билгеләмә бирү мәсьәләсе һәм аларның төрләре, принциплары.

3. Синтаксик синонимнар, синтаксик тәңгәлләр һәм синтаксик вариантлар.

4. Синтаксик синонимнарның функциональ төрләре: сүзтезмәләрнең синонимлыгы.

5. Синтаксик синонимнарның функциональ төрләре: чагыштырулы төзелмәләр һәм аларның синонимлыгы.

6. Синтаксик синонимнарның функциональ төрләре: бер составлы җөмләләр һәм аларның синонимлыгы.

7. Синтаксик синонимнарның функциональ төрләре: актив һәм пассив төзелмәләрнең синонимлыгы.

Татар телендә синтаксик синонимнар

Синтаксик синонимнар синтаксик стилистиканың төп мәсьәләләреннән санала. Алар сөйләмнең төгәллегенә ирешүдә әһәмиятле урын тоталар. Берүк мәгънә мөнәсәбәтен бирү өчен төрле чаралар бар. Иң кирәклесен сайлап алу – синтаксик стилистиканың төп бурычы. Синтаксик синонимнар дигәндә, ике компонент арасындагы мәгънә мөнәсәбәтен төрле чаралар ярдәмендә белдерә алуга әйтәләр:

Кунаклар белән арган кебек тоела.

Кунаклардан арган кебек тоела.

Синтаксик синонимнарның өйрәнелә башлавы М.Казыймбеккә барып тоташа. Ул 1939 нчы елда “Грамматика турецко-татарского языка” дигән хезмәтен яза. Бу хезмәттә беренчеләрдән булып, җыючы теркәгечләр ярдәмендә бәйләнгән җөмләләргә синоним итеп, теркәгечләр, мөнәсәбәтле сүзләр ярдәмендә төзелгән җөмләләрне китерә.

1891 нче елда “Әнмүзәҗ”дә К.Насыйри җөмләләргә синоним буларак сүз тезмәләрне китерә.

М.Корбангалиев һәм Х.Бәдигыйның 1919 нчы елда “Ана теле нәхүе” дигән дәреслеге басыла. Дәреслектә иярчен җөмләләрнең бер төрен икенче

төргә әйләндерәләр, ягъни берүк мәгънәне берничә төзелешле җөмләләр белән бирәләр.

1919 нчы елда Җ.Вәлиди дә шул ук мәсьәләне карый.

1934 нче елда Г.Алпаров һәм С.Атнагулов бәйлекләр, кушымчалар ярдәмендә төзелгән җөмләләрне теркәгечләр, мөнәсәбәтле сүзләр белән бәйләнешкә кергән җөмләләргә синоним буларак кулланалар.

1940 нчы елда В.Хангилдинның "Татар теленең синонимикасы" исемле мәкаләсе басыла (Сов. мәк., 1940, № 11-12). Бу автор беренчеләрдән булып синтаксик синонимнарга билгеләмә бирә һәм грамматик синонимнарның критериясен билгели. Бу җөмләләрдәге хәбәрләрне катлауландырып, автор грамматик синонимнарны аңлауны кыенлаштыра.Мәсәлән:

Яңгыр яуганлыктан, без экскурсиягә бара алмадык.

Яңгыр яуганга күрә, без экскурсиягә бара алмадык.

Л.Җәләй "Татар диалектологиясе" (1947) хезмәтендә иярчен вакыт җөмләләрнең ундүрт төрен күрсәтә. Алар арасында синтаксик синонимнар күп, ләкин эчтәлек белән генә тәңгәл төзелмәләр дә бар. Шул ук вакытта әлеге җөмләләр эчендә бер-берсеннән бары тик кисәкчәләр белән генә аерылып торучы җөмләләр дә бар:

Яңгыр яву белән үләннәр яшәрде.

Яңгыр яугач, үләннәр яшәрде.

Яңгыр яуды һәм үләннәр яшәрде.

Яңгыр яву белән үк үләннәр яшәрде.

Яңгырдан соң үләннәр яшәрде.

1961 нче елда Ш.Ханбикованың "Татар телендә синонимнар" дигән хезмәтендә синтаксик синонимнар автор тарафыннан җентекләп тикшерелә. Мәсәлән:

Синең белән сөйләшсәң, күп гөмбә җыя алмыйсың.

Синең белән сөйләшеп, күп гөмбә җыя алмыйсың.

Матур көндә чыгам кырга,

Ачылмасмы күңелләр дип. (М.Гафури)

Матур көндә кырга (максат хәле) күңелләр ачарга дип чыгам.

1963 нче елда М.З.Зәкиевның “Синтаксический строй татарского языка” хезмәте чыга. Биредә синтетик һәм аналитик җөмләләрнең синонимлыгы, бер сүз тезмәнең икенчесенә синонимлыгы һ.б. карала.

1976 нчы елда С.М.Ибраһимов “Татар телендә синтаксик синонимнар” хезмәте чыга.

Синтаксик синонимнарны билгеләүнең бер төрле генә принцибы юк, нигезендә яткан берничә принцип бар.

1. В.П.Сухотин “Реаль чынбарлыктагы күренешләрнең бердәй бәйләнеш һәм мөнәсәбәтен чагылдырып, төзелешләре белән аерыла торган конструкцияләр синтаксик синоним итеп санала.” Синтаксик синонимнарны билгеләүнең төп критериесе итеп, синтаксик төзелмәләрдәге аермалыклар алына. Автор грамматик мәгънәне күз алдында тотмый.

2. А.Пешковский һәм А.Н.Гвоздев синтаксик синонимнарның бер-берсен алыштыра алу мөмкинлекләренә игътибар итәләр, ләкин шул ук вакытта грамматик мөнәсәбәт һәм аларны белдерүче чаралар белән эш итәргә кирәклек исәпкә алынмый.

3. А.Л.Шумилина билгеләвенчә, синтаксик мәгънәләре белән тәңгәл килүче, бары тик бәйләүче чаралары белән генә аерыла торган төзелмәләр синтаксик синоним исәпләнәләр. Бу очракта синонимнарның функцияләре бары тик форма ягыннан гына берсен-берсе алмаштыруга кайтып калыр иде.

1940 нчы елда В.Хангилдин “Татар теле синонимикасы” мәкаләсендә татар тел белемендә синтаксик синонимнарга билгеләмә бирә: “...Чыккан тамырлары һәм фонетик, морфологик төзелешләре ягыннан башка төрле булып та, уртак бер төшенчәгә ия булган, бары тик мәгънә оттеноклары белән генә аерыла торга сүзләр, шулай ук уртак төшенчәне аерым оттеноклары белән генә тәгъбир итә торган, ләкин төзелешләре белән бер-берсеннән азмы-күпме аерымлыклары булган (сүзләр яки сүзләр арасындагы бәйләнеш формаларында) сүз тезмәләре синоним дип аталалар (47 бит).

Автор бу билгеләмәдә лексик һәм грамматик синонимнарны беррәттән ала. Алар арасында уртак яклар булса да, һәрберсенең үзенә генә хас үзенчәлекләре бар. Билгеләмәнең икенче өлешендә синтаксик синонимнар күздә тотыла һәм аларның өч үзенчәлеге аерып күрсәтелә:

- мәгънә берлеге;

- төзелеш аерымлыгы;

- бәйләүче чара.

Бу билгеләмә (билгеләр) синтаксик параллельләр, синтаксик вариантларга да карарга мөмкин. С.М.Ибраһимов: "Төзелмәдәге сүзләр арасында аермалык булу ул – синтаксик синонимнарны билгеләү өчен җитәрлек нигез санала алмый" (Татар телендә синтаксик синонимнар, 1976. Б. 24).

Ш.Ханбикова "Татар телендә синонимнар" (1961) хезмәтендә: "Бер үк реаль мәгънәсе булган, ләкин грамматик структурасы һәм функциональ мәгънә төсмерләре белән аерыла торган сүз тезмәләре һәм җөмләләр синтаксик синонимикага керәләр" (49 бит). (Сухотин принцибына якын). Ш.Ханбикова бәйләүче чараларның аерымлыгын исәпкә алмый.

Синтаксик синонимнар дигәндә, төзелешләре һәм бәйләүче чаралары белән аерылып торучы төзелмәләр алынырга тиеш. Иң тулы билгеләмә С.М.Ибраһимов тарафыннан бирелә: "Компонентлары арасындагы мәгънә мөнәсәбәте һәм грамматик функциясе белән бер-берсенә якын, ләкин синтаксик төзелеше, шулай ук бәйләүче чаралары белән аерыла торган төзелмәләр (сүзтезмә, әйләнмә һәм җөмләләр) синтаксик синоним итеп карала. (Татар телендә синтаксик синонимнар, 1976. Б. 26.).

Ул ятим булганлыктан, алар аны кактылар да суктылар.

Алар аны кактылар да суктылар, чөнки ул ятим иде.

Бу ике төзелмәнең һәр икесендә дә компонентлар бер үк мәгънә мөнәсәбәтендә торалар, ияртүче компонентлар бер үк грамматик функцияне үти. Димәк, алар компонентлар арасындагы мәгънә мөнәсәбәтләре һәм грамматик функцияләре белән туры килә, бары тик төзелешләре (синтетик, аналитик) һәм бәйләүче чаралары белә аерылалар.

Алдагы мисалда функциональ яктан якынлык башкачарак:

Тау өсте пыяла вагы сибелгәндәй ялтырап ята.

Тау өсте пыяла вагы сипкәндәй ялтырап ята.

Бәйләүче чара – сыйфат фигыль формасы һәм чагыштыру кушымчасы. Мәгънә мөнәсәбәте – ияртүче компоненттагы процессның ни рәвешле булуын иярүче компонент ачыклый. Функциональ якынлык – беренчесендә – иярчен рәвеш җөмлә, икенчесендә – рәвеш хәле.

Синтаксик синонимнар, синтаксик тәңгәлләр һәм синтаксик вариантлар

Тел белемендә синтаксик синоним, синтаксик тәңгәл, синтаксик вариант төшенчәләрен бер-берсеннән аерып карарга, аларның үзләренә генә хас билгеләрен исәпкә алып эш итәргә кирәклек зарури санала.

Синтаксик синоним булу өчен эчтәлек һәм мәгънә якынлыгы гына җитми, төзелмәләр грамматик функцияләре ягыннан да бер-берсенә якын булырга тиеш. Синтаксик тәңгәлләрдә исә функциональ якынлык таләп ителми, функцияләрнең бердәй булуы мәҗбүр итеп куелмый. Димәк, синтаксик синонимнарга караганда, синтаксик тәңгәлләр киңрәк планда карала, тәңгәлләр эчендә синонимнар бүленеп чыгарыла.

25 ел буе бу шигырьне кабат укыганы юк иде аның, шулай да балачакта күңелгә бикләнгән шигырь онытылмый икән.

25 ел буе бу шигырьне кабат укыганы юк иде аның, ләкин балачакта күңелгә бикләнгән шигырь онытылмый икән.

Җөмләләрдә функциональ якынлык юк: иярчен җөмлә һәм тезмә кушма җөмлә. Бу ике җөмлә үзара синтаксик тәңгәл.

Яңгыр яугач, көннәр җылынып китте.

Яңгыр яуганнан соң, көннәр җылынып китте.

Яңгыр яуды, шуннан соң көннәр җылынып китте.

Яңгыр яуды, һәм көннәр җылынып китте.

Бу дүрт җөмлә дә синтаксик тәңгәлләр итеп арала ала. Синтаксик синонимнарны синтаксик тәңгәлләр эченнән сайлап алабыз. Димәк, синтаксик тңңгәлләрдә грамматик күренеш киңрәк күләмдә алына, синтаксик синонимнарда ул тарая, конкретлаша.

Реаль чынбарлыктагы бердәй күренеш һәм бәйләнешләрне төрле юллар белән бирә алучы, мәгънәләре белән якын төзелмәләр синтаксик тәңгәлләр дип йөртелә. (Синтаксик стилистика, 1989. Б. 55.; Тат. тел. синт. син., Б.36.).

Татар телендә синтаксик тәңгәлләрнең берничә төрен билгеләргә мөмкин. Аның иң таралганы – ияртүле һәм тезүле бәйләнеш нигезендә барлыкка килгән тәңгәлләр. Тәңгәлләр семантик яктан да бер-берсеннән аерылып торырга мөмкиннәр (вакыт һәм сәбәп мөнәсәбәтен, каршылык нисбәтендә торган төзелмәләр).

Синтаксик тәңгәлләр синтаксик синонимнардан киңрәк төшенчәне белдерсәләр, синтаксик вариантлар исә таррак күләмдә каралалар. Шул ук вакытта алар синтаксик синонимнарның бер өлеше булып тормыйлар.

Синтаксик вариант итеп алынган төзелмәләр үзләренең төзелешләре, бәйләүче чаралары белән бердәй булалар, бары тик аерым сүзләрнең тәртибе, кисәкчәләрнең, кайбер формаль күрсәткечләрнең булу-булмавы белән генә бер-берсеннән аерылып торалар. Синтаксик вариантлар бер үк синтаксик берәмлекләр эчендә генә билгеләнәләр. Синтаксик вариантларның түбәндәге төрләрен аерып чыгарырга мөмкин:

1. Сүз тәртибендәге үзгәрешләр;

2. Җөмләдә аерым кисәкчәләрне куллану яки кулланмау билгеләнә (чикләүче кисәкчә – гына, генә; күрсәтүче кисәкчә – менә, шушы; көчәйткеч кисәкчә – иң, бик);

3. Сүзләрне, аерым әйләнмәләрне кабатлау;

4. Ким җөмләнең ваианты итеп тулы җөмлә карала;

5. Ия күплектә булып та, хәбәрне берлектә куллану. моңа вариант итеп ияне дә, хәбәрне дә күплектә куллану;

6. Мөнәсәбәтле сүзләр ярдәмендә бәйләнешкә кергән кушма җөмләдә шарт фигыль кушымчасы куллану: *Кемнең кесәсенә ут төшсә, шул яна. Кемнең кесәсенә ут төшә, шул яна.*

7. Өстәлмә конструкцияле җөмләләрнең варианты итеп, шундый ук сүзләр белән килгән гадәти төзелештәге җөмләләр алына.

Синтаксик синонимнарның функциональ төрләре: сүзтезмәләрнең синонимлыгы

Синтаксик синонимнарның функциональ төрләре. Сннтаксик синонимнарның фунциональ яктан төркемләгәндә, синтаксик берәмлекләрнең түбәндәге төрләрен аерып чыгаралар:

1. Сүзтезмәләрнең синонимлыгы;
2. Бер составлы җөмләләрнең синонимлыгы;
3. Актив һәм пассив төзелмәләрнең синонимлыгы;
4. Раслау һәм инкяр җөмләләрнең синонимлыгы;
5. Җөмлә кисәге белән иярчен җөмлә синонимлыгы;
6. Аналитик һәм синтетик төзелмәләрнең синонимлыгы;
7. Чагыштырулы төзелмәләр һәм аларның синонимлыгы;
8. Туры һәм кыек сөйләмнең синонимлыгы.

Мәсәлән: Инде менә ут сүнәргә ике генә сәгать калып бара (Р.Төхвәтуллин). Шәриф бер дә эндәшми генә, нәрсә ашарбыз икән дип торган чакта Бәдри ашарга рәтли башлады (М.Гафури).

Сүзтезмәләрнең синонимлыгы. Компонентлары (иярүче һәм ияртүче сүз) арасындагы мәгънә мөнәсәбәте һәм синтаксик функцияләре белән бер-берсенә якын, ә төзелешләре, бәйләүче чаралары белән аерыла торган сүзтезмәләр үзара синоним булалар.

Ул авырганга килмәде. Авыргач килмәде. Авырганлыктан килмәде. Авыру сәбәпле килмәде.

Бу китап 1990 нчы елда (елны) басыла.

Сүзтезмәләр турында фикер йөртү ул – нигездә бәйләүче чараларның күп төрлелегеннән файдалану, аларны эшкә җигү дигән сүз. Бер җөмлә эчендә ияртүче сүз ияртүче сүзгә нинди дә булса бәйләүче чара белән ияреп, билгеле бер мәгънә мөнәсәбәтен бирсә, икенче җөмләдә шул ук мәгънә мөнәсәбәтен, шул ук синтаксик функцияләр җирлегендә башка бәйләүче чара аша чагылдырып була.

Сүзтезмәләрдәге синонимнар да үзләренең структур төрләре белән икегә бүленеп йөртелә: беренче һәм икенче дәрәҗә синонимнар:

Эзләгәнен кеше һәрвакыт табар – Кеше ни эзләсә, шуны һәрвакыт табар.

Сүзтезмәләрнең синонимлыгын өйрәнгәндә, аларны синтаксик-морфологик принциптан чыгып төркемлибез. Шул юнәлештән карап, алар фигыль, исем, сыйфат, сан, рәвеш сүзтезмәләргә бүленәләр. Ияртүче сүзгә нисбәтле үз эчләрендә ваграк төркемнәр аерыла (исемле фигыль, фигыльле фигыль һ.б.).

Фигыль сүзтезмәләр. Бу сүзтезмәләрнең һәркайсы үз чиратында тагын бәйләүче чараларның нинди булуыннан чыгып төркемләнәләр.

Исемле фигыль сүзтезмәләр. Исем ияртүче сүз булган фигыльгә берничә төр чара белән иярергә мөмкин. Шундыйлардан килеш кушымчалары, чагыштыруны, әйбернең булу-булмавын белдерүче һ.б аффикслар, бәйлек һәм бәйлек сүзләр саналалар.

Исемнең фигыльгә килеш кушымчалары аша ияреүннән ясалган сүзтезмәләр һәм аларның синонимлыгы.

Юнәлеш килеш кушымчасы.

1. Ияртүче исме ияртүче сүздән аңлашылган процессның кая таба юнәлүен белдерә: *Җәмилә, әнисен култыклап, ишеккә (таба) юнәлде*.

2. Юнәлеш килешендәге исем ияртүче фигыльдән аңлашылган процессның кем өчен, нәрсә өчен үтәлүен белдерә һәм *өчен* бәйлеге, *дип* бәйлек сүзе ярдәмендә ясалган исемле фигыль сүзтезмәләргә синоним була:

Озак уйлап торгач, комод тартмасыннан ул *Ләйләгә* яулык *алды*. (*Ләйләгә дип алды, Ләйлә өчен алды*).

3. Юнәлеш килешендәге исем ияртүче фигыльдән аңлашылган процессның объектын белдерә:

Ул шакмаклы *кульяулыгына* бите *сөртеп алды* (*кульяулыгы белән сөртеп алды*).

4. Юнәлеш килештәге ияручe сүз фигыльдән аңлашылган процессны вакыт ягыннан ачыклап килә:

Гомергә бер балык *тоттым*, аны да ашаган кебек булмады (мәкаль). (*Гомердә тоттым*).

5. Юнәлеш кушымчасы алып ияргән сүз белән ияртүче фигыль арасында сәбәп мөнәсәбәте дә урнаша ала. Аңа синоним булган сүзтезмәләрнең бәйләүче чаралары булып *дип* бәйлек сүзе, *өчен* бәйлеге, *чыгыш килеш* кушымчасы санала:

Кешеләр кан койсын, сабыйлар бер телем сынык *икмәккә тилмерсен,* болар эчеп ятсыннар (Р.Төхвәтулин).

Бер телем *икмәккә дип*, анда назлы нечкә бил *җылый* (Г.Тукай).

Алардан *икмәк өчен* акча *алган идек*.

Төшем килеш кушымчасы.

1. Иярүче исем фигыльдән аңлашылган процессның туры объектын белдерә. Бу очракта төшем килеш кушымчасы ярдәмендә ясалган исемле фигыль сүзтезмәгә төшем килешенең кушымчасыз төре (билгесез килеш) аша ясалган исемле фигыль сүзтезмә синоним була һәм объектны белдерүче исем билгесезлек төсмеренә ия:

Коены күреп, туп-туры аның янына килде (*кое күреп*).

2. Исем ияртүче фигыльгә төшем килеше кушымчасы аша ияргәндә, процессның үтәлү вакытын да белдерә. Бу вакытта аңа белән бәйлеге, чыгыш килеше, тарихи яктан караганда корал килеше кушымчасы, урын-вакыт килеше кушымчасы, белән бәйлегенең кымкартылган варианты, билгесез килеш формасы аша ияргән исемле фигыль сүзтезмәләр синоним була:

Яңа йортка *кич белән күченделәр*. (*кичтән күченделәр, кичен күченделәр*)

3. Төшем килеше кушымчасы алган исем ияртүче фигыльдән аңлашылган процессның урынын да белдерә:

Авылны узып киттек (Н.Дәүли). Бары торгач, тагын ике *авыл үттек*.

4. Фикерләүгәбәйле мәгънәдәге фигыльләр белән килгәндә, төшем килешендәге исем сөйләү объектын белдерә һәм аңа *билгесез килеш* формасы, *турында, хакында* бәйлек сүзләре ярдәмендә ясалган фигыль сүзтезмәләр синоним була:

Мин, *бернәрсәне дә уйламыйча*, шактый озак тордым (*бернәрсә дә уйламыйча, бернәрсә турында да уйламыйча*).

Чыгыш килеше кушымчасы.

1. Чыгыш килешендәге исем, ияртүче фигыльдән аңлашылган процессның чыгу ноктасын белдерә:

Мин китапны *шкафтан алдым* (*шкаф эченнән алдым*).

2. Процессның урынын белдерә. Шушы ук мәгънә төсмерен бәйлек сүзләр ярдәмендә дә биреп була:

Караңгы *урамнан* сүзсез генә *кайттылар* алар (А.Гыйләҗев). Инде очрашудан өмет өзеп, *урам буйлап* акрын гына *кайтып китте* Корякин (А.Гыйләҗев).

3. Процессның вакытын белдерә. Шул ук вакыт мәгънәсен төшем килеше һәм билгесез килеш формасы аша иярүдән ясалган исемле фигыль сүзтезмәләр дә белдерә:

Әни белән икебезгә бер ыштан, ничек *чыгарбыз* икән бу *кыштан* (мәкаль). Бу *кышны* ничек *чыгу* хакында план корып утырды.

Урын-вакыт килеше кушымчасы.

1. Иярүче исем санна белән бергә килеп, ияртүче фигыльдән аңлашылган процессның вакытын белдерә: *1900 елны – 1900 елда*.

2. Процессның объектын белдерә: Ул *скрипкада уйный* (*скрипка уйный*).

3. Башкарылу урынын: *Күлдә* казлар *коена* (И.Гази). *Күл өстендә* үрдәкләр, казлар *йөзеп йөри*. (И.Гази).

Булу-булмауны белдерүче кушымчалар (-лы / -ле, -сыз / -сез) ярдәмендә ясалган сүзтезмәләр һәм аларның синонимнары

Бу кушымча белән ясалган фигыль сүзтезмәләргә синоним итеп, бәйлек сүзләр һәм чыгыш килеше кушымчасы ярдәмендә ияреп исемле фигыль сүзтезмәләр алына:

Синсез нишләрмен мин (*синнән башка нишләрмен* мин).

Дүртенче көн инде Мәликә апа тәмам *аяктан калды* (К.Нәҗми) – *аяксыз калды*.

Бәйлек (белән, өчен, саен, таба, чаклы, тикле, кадәр, хәтле, аша, бирле) һәм бәйлек сүзләр (буенча, өстенә, астында) ярдәмендә ясалган төзелгән сүзтезмәләр һәм аларның синонимлыгы

Белән бәйлеге ярдәмендә төзелгән исемле фигыль сүзтезмәләрдә иярүче ияртүче сүздән аңлашылган процессның *урынын, үтәлү вакытын, рәвешен, максатын* һ.б. белдерә:

Мөнирә Казанга *таң белән китте* (Г.Әпсәләмов) – *таңда китте, таннан китте*. Төште дә тизрәк арт *урам белән* өйләренә *йөгерде*. – *урам буйлап йөгерде*.

Өчен бәйлеге ярдәмендә ияргән сүз ияртүче сүздән аңлашылган процессның *максатын, сәбәбен* һәм процессны үтәргә тиеш булып та үтәмичә калган *затны* белдерә:

Гаиләң өчен кайгырма. Гаиләң дип кайгырма.

Инде *синең өчен* дә (*урыныңа* да) мин *калдым* (Г.Әпсәләмов).

Саен бәйлеге белән ясалган сүзтезмәләрдә түбәндәге мәгънә мөнәсәбәтләрен билгеләргә була: процессның вакыт ягыннан кабатлануын, урын нисбәтен:

Ул *көн саен* яңа нәрсә *уйлап чыгара* (*көн дә уйлап чыгара*).

Синтаксик синонимнарның функциональ төрләре: чагыштырулы төзелмәләр һәм аларның синонимлыгы

Чагыштыру дөньяны танып белүдә әһәмиятле алым булып санала. Бер әйбер яки күренешне икенчесе белән чагыштырып, без алар арасындагы охшаш якларны билгелибез.

Аралашу процессында халык чагыштырулардан иркен файдаланган. Телебездә күп кенә атамалар чагыштыру нигезендә барлыкка килгән. Халык авыз иҗатында да (мәкаль-әйтемнәр, табышмак, җырлар) чагыштырулар зур урын алып тора.

Чагыштырулы төзелмәләр берничә компоненттан (элементтан) оешалар:

1) чагыштырыла торган мәйбер (чагыштыру субъекты);

2) чагыштыру өчен алынган әйбер (чагыштыру объекты);

3) чагыштыруның нигезе;

4) бәйләүче чара.

Калганын Нәгыймә апа ишетеп өлгермәде, зур самовар, кузгалырга торган паровоздай, төрле якка пар бөркеп, ташый башлады. (К.Нәҗми)

Биредә чагыштырыла торган әйбер – *самовар*, чагыштыру объекты – *паровоз*, пар беркеп тору – чагыштыру нигезе, -*дай* кушымчасы – бәйләүче чара.

Чагыштырулы төзелмәләрне оештыруда аерым мөстәкыйль сүзләр дә, күпләгән ярдәмлекләр дә катнашалар. Мөстәкыйль сүзләр бәйләүче чара рәтенә кермиләр, бәлки аларны чагыштырулар төзүдә катнашучы лексик чаралар дип йөртәләр. Чагыштырулы төзелмәләрдә ике төрле бәйләнеш тә урын ала. Менә шуннан чыгып чагыштырулы төзелмәләрне түбәндәгечә төркемләргә мөмкин:

1. Ияртүле бәйләнеш җирлегендә ясалган төзелмәләр. Бу төр төзелмәләрне, ничек ясалуларына карап, тагын ике төркемгә бүләләр:

1) бәйләүче ярдәмлекләр белән ясалган төзелмәләр;

2) лексик чаралар ярдәмендә ясалган төзелмәләр.

2. Тезүле бәйләнеш җирлегендә ясалган төзелмәләр.

Ияртүле бәйләнеш җирлегендә ясалган төзелмәләр татар телендә гаять киң кулланыла. Мондый төзелмәләрдә чагыштыруның бер компоненты икенчесенә буйсынып, ияреп килә. Бер төр төзелмәләрдә бәйләүче чара иярүче

сүзнең составында була, ә икенче төрләрендә бәйләүче чара иярүче сүз составына керми, аннан читтә тора. Шундый аермалыклардан чыгып, чагыштырулы төзелмәләрне синтетик һәм аналитик төрләргә бүлеп карыйбыз.

Чагыштырулы төзелмәләрнең синтетик төрләре синтетик чаралар ярдәмендә ясалалар. Шулай ук лексик чаралар да, үзләре ияртүче сүз булып килгәнлектән һәм башка сүзләрне үз составындагы нинди дә булса берәр чара аша ияртә алганлыктан, синтетик төрләр эчендә каралалар.

Чагыштырулы төзелмәләрнең синтетик төрләре түбәндәге бәйләүче чаралар ярдәмендә ясала: *бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр, ярдәмче фигыльләр, килеш кушымчалары, чагыштыруны белдерүче аффикслар, ике сүзнең хәбәрлекле мөнәсәбәттә торып буйсынуы.*

Татар телендә бәйлекләр белән ясалган чагыштырулы төзелмәләр үзләренең күп кулланылуы белән аерылып торалар. *Шикелле, төсле, кебек, күк, сыман, чаклы, хәтле, кадәр* бәйлекләре чагыштырулы төзелмәләрдә еш кулланыла.

Агыйделдән ерак юлга чыкты

Аккош <u>кебек</u> ап-ак пароход. (М.Садри)

Төзелмәдә *кебек* бәйлеге урынына *төсле* бәйлегендә дә кулланырга мөмкин. *Сыман* бәйлеге, гадәттә, рәвеш функциясендә килгән сүзләрне бәйләү өчен кулланыла: *Тау бөркете <u>сыман</u> талпына*.

Чагыштыру объекты һәм чагыштырыла торган әйбер үзара хәбәрлекле мөнәсәбәттә торсалар, мондый чикләүлә булмый, *шикелле, кебек, төсле, сыман* бәйлекләренең һәркайсы кулланыла ала:

Синең караш җылы яңгыр <u>төсле</u>,

Синең караш кояш <u>шикелле</u>.

Синең караш минем йөрәгемә

Ак чәчәкле язлар китерде. (М.Җәлил)

Кадәр бәйлеге аша ясалган төзелмәләргә *чаклы, хәтле, тикле* бәйлекләре белән ямалган төзелмәләр синоним итеп алына: *Чәй тәлинкәсе <u>кадәр</u> кесә сәгатен күрсәтте.*

Караганда бәйлек сүзе белән ясалган төзелмәләрнең синонимы булып чыгыш килеше кушымчасы ярдәмендә ясалган төзелмә килергә мөмкин: *Бүген һава бүтән көннәргә караганда да күңелерәк.*

Булып бәйлек сүзе белән ясалган төзелмәнең синонимы рәвешендә *-дай / -дәй* кушымчалары һәм бәйлекләр ярдәмендә барлыкка килгән җөмләләр алына:

Кызның кара тутлы матур бите комач булып кызарды, башы иелде.

Чагыштырулы төзелмәләрне ясау өчен, татар телендә түбәндәге кушымчалар да кулланыла: *-дай / -дәй, -тай / -тәй, -ча / -чә, -дан / - дән, -тан / -тән, -рак / -рәк.*

Чагыштыру объекты һәм чагыштырыла торган әйбер хәбәрлекле мөнәсәбәттә торып төзелмәләр ясала: *плансыз эш – тозсыз аш.*

Аналитик төзелмәләрне оештыруда *мөнәсәбәтле сүзләр, ияртүче теркәгечләр һәм теркәгеч сүзләр, көттерү паузасы* катнаша. Аналитик төзелешле чагыштырулар парлы һәм ялгызак мөнәсбәтле сүзләр ярдәмендә ясалалар, синоним булып синтетик төзелешле төзелмәләр кулланыла:

Без шундыйлар: утта янмый,

Суга батмый чыгабыз. (М.Җәлил)

Шәриф ничек килеп керсә, шулай атылып чыгып та китте. Шәриф килеп кергәндәгечә атылып чыгып та китте.

Чагыштырулы төзелмәләр *гүя* теркәгече, *әйтерсең, диярсең* теркәгеч сүзләре белән дә ясала, аларга синоним булып бәйлекләр ярдәмендә ясалган төзелмәләр килә:

Кинәт ул җиңеләеп киткәндәй булды, әйтерсең аңа канатлар чыкты. (Г.Әпсәләмов). Кинәт ул канатлар чыккан кебек җиңеләеп киткәндәй булды.

Тезүле бәйләнештәге чагыштырулы төзелмәләрдә чагыштыру объекты белән чагыштырыла торган әйбер бер-берсенә янәшә алына, яки, аларны капма-каршы куеп, охшату ясала. Шуннан чыгып аларны ике төркемгә бүләләр:

1. Санау интонациясе нигезендә барлыкка килгән чагыштырулы төзелмәләр:

Ачның күзе икмәктә, тукның күзе хикмәттә. Ачның күзе икмәктә булса, тукның күзе хикмәттә.

2. Каршы кую юлы белән бәйләнешкә кергән чагыштырулы төзелмәләр:

Белгәнгә якты, белмәгәнгә караңгы.

Синтаксик синонимнарның функциональ төрләре: бер составлы җөмләләр һәм аларның синонимлыгы

Реаль чынбарлыктагы күренешләрне, табигать һәм кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне, уй-тойгыларны төрле-төрле төзелеш белән бирелгән җөмләләр аша тыңлаучыга, укучыга җиткереп була. Бер фикерне ике составлы җөмлә белән бирергә уңай булса да, икенчесен төшендергәндә, бер составлы җөмләне куллану отышлырак килеп чыга. Шуны истә тотып, бер составлы җөмләләрнең синонимлыгын өч юнәлештә тикшерәләр:

1. Бер составлы җөмлә белән ике составлы җөмлә синонимлыгы;
2. Бер составлы җөмләдәге бер төр белән икенче төр синонимлыгы;
3. Бер составлы җөмләләрнең бер үк төре эчендәге синонимнар.

Бер составлы җөмлә белән ике составлы җөмлә синонимлыгы

Сөйләмдә бер һәм ике составлы җөмләләр мәгънәдәш буларак кулланыла алалар. Ике җөмләдә дә эш башкаручы бер үк затка карый, икесенә дә бер үк мәгънә берлеге хас, ләкин бу җөмләләр төзелешләре ягыннан бер-берсеннән аерыла. Ике составлы җөмлә белән биреп булганны бер составлы җөмләнең кайсыдыр төре аша чагылдырырга мөмкин. Шулнигездә бер составлы җөмлә белән ике составлы җөмлә арасында синтаксик синонимлык туа. Мондый синонимлыкның өч төрен билгеләп була:

- билгеле үтәүчеле җөмлә белән ике составлы җөмлә синонимлыгы;
- билгесез үтәүчеле җөмлә белән ике составлы җөмлә синонимлыгы;
- гомуми үтәүчеле җөмлә белән ике составлы җөмлә синонимлыгы.

Билгеле үтәүчеле җөмлә белән ике составлы җөмлә синонимлыгы. Үтәүченең ничек бирелүенә карап, мондый җөмләләр берничә төрне үз эченә ала:

- Үтәүчесе иялек килешендә, баш кисәге сыйфат фигыль + ярдәмлек сүзләр белән белдерелгәндә, билгеле үтәүчеле җөмлә белән ике составлы җөмлә арасында синонимлык туа:

Әткәйне минем дә бик күрәсем килә, - *дигәнсез. (Э.Касыймов)* (*Әткәйне мин дә күрергә телим,* - *дигәнсез*) – ике составлы җөмлә.

Биредә ия юк, ләкин баш кисәктән аңлашылган процессның үтәүчесе иялек килешендәге тәмамлык (минем) белән белдерелә. Ике җөмлә дә беренче затка карый, мәгънә берлеге хас, алар төзелешләре белән аерылып торалар, димәк, әлеге җөмләләр – синоним.

- Үтәүчесе юнәлеш килешендәге тәмамлык, ә баш кисәге инфинитиф формасы + ярдәмлек сүзләр белән белдерелгән билгеле үтәчеле бер составлы җөмлә белән ике составлы җөмлә арасында синонимлык туа:

Безгә бик ашыгыч барырга кирәк иде (А.Гыйләҗев). (Без бик ашыгыч барырга тиеш идек) – ике составлы җөмлә.

Биредә үтәүче юнәлеш килешендәге тәмамлыктан җиңел аңлашыла. Процесс күплек санындагы беренче затка карый (без), икесендә дә *барырга тиешлек* мәгънәсе саклана.

- Билгеле үтәүчеле инфинитиф җөмләләрдә үтәүче бирелмәскә дә мөмкин, әмма очракта да үтәүченең кем булуы контекст, җөмләнең төзелеше белән билгеләнә ала. Мондый җөмләләр күп төрле мәгънә төсмерләренә ия булалар:

Әйтергәме соң фимилияне? (Г.Минский). Әйтимме соң фамилияне? – ике составлы җөмлә.

- Инфинитив янында *ярый* сүзе килсә, бер составлы җөмлә белә түбәндәге мәгънә төсмерләре бирелә: нәрсәне дә булса башкаруга рөхсәт итә, инкяр формасында тыюны белдерә:

Аларга рус әсире белән туктап сөйләшергә ярамый (Н.Дәүли). алар рус әсире белән туктап сөйләшергә тиеш түгелләр. – ике составлы җөмлә.

Ике составлы җөмләдә шушы ук мәгънә төсмерен бирү өчен инфинитив + тиеш, түгел сүзләре кулланыла.

- Инфинитив янында *иде* ярдәмче фигыле кулланылганда, теләк төсмере салына:

Миңа да шунда барырга иде. Мин дә шунда барыр идем.

Билгесез үтәүчеле җөмлә белән ике составлы җөмлә синонимлыгы

Билгесез үтәүчеле җөмләнең баш кисәге иңкүп очракта хәзерге заман хикәя фигыльнең күплек формасы белән белдерелә һәм өченче затта алына. Бу төр җөмләләрнең хәбәре функциясендә киләчәк заман хикәя фигыльләр дә килергә мөмкин:

Киеменә карап каршы алырлар, акылына карап озатырлар.

Билгесез үтәүчеле җөмләдә процессны башкаручы өченче затта итеп күзаллана, әмма аның конкрет кем булуына берничек тә игътибар ителми, шуңа күрә дә аңа синоним булган ике составлы җөмләләрдә күпвакыт билгесезлек алмашлыклары ия булып килә.

Гомуми үтәүчеле җөмлә белән ике составлы җөмлә синонимлыгы

Гомуми үтәүчеле җөмләләрнең баш кисәге икенче зат берлек сандагы хикәя фигыль белән белдерелгәндә, аңа зат алмашлыгы ия булып килгән ике составлы җөмлә синоним санала:

Эшләп үлмәссең, чирләп үләрсең.(Син эшләп үлмәссең, чирләп үләрсең)

Гомуми үтәүчеле җөмләнең баш кисәге шарт фигыль формасы һәм ярдәмче фигыльләр белән бирелгәндә, көчле теләк чагыла:

Их, шунда барсаң иде! (Их, мин дә шунда барсам иде!)

Гомуми үтәүчеле җөмләләрдә баш кисәк сыйфат фигыльнең хәзерге-киләчәк заман формасына *-ырлык* кушымчасы ялгау юлы белән белдерелә. Мондый җөмләләрнең синонимы итеп ия функциясендә исем фигыль килгән инкяр җөмләләр алына:

Тезеп бетерерлек түгел (М.Хәсәнов). Тезеп бетерү мөмкин түгел.

Бер составлы җөмләләрнең үзара синонимлыгы

Бер составлы җөмләләрнең бер төре мәгънә ягыннан якын булган икенче төренә синоним буларак кулланыла. Билгеле үтәүчеле җөмлә белән гомуми

үтәүчеле җөмлә арасында түбәндәге очракларда синтаксик синонимнар барлыкка килә:

- билгеле үтәүчеле җөмләнең баш кисәге *инфинитив* һәм *туры килә* сүзләре белән белдерелә, ә бу төргә синоним итеп, баш кисәге *хәл фигыль* һәм *бул* сүзе белән белдерелгән җөмлә алына:

Балага салкын тигән. Үзен генә кабул итмәячәкләр. Үзегезгә дә <u>ятарга туры килер</u>... (Үзегезгә дә ятмыйча булмас).

- баш кисәге *инфинитив + кирәк* белән белдерелгән җөмләнең синонимы итеп *хәл фигыль + ярамый* сүзе ярдәмендә бирелгән җөмлә алына:

Язарга кирәк, - дип күтәреп алды аның сүзен Әхәтов. Язмыйча ярамый, - дип күтәреп алды аның сүзен Әхәтов (Э.Касыймов).

- мөмкинлек мәгънәсен белдергән *инфинитив* җөмләгә *хәл фигыль* һәм *бул* ярдәмче фигыле белән килгән гомуми үтәүчеле җөмлә синоним була:

Йоклыйсың килми торгандыр, монда да яхшылап йокларга мөмкин. Йоклыйсың килми торгандыр, монда да яхшылап йоклап була (Ш.Усманов).

Билгесез үтәүчеле җөмлә белән гомуми үтәүчеле җөмлә үзара синоним була:

Ир танымый, әйтә салма (гомуми). Ир танымый, әйтә салмыйлар (билгесез).

Бер составлы җөмләләрнең бер үк төре эчендәге синонимнар

Бер составлы җөмләләрнең аерым төрләре берничә чара ярдәмендә формалаша һәм мәгънә ягыннан якын булган бу җөмләләр үзара синоним итеп карала. Гомуми үтәүчеле җөмләнең аерым төрләре синоним була:

- баш кисәге *икенче зат берлек сандагы хикәя фигыль* белән белдерелгән җөмлә һәм *хәбәре хәл фигыль + ярдәмлек сүзләр* булган җөмлә синоним була:

Ике көймә койрыгын тота алмассың. Ике көймә койрыгын тотып булмый.

Тауга карап, тау була алмассың. Тауга карап, тау булып булмый.

- *икенче зат берлек сандагы хикәя фигыль* баш кисәк булып килгән җөмлә белән хәбәре *–ырлык кушымчалы* сүз һәм ярдәмлекләр аша бирелгән гомуми үтәүчеле җөмлә синоним була:

Һәр көн димәсәм дә, бик еш буран. Урамга да чыга алмыйсың (С.Кудаш). Урамга да чыгарлык түгел.

- *Хәл фигыль* формасы *бул* ярдәмлеге белән белдерелгән җөмләгә хәбәре *-ырлык кушымчалы* сүз һәм ярдәмлекләр аша бирелгән җөмлә синоним була:

Бөтенләй караңгы йорт эчендә берни дә аерырлык түгел (Г.Ибраһимов). Бөтенләй караңгы йорт эчендә берни дә аерып булмый.

Синтаксик синонимнарның функциональ төрләре: актив һәм пассив төзелмәләрнең синонимлыгы

Гомуми тел белемендә процесс иягә юнәлтелгән җөмләне пассив конструкция дип билгелиләр. Бу төзелмәгә нисбәттә иясе процессны башкаручы рәвешендә бирелгән конструкцияләрне алалар һәм актив конструкция дип йөртәләр. Шулай итеп актив һәм пассив төзелмәләрне бер-берсенә бәйле рәвештә карау килеп чыга (Ибраһимов С.М. Татар телендә синтаксик синонимнар / С.М.Ибраһимов. – Казан: КДУ нәшр., 1976. – 38 б.).

Пассив төзелмәләрне икенче төрле оештыручы үзәге төшем юнәлешендәге фигыль белән белдерелгән төзелмәләр дип тә атыйлар.

Пассив конструкция фигыль юнәлешләре белән бәйле. Юнәлешләр – фигыльнең иң катлулы һәм иң бәхәсле лексик-грамматик категорияләренең берсе. Татар теле белемендә “юнәлеш” төшенчәсенең эчтәлеге һәм күләме бертөрле билгеләнми. Галимнәрнең иң зур күпчелеге юнәлешләрне грамматик категория итеп карый, әмма бу категориянең асылы турында төрле карашлар яшәп килә.

Татар телендә биш юнәлеш бар: *төп, төшем, кайтым, уртаклык, йөкләтү юнәлешләре*.

Юнәлеш кушымчалары затка яки предметка каратылган процессларны белдерә торган фигыльләргә генә ялганалар. Мондый мөнәсәбәтне белдермәгән,

нигездә, табигать күренешләрен белдерә торган фигыльләр бары тик төп юнәлеш формасында гына кулланылалар: *давыллый, буранлый, яңгырлый һ.б.*

Барлык юнәлеш формалары да булган фигыльләрнең саны йөздән артмый: *актару, бизәү, йөрү, йөгерү, казу, карау һ.б.*

Пассив конструкцияләрне барлыкка китерүдә катнашкан төшем юнәлешенең мәгънәсен тел белгечләре төрлечә аңлаталар.

В.Н.Хангилдин фикеренчә, бу юнәлеш грамматик субъект-иянең пассивлыгын, эш башкаручының билгесез булуын күрсәтә.

М.З.Зәкиев эш башкаручының пассивлыгы турында сүз алып бара.

Д.Г.Тумашева көчемле фигыльләрдән ясалган процессны логик объект ясалган итеп бирәләр, ә көчемсез фигыльләрдән ясалган эшнең үтәүчесез башкарылганын белдерәләр дип исәпли.

Төшем юнәлеше формаларының башка кайбер мәгънәләре дә искә алына, ләкин аларны төрлечә аңлаталар: я аларны *-л-* кушымчасының сүз ясагыч функциясе нәтиҗәсе итеп карыйлар, я кайтым юнәлешенә кертәләр, яисә, гомумән, игътибарга алмыйлар, төшереп калдыралар.

Фигыльнең төшем юнәлеш формасы татар телендә -л- (-ел-, -ыл-) кушымчасы ярдәмендә ясала. Тартыкка тәмамланган һәм сузыкка тәмамланган бер иҗекле нигезләрдән соң бу кушымчаның –ыл-, -ел- вариантлары килә: *тапшыр-ыл-у, җибәр-ел-ү, у-ыл-у, бу-ыл-у, и-ел-ү һ.б.* Калган очракларда, ягъни берничә иҗекле, сузыкка тәмамланган нигезләрдә -л- кушымчасы күзәтелә: *аша-л-у, күрә-л-ү һ.б.ш.*

Димәк, татар телендә фигыльләрнең төшем юнәлеше формасы пассив төзелмәләрне барлыкка китерә. Бу мәсьәлә төрле телләрдә өйрәнелгән. С.М.Ибраһимов билгеләп үтүенчә, Европа телләрендә бер үк мәгънә мөнәсәбәтенә ия булган актив һәм пассив конструкцияне берсеннән икенчесенә күчерү алымы телнең үзенчәлекләрен практик өйрәнү дәресләрендә еш кулланыла.

Төрки телләрдә актив һәм пассив төзелмәләрнең кулланылышы, аларның синонимлыгы хакында махсус хезмәт булмаса да, бу мәсьәләнең күп кенә

яклары төрки грамматикаларда һәм юнәлеш категориясенә кагылышлы аерым тикшеренүләрдә яктыртыла.

Төрки телләрдә актив һәм пассив төрләрнең үзара синоним булып килүе хакында без Ф.Убаеваның “Хәл категориясе” исемле хезмәтеннән күрәбез. Ул бу хакта менә боларны белдереп китә: “Хәбәре төп юнәлештәге фигыль белән белдерелгән гади җөмлә һәм хәбәр төшем юнәлешендәге фигыль белән белдерелгән гади җөмлә синтаксик синонимлык хасил итә. Хәбәре төп юнәлештәге фигыль белән белдерелгән җөмләләрдә ия объектны, тәмамлык субъектны күрсәтә”.

Татар телендә актив һәм пассив төзелмәләр турында иң төп хезмәт буларак С.М.Ибраһимовның “Татар телендә синтаксик синонимнар” монографиясе карала. Галим биредә, башка төр синтаксик синонимнар белән беррәттән, пассив төзелмәләрне дә тикшерә һәм аларның актив төзелмәләр белән синонимлыгын ачыклый, төрләрен аерып чыгара.

С.М.Ибраһимов фикеренчә, актив төрләрдә ия үтәүче функциясендә кулланыла һәм процессны белдерә торган оештыручы үзәк (җөмләнең нинди дә булса берәр кисәгенә ияреп килгән фигыль яки иянең хәбәре) төп, кайтым, уртаклык һәм йөкләтү юнәлешендә алына. Мәсәлән: *Чынлап та, Искәндәр онык әбисе куаныч арты куаныч кына **өсти**: умартачылык һөнәренә укып, урмандагы хуҗалыкта көн күрә башлый (Н.Гыйматдинова); Бу кыска-кыска авазлар Сибгатуллаларга да ап-ачык **ишетелде** (Н.Гыйматдинова); Мизхәт Зөбәрҗәт белән кибет ишегендә йөзгә-йөз **очрашты** (Ф.Садриев); Моны бик тиз **ишеттерделәр** (Ф.Садриев).*

Пассив төзелмәләрдә исә ия үтәүче булып килми. Процесс шушы иягә төшә, ия төшем юнәлешендәге фигыль белән белдерелгән процессның объекты булып аңлашыла. Мәсәлән:

Күзләрем – кан,
*Телем **телгәләнгән**,*
*Күкрәгемә йолдыз **уелган.** (И.Юзеев)*

Татар телендә, С.М.Ибраһимов билгеләгәнчә, пассив төзелмәләрдә процессны башкаручы төрле-төрле чара белән бирелә. Шул чарага бәйле рәвештә, пассив төзелмәләрнең алты төре аерып чыгарыла.

1. *Тарафыннан* бәйлек сүзе белән төзелгән конструкцияләр

Беренче төрдә билгесез килештәге исем яки иялек килешендәге алмашлык янында *тарафыннан* бәйлек сүзе килә. III зат күплектәге алмашлык (*алар*) иялек килеше кушымчасы алмый.

Мәсәлән: *Соңгы берничә көндә тимер юл сызыгының бу күренгән өлеше ак **казак отрядлары тарафыннан кисеп алынгач**, юл бөтенләй җансызланып калды (Ш.Усманов).*

*Инде Гайфуллага **балдызы тарафыннан** өстенә **яудырылган утлы сүзләрне** учына җыярга гына калды. (Бүләк)*

2. *Белән* бәйлеге ярдәмендә төзелгән конструкцияләр

Пассив конструкцияләрнең икенче төре процессны башкаручының төшем юнәлешендәге фигыльгә *белән* бәйлеге ярдәмендә иярүенә нигезләнеп барлыкка килә:

*Ана белән улының үбешкән чакларында, авыздан-авызга бирелгән бу кечкенә кәгазь кисәгендә бик вак, шулай да бик ачык итеп, Булат **кулы белән** шул ук **сүзләр тезелгәннәр** иде (Г.Ибраһимов)*

*Моңа, гомумән, **пычак белән кагылырга** ярамый, - дигәннәр. (Ф.Яруллин. Урман кызы)*

Әгәр дә без бу конструкцияне актив конструкция итеп үзгәртсәк, ул түбәндәгечә яңгырар иде: *Пычак кагыла (кайтым юнәлеше)*. Димәк, чыннан да, биредә *белән* бәйлеге процессны башкаручыны төшем килешендәге фигыльгә бәйләүче чара булып тора.

*Һәм бу ис күңелендәге **вакыт тузаны белән капланган** күптәнге хатирәләрне уятып җибәрде (Читлек кошы).* Актив конструкция итеп караганда, ул *Вакыт тузаны каплаган* формасында әйтелер иде.

*Шофер егет Миләүшәнең **яулык белән бәйләнгән** кулын чиште. (Мәхәббәт упкыны).* Актив конструкциядә бу җөмлә *Яулык бәйләгән кул* формасында әйтелер иде.

3. *Өчен* бәйлеге ярдәмендә бәйләнгән төзелмәләр

Пассив төзелмәләрнең өченче төре процессны башкаручының төшем юнәлешендәге фигыльгә *өчен* бәйлеге ярдәмендә иярүе белән характерлана. *Мондый **кыз өчен** мин көн саен **кыйналырга** әзер. (Ф.Яруллин. Мәхәббәт упкыны)*

***Синең өчен әзерләнгән** табын бу. (Ф.Яруллин. Мәхәббәт упкыны)*

4. *Чыгыш килеше кушымчасы* ярдәмендә бәйләнгән төзелмәләр

Пассив төзелмәләрнең дүртенче төрендә үтәүчене белдерә торган сүз фигыльгә чыгыш килеш кушымчасы ярдәмендә иярә.

Гомерем шигырьдән шигырьгә

***Сузылган юлдан** тора.(Ф.Ярулллин “Язам-сызам, язам-сызам”)*

Әлеге мисалдан күренгәнчә, *сузылган юлдан* пассив конструкциясен актив конструкция итеп үзгәртсәк, ул *юл сузу* рәвешендә яңгырар иде.

С.М.Ибраһимов билгеләвенчә, чыгыш килеше кушымчасы ярдәмендә оешкан пассив төзелмәләрдә, беренчедән, сәбәп мөнәсәбәте булырга мөмкин. Бу вакытта пассив конструкциягә *аркасында* бәйлек сүзле актив төзелмә синоним булып килә: *Юк кына нәрсәләр аркасында тәэсирләнәм*. Икенче очракта исә чыгыш килеше кушымчасы белән бирелгән сүз бер башкаручыны, ә төшем юнәлешендәге фигыль йөкләтү юнәлеше кушымчасы белән берлектә икенче башкаручыны белдерә.

5. Юнәлеш килеше кушымчасы белән бәйләнгән төзелмәләр

Пассив төзелмәләрнең бишенче төрендә процессны башкаручы төшем юнәлешендәге фигыльгә юнәлеш килеше кушымчасы белән иярә.

Шатлыкка** шундый нык **сусалган,

*Үткәннәр **рәшәгә уралган**. (Ф.Яруллин “Сафлыкка шундый нык сусалган”).* Бу мисалдагы пассив конструкцияләрне актив конструкция итеп

үзгәртсәк, ул түбәндәгечә яңгырар иде: *шатлык сусату, рәшә урау.* Мондый формалар татар теле өчен ят, шигърият өчен бигрәк тә.

*Әйтик, сез караватм кадәр зур өстәл артында **кәгазьләргә күмелеп** эшләп утырасыз, ди. (Ф.Яруллин. Читлек кошы)*

6. Үтәүче аерым сүз белән бирелмәгән конструкцияләр

Пассив төзелмәләрнең татар телендә иң еш очраган төре – үтәүче аерым сүз белән бирелмәгән очрак. Үз эчендә ул тагын, үтәүченең нинди сүздән аңлашылуына карап, берничә төргә бүленә.

1. Беренче очракта үтәүче алдагы җөмләләрдән, контексттан яки әйләнә-тирә обстановкадан билгеле була. Әгәр мондый очракта үтәүче яңадан кабатланса, бу – тавтологиягә китерер иде:

***Сыгылган** чаклар була,*

***Егылган** чаклар була,*

Үзеңнән сыекларга да

***Сыенган** чаклар була. ("Сыгылган чаклар була...")*

Бу мисалда *сыгылгын, егылган, сыенган* сүзләре теләкнең лирик геройга, сөйләүчегә каравын белдерә һәм шагыйрь тарафыннан лирик герой кичерешләренең авырыгын җиткерелә. Автор, әлеге формаларны кулланып, тормышта кыенлыклар, сынаулар, борчулар күплеген ассызыклый һәм аларның котылгысыз булуын искәртә. Пассив конструкцияне куллануның төп максаты – шул.

2. Икенче очракта процессны үтәүче аерым сүз белән бирелә алмый, шуңа күрә мондый җөмләләрне үтәүчесез бер составлы җөмләләр дип атап йөртәләр: *Шәһәргә бик озак барылды һәм бик арылды*.

К.З.Зиннәтуллина исә үзенең хезмәтендә мондый пассив төзелмәләрдә эшнең үзеннән-үзе башкарылуын билгеләп үткәннән соң, аларны актив төрләр белән чагыштырып, бу җөмләләрне билгеле үтәүчеле бер составлы җөмлә итеп карарга тәкъдим итә.

Соңгы елларда чыккан хезмәтләрдә исә билгесез үтәүчеле һәм үтәүчесез бер составлы җөмләләр аерып күрсәтелә.

2. Күчемсез фигыльнең төшем юнәлешендәге төре үтәүченең тәмамлык рәвешендә килүен таләп итми. Мондый конструкцияләр актив төзелмәләргә якыная.

Яшен сукты очып барган кошны,

***Кош гәүдәсе** меңгә **теленде.** (Матур күренеш)*

Бу мисаллардан күренгәнчә, төшем юнәлешендәге фигыльләрнең үтәүчесе тәмамлык булып килми, ия функциясен үти, шунлыктан, аларның актив конструкция белән охшашлыгы күзгә ташлана.

Җөмләнең эчтәлегенә бәйле рәвештә, күчемле фигыльдән ясалган хәбәр янында да үтәүченең килүе мәҗбүри булмый: *Алдан кычкырган күкенең башы ярыла.*

Сораулар һәм биремнәр.

1. Синтаксик синонимнар мәсьәләләрен өйрәнү тарихы.

2. Синтаксик синонимнарга билгеләмә бирү мәсьәләсе һәм аларның төрләре, принциплары.

3. Синтаксик синонимнарны өйрәнү һәм билгеләү (В.В.Виноградов, А.Н.Гвоздев, А.И.Ефимов, Г.Я.Солганик, В.Н.Хангилдин, Х.Р.Курбатов, В.Х.Хаков, М.З.Зәкиев, Ш.Ханбикова, С.М.Ибраһимов һ.б.).

4. Синтаксик синонимнар һәм аларның төрләре.

5. Синтаксик синонимнар һәм синтаксик тәңгәлләр.

6. Синтаксик синонимнар һәм синтаксик вариантлар.

7. Беренче дәрәҗә синонимнарны билгеләү мәсьәләсе, аларның төп үзенчәлекләре һәм төрләре.

8. Икенче дәрәҗә синонимнарны билгеләү мәсьәләсе, аларның төп үзенчәлекләре һәм төрләре.

9. Сүзләрнең мәгънә ягыннан сыешуы (лексик, лексик-грамматик, морфологик һәм синтаксик төрләре).

10. Сүзтезмәләрдәге бәйләүче чаралар (кушымчаларны куллану, бәйлекләрне һәм бәйлек сүзләрне куллану).

11. Сүзтезмәләрнең синонимлыгы, билгеләмә бирү мәсьәләсе.

12. Фигыль сүзтезмәләрнең синонимлыгы.

13. Исемле фигыль һәм аларның синонимнары.

14. Чагыштырулы төзелмәләр һәм аларның элементлары.

15. Чагыштырулы төзелмәләрне оештыруда катнашучы чаралар.

16. Ияртүле бәйләнеш җирлегендә ясалган төзелмәләр.

17. Тезүле бәйләнеш җирлегендә ясалган төзелмәләр.

18. Чагыштырулы төзелмәләрнең синтетик һәм аналитик төрләре. Аналитик һәм синтетик төрләрнең үзара синонимлыгы.

19. Тезүле бәйләнештәге чагыштырулы төзелмәләрнең ияртүле бәйләнештәге төзелмәләр белән тәңгәллеге.

20. Бер составлы җөмләләрнең төрләре, аларны билгеләү үзенчәлекләре.

21. Бер составлы җөмлә белән ике составлы җөмлә синонимлыгы.

22. Бер составлы җөмләнең бер төре белән икенче төре арасындагы синонимлык.

23. Бер составлы җөмләнең бер үк төре эчендәге синонимлык.

24. Татар телендә актив һәм пассив төзелмәләрнең әһәмияте.

25. Актив һәм пассив төзелмәләрне әйрәнүнең тарихы (И.Хәлфин, М.Иванов, К.Насыйри, Г.Нугайбәк, Җ.Вәлиди, Л.Җәләй, В.Хангилдин, Д.Тумашева, М.Зәкиев, С.М.Ибраһимов һ.б.).

26. Актив (актив төрләрдә ия ике составлы җөмләләрнең үтәүчесе булып килә һәм процессны белдерүче хәбәр төп, кайтым, йөкләтү һәм уртаклык юнәлешләрендә алына) һәм пассив (хәбәре төшем юнәлешендәге фигыль белән белдерелә) төзелмәләрнең үзара синоним булып килүе.

Әдәбият исемлеге.

1. Ибраһимов С.М. Татар телендә синтаксик синонимнар / С.М.Ибраһимов. – Казан: КДУ нәшр., 1976. – 168 б.

2. Ибраһимов С.М. Синтаксик стилистика / С.М.Ибраһимов. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1989. – 150 б.

3. Ибраһимов С.М. Сандугач теле кирәк: Синтаксик ситилистика: Уку-укыту ярдәмлеге / С.М.Ибраһимов. – Казан: Мәгариф, 2008. – 159 б.

4. Солганик Г.Я. Синтаксическая стилистика: Сложное целое / Г.Я.Слоганик. – М.: Высш. школа, 2003. – 214 с.

5. Татар грамматикасы. – Т.II. Морфология. – М.: Инсан, Казан: Фикер, 2002. – 448 б.

6. Татар грамматикасы. – Т.III. Синтаксис. – М.: Инсан, Казан: Фикер, 1999. – 512 б.

7. Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе: Югары уку йортлары өчен дәреслек / Ф.М.Хисамова. – Казан: Мәгариф, 2006. – 335 б.

Тема 8. Стилистик фигурлар: стиль әйләнмәләре. Синтаксик омонимнар һәм аларның төрләре

Лекция 8

Аннотация. Лекциядә татар әдәби телендә стиль әйләнмәләре турында фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Стиль әйләнмәләренең төзелеш үзенчәлекләре һәм башка төр күренешләр еблән мөнәсәбәте ачыклана. Шулай ук лекциядә синтаксик омонимнар һәм аларның төрләре өйрәнелә. Синтаксик омонимнарда котылу юллары күрсәтелә.

Ачкыч сүзләр: стиль әйләнмәләре, синтаксик омонимнар, уңай омонимнар, стиль ононимнар.

Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр. Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә эзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

Лекциянең планы:

1. Татар телендә стиль әйләнмәләре һәм аларның төзелеше.
2. Стиль әйләнмәләре һәм аларның башка төр күренешләр белән мөнәсәбәте.
3. Синтаксик омонимнарга билгеләмә бирү мәсьәләсе.
4. Синтаксик омонимнарның төрләре: уңай һәм стиль омонимнары.

Татар телендә стиль әйләнмәләре

Стильдә сүз тәртибе белән бәйле бер күренеш бар. Телне тикшерүчеләр, әдәби стиль үзенчәлекләрен өйрәнүчеләр, әдәбият теориясе белән шөгыльләнүчеләр аңа төрлечә аңлатма биреп киләләр. Бу күренешнең нигезендә сүзләрнең, шул ук сүзләрдән торган әйләнмәләрнең урынын алмаштыру ята, әмма бу алмаштыру – сүзнең урынын гади генә күчереп кую түгел. Мәсәлән:

Әрнеттең дә ничә кабат,

Юаттың үзең озак.

Газаптан торган шатлык син,

Шатлыктан торган азап. (Р.Миңнуллин)

Биредә сүзләрнең урынын алмаштыру әйтергә теләгән образлы яңа фикерне бирү өчен эшләнгән. Форма ягыннан караганда да, грамматик бәйләнеш чарасы булган чыгыш килеше кушымчасы мондый төзелмәне оештыруда катнаша. Төрле бәйләүче чараларны кулланып ясалган урын алмаштырулар нинди дә булса бер тирән фикер әйтүне күздә тота:

Якутлар табылыр вакыт белән,

Вакытлар табылмас якут белән (мәкаль).

Бүген бәхет минем кулда,

Бүген бәхет кулында мин (Р.Миңнулин).

Сөйләмдә стильнең әлеге алымы күптәннән кулланылып йөрсә дә, аңа төгәл исем табылганы юк. И.Бәширова “Сүз белән сурәт ясау” хезмәтендә, шагыйрьләрдән мисаллар китереп, *шигырь эчтәлегендә чагыштырыла торган сүзләрнең урынын алмаштырып кабатлау* дип бәяли. (137 бит).

Х.Курбатов аларны фразеологизмнарның *“төзүче кисәкләрен логик-грамматик яктан бер-берсе белән алыштыру”* нигезендә ясалган бер төре итеп карый. Ф.Сафиуллина мондый синтаксик һәм стилистик күренешкә *синтаксик параллелизм* буларак бәяләмә бирә.

Шул рәвешле, бу төр төзелмәләрнең үзенчәлегенә әледән-әле игътибар итеп киленә, шуңа да карамастан аны, аерым бер стиль алымы итеп тикшерү,

билгеле бер исем астында өйрәнү булмый. Соңгы елларда аны стиль әйләнмәләре дип атау киң җәелде. Бу күренешне стиль әйләнмәләре дип карарга нигез бар: алар билгеле бер стиль максатыннан чыгып төзелә һәм стиль чарасы булып китә, сөйләмгә образлылык өсти, үткенлек бирә, әйтергә теләгән фикерне җыйнак төзелмә белән җиткерү теләге туа.

Стиль әйләнмәләренең төзелеше. Стиль әйләнмәләрен тикшергәндә, бер-бере белән тыгыз бәйлнештә торган ике якка игътибар итәргә кирәк: 1) аларның стильдәге башка төр күренешләр белән бәйләнеше; 2) аларны оештыруда катнаша торган чаралар.

Стиль әйләнмәләренең башка төр күренешләр белән бәйләнеше.

Стиль әйләнмәләре иң беренче чиратта грамматик һәм стилистик чара булган сүз тәртибе белән тыгыз бәйләнештә карала. Стиль әйләнмәләренең нигезен нәкъ менә шул тәшкил итә. Җөмлә кисәгенең кайсысы үз урынын алмаштыруына карап, стиль әйләнмәләрендә берничә төр-модельне билгеләргә була:

1. ия функциясендәге сүз үз урынын алыштыра: *Җаның тынса, кулың тынмый, кулың тынса, җаның тынмый (мәкаль).*

2. җөмләнең хәбәре үз урынын алыштыра: *Былбыл да син, син дә былбыл икәнсең (Ә.Еники).*

3. тәмамлык үз урынын алыштыра:

Атлар атламас инде,

Син миңа, мин сиңа

Ятлар мактамас инде. (Җыр)

4. аергыч үз урынын алыштыра:

Гамлет ролен Мутин уйнаса да,

Мутин ролен Гамлет уйнамас (Х.Туфан).

5. Хәл кисәк үз урынын алыштыра (рәвеш хәле, күләм хәле, кире хәл, сәбәп хәле, максат хәле): *Ашар өчен яшәмә, яшәр өчен аша (мәкаль)*

Татар телендә синтаксик омонимнар

Соңгы елларда рус тел белемендә, шулай ук төрки телләрдә дә синтаксик омонимнарны өйрәнүгә багышланган хезмәтләр күренә башлады.

Аваз төзелешләре белән бердәй булып, берничә мәгънә аңлата торган сүзләрне лексик омонимнар дип йөрткән кебек, синтаксик төзелешләре белән бердәй булып, берничә мәгънә аңлата торган сүзтезмә, әйләнмә һәм җөмләләрне синтаксик омоним дип билгелиләр (Ибраһимов “Синтаксик стилистика, Б. 103.). Мәсәлән:

Фәттах мулла килеп китте (Ф.Хөсни). Ике мәгънәдә аңлашыла: 1) Фәттах исемле кеше мулла булып киткән. 2) Фәттах исемле мулла бу тирәгә килеп киткән. Бер үк төзелештәге җөмлә ике мәгънәгә ия булганлыктан, монда синтаксик омонимлык күренеше бар дип саныйбыз.

Кайвакыт бер үк җөмлә икедән артык мәгънәне дә аңлатыга мөмкин:

Капитан Гатин өстәле белән янәшә торган кәнәфигә утырды (А.Расих). 1) Ниндидер бер капитан икенче Гатин исемле кешенең өстәле белән янәшә торган кәнәфигә утырган. - әсәрдә җөмлә шул мәгънәдә. 2) Капитан Гатин үзенең өстәле белән янәшә торган кәнәфигә утырган. 3) Берәү капитан Гатин өстәле белән янәшә торган кәнәфигә утырган.

Омонимлык күренеше сөйләм телендә, шулай ук әдәби жанрларның барысында да шактый еш очрый. Сөйләмдә кулланылышына карап, синтаксик омонимнарны ике төркемгә бүләләр: *уңай омонимнар* һәм *стиль (кире) омонимнар*.

Уңай омонимнар телдә еш очрый, аларны уңай яктан бәяләргә кирәк, чөнки алар, бер очракта, сөйләмне бизәү өчен киная белән кулланылалар, билгеле бер күләмдә үз үлчәме белән сөйләмгә кертеләләр икән алар стильне матурлыйлар. Икенче яктан, туры мәгънәдә алынганда да, фикерне аңлауга комачаулык итмиләр. Мәсәлән:

Ул алардан аерылу өчен агымга каршы йөзеп карады (М.Әмир)

Кода, син агымга каршы йөзәсең түгелме?

Һәр икесен тәңгәл куйганда, алар синтаксик омоним тәшкил итәләр, чөнки төзелешләре белән бердәй җөмләләр ике мәгънәдә кулланылган.

Уңай омонимнарны, сөйләмдә кулланылышларына карап, өчкә бүлеп карарга мөмкин: 1) әдәби әсәрнең нигезендә яткан, 2) халык авыз иҗатында кулланылып килә торган, 3) гадәти һәм фразеологик әйләнмәгә нигезләнгән омонимнар.

Әдәби әсәрнең нигезендә яткан омонимнар. Язучы, синтаксик омонимнарның төп үзенчәлегенә - бер үк төзелешнең ике яки берничә мәгънәгә ия булуына таянып, әдәби әсәрләр иҗат итә. Мондый әсәрләр күләмле булмыйлар. Мәсәлән, Ш.Галиевның “Кеше хәлен кеше белми”, “Авызга су кабып”, Н.Арслановның “Каш”, “Сакал” шигырьләре.

Халык авыз иҗатында кулланылып килә торган омонимнар. Төрле жанрларда бер үк җөмләнең, сүзтезмәнең ике мәгънә аңлатуы укучыны җәлеп итү өчен кулланыла. Мәзәкләрдә синтаксик омоним аның нигезен тәшкил итә.

Гадәти һәм фразеологик әйләнмәгә нигезләнгән омонимнар. Мондый омонимнар ике төрле юл белән барлыкка киләләр: 1) Гадәти сүзтезмә, җөмлә еш кына кулланылып, фразелогик әйләнмәгә әверелеп китә һәм алар аерым очракларда ике функциядә дә йөриләр. Мәсәлән: *Шуннан, бу ни соң дип, җынлабрак карасам, ул тирән бер чокыр икән. Ул үзе белән егет арасында никадәр тирән чокыр ятканлыгын, егетнең бер ягы беән дә үзенә лаек булмаганлыгын ничек күрмәде икән?* (Ә.Еники).

2) Автор омонимнарны бер-бер артлы куллана. Шул ике әйләнмә капма-каршы куелганлыктан яңа образ-сурәт барлыкка килә.

Стиль омонимнар. Бу төр омонимнар стильне матурламыйлар, бәлки фикерне төгәл, ачык һәм дөрес итеп әйтеп бирергә комачаулыйлар, берничә төрле хөкем йөртергә урын кала, шуңа күрә аларны кире омонимнар да дип тә атап йөртәләр. Кире омонимнарның түбәндәге төрләре телдә еш кабатлана:

Җөмләдә сүз тәртибе белән бәйле синтаксик омонимнар. Җөмләдә нинди дә булса бер сүз ияртүче сүздән читләштерелгән була һәм автор әйтергә теләгән мәгънәгә караган икенче бер мәгънәне аңларлык урын кала: *Заһри сиздермичә генә исерә башлаган Фазылҗанны күзәтте* (Ф.Хөсни).

Мондый аңлашылмауларны бетерүнең берничә төрле юлы бар. 1) Сүз тәртибен үзгәртеп, иярүче сүзне ияртүче сүз янына кую. 2) иялек килеше кушымчасы өстшү юлы белән: *Бөтендөнья агрономнар киңәшмәсендә катнашучыларга. Агрономнарның бөтендөнья кинәшмәсендә катнашучыларга.*

3) Бәйлек һәм бәйлек сүзне теркәгечләр белән алмаштыру: *Саттаров белән милициядән килгән ике офицер гына бирешми* (М,Насыйбуллин). *Саттаров һәм милициядән килгән ике офицер гына бирешми.*

4) Җөмлә кисәген аерымлау юлы белән: *Ашыкмыйча гына дежур торучы өстәлендәге телефон янына килдем* (М.Юныс). *Дежур торучының өстәлендәге телефон янына ашыкмыйча гына килдем.*

5) Берничә төр чараны берьюлы куллану.

Хәл фигыльнең урыны белән бәйле синтаксик синонимнар. Хәл фигыль белән төп фигыль, җөмләдә янәшә килеп, күпвакыт кушма бер кисәк (хәл кисәк), бигрәк тә кушма фигыль хәбәр барлыкка китергәнлектән, башка функцияне истә тотып кулланылган сүз синтаксик омоним хасил итә. *Карт җан-фәрманга **өреп сөйләшергә** комачаулаган этне куып җибәрде.* (М.Хәсәнов).

Белгечлек белән бәйле синтаксик омонимнар. Белгечлекне аңлаткан сүз башка функциядә килсә, үзеннән соңгы сүз белән бергә синтаксик омоним хасил итә: белгечлекне белдергән сүз бу шәхескә карый икән дип фикер йөртергә урын кала. *Агроном Иван Ивановичны ишетеп кенә белә иде.* (А.Расих). Бу очракта сүз тәртибен үзгәртү юлы белән стиль ялгышыннан котылып була.

Туганлык терминнары белән эш иткәндә дә, шушы ук закончалыкны истә тотарга кирәк, чөнки сөйләмдә бу сүзләр, ялгызлык исеме белән бергә килеп, бер шәхесне белдерәләр. Моннан читкә тайпылу стиль чатаклыгына китерә: *Казанга кайткач, Вәли картның киңәшен тотмады.* (Г.Әпсәләмов).

Исем һәм фамилия белән бәйле синтаксик омонимнар. Бер исем белән икенче кешенең фамилиясен янәшә кую синтаксик омоним барлыкка китерә: *Григорий Федоров "эшеннән" тәмам туйган иде* (А.Расих).

Тартымлы сүз белән бәйле синтаксик омонимнар. Бу очракта, тартымлы сүз алдагы сүз белән бәйләнештә каралып, синтаксик омоним ясала: *Көн кичкә авыша башлаганда, Вәли абзый кодасы Җәгъфәр белән кайтып керде* (Ә.Фәйзи).

Күрсәтү алмашлыклары белән бәйле синтаксик омонимнар. Алмашлык белән белдерелгән кисәк мондый җөмләләрдә берничә функцияне үтәү мөмкинлеген ала: *Алиш бу көннең бер килеп җитәсен ачык белгәнгә күрә, ул хатны күптән үк язып куйган иде инде* (Ш.Маннур).

Үтәүче һәм объектка бәйле синтаксик омонимнар. Бер үк формада (мәсәлән, юнәлеш килеше кушымчасы белән) килгән сүзне бер составлы җөмләнең билгеле үтәүчесе дип тә һәм аның объекты дип тә аңларга мөмкинлек туа: *Габдулла кәгазьдәге "техник һәм материаль нигез" дигән сүзгә әһәмият бирмәде, шуңа күрә Кәбир әфәндегә аны да аңлатып бирергә һәм Чердынцев белән булган әңгәмәне төшендерергә туры килде* (Ә.Фәйзи).

Чикләүче сүзләр белән бәйле синтаксик омонимнар. Бу очракта, исем яки алмашлыклар белән рәттән чикләүче кисәкчәләр, кайбер саннар килеп, берничә мәгънә аңлашыла: *Бер карлыгач кына яз китерми.*

Раслау һәм инкяр мәгънәләре белән бәйле синтаксик омонимнар. Язуда бер төсле булып та, төрле интонация белән укуга карап, бер җөмләдән берничә мәгънә аңлап була: *Куандырды улы телеграмма белән* (А.Гыйләҗев).

Моннан тыш синтаксик омонимнарның тагын берничә төрлесе бар.

1. ***Билгесез килеш формасы белән бәйле синтаксик омоним.*** Мондый төзелмәдә төрләндергеч кушымчасыз яки тартым һәм күплек кушымчасы белән килгән сүз аны ике төрле аңларга урын калдыра: *Фәттах ачу белән җилкәсендәге ике кеше салган капчыкны "зыңк" итеп җиргә ташлады да, тын алу өчен, салкын чирәмгә сузылып ятты* (Ф.Кәрим).

2. ***Гади һәм иярчен җөмлә белән бәйле синтаксик омоним.*** *Ул елларда, татарча язу машинкалары булмаганлыктан, наборщиклар танымаслык кульязмаларны күчереп язалар иде* (Г.Ибраһимов турында истәлекләр).

3. ***Ия һәм тиңдәшлеккә бәйле синтаксик омоним.*** *Малайлар, ломовойлар кайтуга дип, йөгереп-йөгереп аш хәзерләп йөриләр* (Ф.Сәйфи-Казанлы).

4. ***Сан белән бәйле синтаксик омоним.*** Саннар белән бирелгән җөмлә кисәгенең ияртүче сүзен үз урынына куймау яки, киресенчә, санны иярүче сүздән читләтү көтелмәгән мәгънәне бирергә мөмкин: *Шушы вакыт эчендә генә дә анда өч тапкыр 9 нчы классны, дүрт тапкыр 8 нче классны тәмамлаучыларның чыгарылыш кичәләре булып узды* ("Тат. яшъләре").

Сораулар һәм биремнәр.

1. Стиль әйләнмәләренең төзелеше.
2. Стиль әйләнмәләре һәм аларның башка төр күренешләр белән мөнәсәбәте.
3. Кушымчалар ярдәмендә формалашкан стиль әйләнмәләре.
4. Бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр ярдәмендә формалашкан стиль әйләнмәләре.
5. Фигыль формасы ярдәмендә формалашкан стиль әйләнмәләре (шарт фигыль, хәл фигыль, исем фигыль һәм инфинитив формалары).
6. Тезү интонациясе һәм тезүче теркәгечләр җирлегендә формалашкан стиль әйләнмәләре.
7. Стиль әйләнмәләренең кулланылыш үзенчәлекләре.
8. Хәзерге татар телендә синтаксик омоним күренеше, аңа билгеләмә бирү мәсьәләсе.
9. Синтаксик омонимнарның төрләре (уңай һәм стиль омонимнары) һәм стиль омонимнарын төзәтү юллары.
10. Стиль хаталары, аларның иң еш кабатланган төрләре һәм аларны төзәтү юллары.

Әдәбият исемлеге.

1. Ибраһимов С.М. Татар телендә синтаксик синонимнар / С.М.Ибраһимов. – Казан: КДУ нәшр., 1976. – 168 б.

2. Ибраһимов С.М., Сафиуллина Ф.С. Практик стилистика: Күнегүләр җыентыгы / С.М.Ибраһимов. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1978. – 144 б.

3. Ибраһимов С.М. Синтаксик стилистика / С.М.Ибраһимов. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1989. – 150 б.

4. Ибраһимов С.М. Сандугач теле кирәк: Синтаксик ситилистика: Уку-укыту ярдәмлеге / С.М.Ибраһимов. – Казан: Мәгариф, 2008. – 159 б.

5. Курбатов Х.Р. Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы / Х.Р.Курбатов. – Казан: Мәгариф, 2002. – 199 б.

6. Солганик Г.Я. Синтаксическая стилистика: Сложное целое / Г.Я.Слоганик. – М.: Высш. школа, 2003. – 214 с.

Фәнни хезмәтләр, уку-укыту әсбаплары, методик кулланмалар һәм информацион чыганаклар

1) төп әдәбият:

Бәширова И.Б. Фәнни әдәбият стиле: гомуми мәгълүмат. – Журнал “Фән һәм тел”, 2000. - № 3 – Б. 12-15.

Бәширова И.Б. Татар стилистикасының теоретик нигезләре. Татар филологиясе һәм тарихы факультеты студентлары өчен программа / И.Б.Бәширова. – Казан: Казан дәүләт ун-ты, 2005. – 29 б.

Ибраһимов С.М. Синтаксик стилистика / С.М.Ибраһимов. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1989. – 150 б.

Ибраһимов С.М. Сандугач теле кирәк: Синтаксик стилистика: Уку-укыту ярдәмлеге / С.М.Ибраһимов. – Казан: Мәгариф, 2008. – 159 б.

Курбатов Х.Р. Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы / Х.Р.Курбатов. – Казан: Мәгариф, 2002. – 199 б.

Низамов И.М. Уем тел очында... (Сөйләм һәм массакүләм аралашу // – Беренче кисәк. Татар сөйләменең нигезләре) / И.М.Низамов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – 287 б.

Низамов И.М. Татарская речь. Функционирование и развитие речевой системы в массовой коммуникации / И.М.Низамов. – Казань: Изд-во “Матбугат йорты”, 2002. – 272 с.

Солганик Г.Я. Синтаксическая стилистика: Сложное целое / Г.Я.Слоганик. – М.: Высш. школа, 2003. – 214 с.

Хаков В.Х. Татар әдәби теле: (Стилистика) / В.Х.Хаков. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1999. – 302 б.

ә) өстәмә әдәбият:

Абдуллина Р.С. Стилистика һәм сөйләм культурасы мәсьәләләре / Р.С.Абдуллина. – Яр Чаллы: "КамАЗ" кит. нәшр., 1997. – 128 б.

Абдуллина Р.С. Риторика һәм интонация / Р.С.Абдуллина. – Яр Чаллы, 1999. – 400 б.

Андреева Л.А. Стилистика и культура речи: учеб. пособие / Л.А.Андреева, Л.В.Мирошниченко. – Казань: ТГГПУ, 2007. – 113 с.

Бәширова И.Б. Сүз белән сурәт ясау / И.Б.Бәширова. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1974. – 175 б.

Бәширова И.Б. Сәнгатьле чәчмә әсәрләр теле: Татар прозасында хикәяләү стильләренең үсеше һәм аның әсәр теленә тәэсире / И.Б.Бәширова. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1979. – 96 б.

Бельчиков Ю.А. Стилистика и культура речи. 2-е изд., испр. и доп. – М.: Изд-во УРАО, 2002. – 160 с.

Введенская Л.А. Риторика и культура речи: учебное пособие для студентов высших учебных заведений / Л.А.Введенская, Л.Г.Павлова. – Изд. 9-е, доп. и перераб.. – Ростов-на-Дону: Феникс, 2008. – 537 с.

Виноградов В.В. О Языке художественной прозы / В.В.Виноградов. - М.: Наука, 1980. – 360 с.

Галимуллин Ф. Укучыларны сәнгатьле укырга өйрәтү. Татар әдәбияты укытучылары өчен методик кулланма / Ф.Галимуллин. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1988. – 86 б.

Гарифуллин В.З. Хәбәри жанрлар: Университетның журналистика факультеты студентлары өчен уку ярдәмлеге / В.З.Гарифуллин. – Казан: КГУ нәшр., 1991. – 42 б.

Гарифулллин В.З. Журналист текстында дәлил: Татар журналистикасы студентлары өчен кулланма / В.З.Гарифуллин. – Казан, 1996. – 22 б.

Ибраһимов С.М. Татар телендә синтаксик синонимнар / С.М.Ибраһимов. – Казан: КДУ нәшр., 1976. – 168 б.

Кузьмина Х.Х. Фонетик стилистика / Х.Х. Кузьмина // Милли мәдәният. – 2006. – № 9. – С. 44-45.

Кузьмина Х.Х. Фонетик стилистика мәсьәләләре / Х.Х.Кузьмина // Milli mədəniәт. – Казань, 2006. - № 11. – Б. 55-57.

Курбатов Х.Р. Хәзерге татар әдәби теленең стилистик системасы / Х.Р.Курбатов. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1971. – 192 б.

Курбатов Х.Р. Татарская лингвистическая стилистика и поэтика / Х.Р.Куратов. – М.: Наука, 1978. – 218 с.

Львов М.Р. Риторика. Культура речи: Учеб.пособие для студентов гуманитарных факультетов вузов. – М.: Изд. центр "Академия", 2002. – 272 с.

Низамов И.М. Матбугатның тәэсирле сүзе: Газета лексикасы мәсьәләләре / И.М.Низамов. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1981. – 144 б.

Низамов И.М. Ничек әйтергә? Ничек язарга? (Татар интонациясе һәм аны язуда белдерүнең кайбер мәсьәләләре) / И.М.Низамов. – Казан: КПССның Татарстан рескомы нәшр., 1990. – 36 б.

Низамов И.М. И туган тел...: Татар теле – дәүләт теле / И.М.Низамов. – Казан: Мәгариф, 1998. – 207 б.

Низамов И.М. Очерк // Татар очеркы: кичә, бүген, иртәгә/ "Әдәби-публицистик жанрлар" курсыннан журналистика факультеты студентларына һәм аспирантларына уку кулланмасы / И.М.Низамов. – Казан, Яр Чаллы: Яр Чаллы шәһәрендәге Казан дәүләт университеты филиалының оператив полиграфия лабораториясе, 2003. – 71 б.

Розенталь Д.Э. Секреты стилистики / Д.Э.Розенталь, И.Б.Голубь. – М.: Рольф, 2001. – 272 с.

Сафиуллина Ф.С. Татар телендә сүз тәртибе / Ф.С.Сафиуллина. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1974. – 152 б.

Тимерханов А.А. Язык деловых бумаг в современном татарском языке / А.А.Тимерханов. – Казан: Гуманитария, 2002.

Хайруллина А. Дөрес сөйләргә өйрәнегез / А.Хайруллина. – Казан: "Казан" нәшр., 1992. – 96 б.

Ханбикова Ш.С. Татар телендә синонимнар / Ш.С.Ханбикова. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1961. – 70 б.

Хисамова Ф.М. Татарский язык в восточной дипломатии России (XVI - начало XIX вв.) / Ф.М.Хисамова. – Казань: Мастер Лайн, 1999. – 408 с.

Шакиров Р. Риторическая культура как дидактическая основа культуры речи / Р.Шакиров // Фән һәм мәктәп (Наука и школа). – 2006. - № 2. – С. 61-63.

Юсупов Р.А. Икетеллелек һәм сөйләм культурасы / Р.А.Юсупов. – Казан: Тат. кит. нәшр, 1987. – 214 б.

б) информацион чыганаклар, интернет-ресурслар:

- Универсальная энциклопедия Википедия – www.wikipedia.ru
- Электронная библиотека и материалы сайта КФУ – www.kpfu.ru
- Электронно-библиотечная система «Знаниум» – www.znanium.com
- Электронные ресурсы сайта Стилистика – www.stilistika.ru
- Электронные словари – www.slovari.ru

Терминологик сүзлекчә

Абсолют синонимнар – мәгънәләре тулысынча тәңгәл килә торган синонимнар (дублетлар).

Автор метафорасы – метафораларның бер төре (икенче төрле – индивидуаль метафора). Авторның әдәбиятка алып килгән яңалыгы; сүз яңа мәгънә белән ачылып китә, яңача яңгыраш ала.

Автор сөйләме – әдәби әсәрдә авторның хикәяләве, әсәрнең персонажлар сөйләме кермәгән өлеше.

Аллитерация – стилистик алым буларак бер үк авазларның яки аваз тезмәләренең кабатланып килүе.

Анафора – бер үк сүзләрнең, бер үк формаларның кабатлануына нигезләнгзн стилистик фигура.

Антитеза – антонимнарга нигезләнгән стилистик фигура, күренешләрне, образларн бер-берсенә капма-каршы куеп сурәтләү.

Әдәби тел – халыкның мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерә торган нормага салынган тел.

Беренче дәрәҗә синонимнар – компонентлары арасындагы мәгънә мөнәсәбәтләре һәм грамматик функцияләре белән бер-берсенә якын, ә структур яктан аерыла торган төзелмәләр (сүзтезмә, әйләнмә һәм җөмләләр).

Гади сөйләм – әдәби сөйләм нормаларына кермәгән, гадиләштерү, тупасландыру төсмере булган сүзләр, тәгъбирләр, формалар, әйтелеш үзенчәлекләре. Әдәби әсәрләрдә экспрессив элементлар буларак кына кулланылалар.

Гомумпоэтик метафара – метафораларның бер төре. Тыңлаучы, укучы тарафыннан сурәт, образ буларак кабул ителә торган метафора.

Ибраһимов Сәгадәт Мөгаллимович (1928-2008) – синтаксик стилистиканы җентекләп өйрәнүче һәм төзек бер системага салучы галим. “Татар телендә синтаксик синонимнар” (1976) хезмәтендә автор татар тел белемендә аз тикшерелгән, әмма сөйләм өчен зур әһәмияте булган синтаксик синонимнарны, аларның төрләрен, кулланылышын өйрәнә. Аларның телне баетудагы, сөйләм матурлыгын арттыру һәм стильне камилләштерүдәге урынын күрсәтә. Синтаксик синонимнарны читләтеп, исәпкә алмыйча эш итүнең стильгә, әдәби телебезгә зарар китерү ихтималы да искәртелә. “Синтаксик стилистика” (1989) хезмәтендә исә сөйләм берәмлекләрен стилистик куллану, синтаксик синоним һәм омоним күренешләре кебек мәсьәләләр яктыртыла.

Икенче дәрәҗә синонимнар – үзләренең төзелешләре белән түгел, бәлки компонентлар арасындагы бәйәүче чаралары белән аерыла торган төзелмәләр. Шул ук вакытта бу бәйләүче чаралар бер үк характерда булалар.

Инверсия – тәэсирлелекне арттыру өчен җөмлә кисәкләренең урыннарын гадәттәгедән үзгә булган тәртиптә урнаштыру.

Интонация – сөйләмнең ритмик-мелодик ягы, сөйләмнеңмәгънәле кисәкләрен аеру, синтаксик мәгънәләр белдерү, сөйләмгә субъектив мөнәсәбәт һәм эмоциональ төсмерләр белдерү өчен хезмәт итә торган аваз чаралары җыелмасы. Ике аспекты була: 1) коммуникатив: сөйләм агымын оештыру, кисәкләргә (синтагмаларга, җөмләләргә, фразаларга) бүлү, әйтелеш типларын аеру, сөйләм берәмлекләре арасындагы мөнәсәбәтләрне белдерү функцияес; 2) эмоциональ: эмоциональ мәгънәләр, сөйләүченең эмоциональ халәтен, модальлек белдерү функциясе. Берничә компоненттан тора: мелодика, тавыш көче, сөйләм тизлеге, паузалар, тембр, басымнар.

Кыек сөйләм – чит кешенең сөйләмен иярчен җөмлә рәвешендә бирү. Туры сөйләмдәге ия тәмамлыкка әйләнә.

Норма – телдәге (сөйләмдәге) вариантлар арасыннан иң таралган, үз вазифасын иң әйбәт үти торган, иң тотрыклы традицион вариант. Төрләре: эофоэпик норма, лексик норма, морфологик норма, синтаксик норма, әдәби норма.

Риторика – сәнгатьле сөйләм, ораторлык сәнгате теориясе.

Синонимлык – морфемаларның, сүзләрнең, синтаксик конструкцияләрнең, фразеологизмнарның мәгънәләре тәңгәл яки якын булу.

Синтаксик вариант итеп алынган төзелмәләр үзләренең төзелешләре, бәйләүче чаралары белән бердәй булалар, бары тик аерым сүзләрнең тәртибе, кисәкчәләрнең, кайбер формаль күрсәткечләрнең булу-булмавы белән генә бер-берсеннән аерылып торалар.

Синтаксик омонимнар – синтаксик төзелешләре белән бердәй булып, берничә мәгънә аңлата торган сүзтезмә, әйләнмә һәм җөмләләр.

Синтаксик синонимнар – компонентлары арасындагы мәгънә мөнәсәбәте һәм грамматик функциясе белән бер-берсенә якын, ләкин синтаксик төзелеше, шулай ук бәйләүче чаралары белән аерыла торган төзелмәләр (сүзтезмә, әйләнмә һәм җөмләләр).

Синтаксик стилистика – гомуми стилистиканың бер тармагы буларак, хәзерге татар әдәби сөйләмен үзенең төп өйрәнү объекты итеп ала. Синтаксик стилистика синтаксик берәмлекләрне (сүзтезмә, җөмлә, синтагма, сиктаксик бөтен) сөйләмдә ничек куллану юлларын өйрәнүне үзенең максаты итеп куя. Шул рәвешле синтаксик берәмлекләрне стилистик куллану алымнары, шуларны истә тотып, сөйләмдә иң кирәкле төрне сайлап алу мөмкинлекләре бу фәннең үзәгендә ята.

Синтаксик тәңгәлләр – реаль чынбарлыктагы бердәй күренеш һәм бәйләнешләрне төрле юллар белән бирә алучы, мәгънәләре белән якын төзелмәләр.

Сөйләм – 1) Сөйләүченең, тел чараларыннан файдаланып, башкалар яки үз-үзе белән аралашу эшчәнлеге, телнең кулланылышы. 2) Тел ярдәмендә аралашуның стилистик төре (гади сөйләм, шигъри сөйләм һ.б.). 3) Әйтелмәне синтаксик төзү төре (автор сөйләме, кыек сөйләм, туры сөйләм һ.б.).

Сөйләм культурасы – 1. Сөйләм һәм язма әдәби тел нормаларына (әйтелеш, басым кую, сүзләр куллану, грамматик нормалар) ия булу. 2. Тел белеменең бер бүлеге. Телне мәдәният коралы буларак камилләштерү, нармалаштыру проблемаларын өйрәнә.

Стилистик метод – телнең төрле стильләрен тикшергәндә кулланыла торган метод, һәр стильнең табигатен танып белү, бер стильне башкаларыннан аера торган фонетик, грамматик һ.б. билгеләрне ачыклау.

Стилистика – тел гыйлеменең бер тармагы. Төрле стильләрне (сөйләм стиле, фәнни стиль, поэтик стиль һ.б.) һәм әдәби тел тарихына бәйле стильләрнең эволюциясен өйрәнә.

Стиль – 1. Нниди дә булса җәмгыятьтә иҗтимагый тормышның белгеле бер сферасына беркетелгән тел төркемчәсе. Гадәттә, һәр телдә өч стиль аерып

чыгаралар: нейтраль стиль, югары (китап) стиль, түбән (сөйләм) стиль. 2. Әдәби телнең бер төре. Тел кешеләрнең берәр иҗтимагый төркемендә, билгеле бер сферада аралашу үзенчәлекләренә бәйле рәвештә катнаша. Бу яктан: эш кәгазьләре, фәнни стилләр һ.б. аерыла. 3. Берәр сөйләм акты яки әсәр башкарылган индивидуаль ысул, манера.

Стиль әйләнмәләре – стильдә сүз тәртибе белән бәйле күренеш. Алар билгеле бер стиль максатыннан чыгып төзелә һәм стиль чарасы булып китә, сөйләмгә образлылык өсти, үткенлек бирә, әйтергә теләгән фикерне җыйнак төзелмә белән җиткерү теләге туа.

Стиль омонимнары стильне матурламыйлар, бәлки фикерне төгәл, ачык һәм дөрес итеп әйтеп бирергә комачаулыйлар, берничә төрле хөкем йөртергә урын кала, шуңа күрә аларны кире омонимнар да дип тә атап йөртәләр.

Сүз тәртибе – 1. Синтаксик һәм стилистик мәгънәләргә бәйле рәвештә җөмләдә сүзләрнең үзара билгеле бер тәртиптә килүе. Мәсәлән, ттаар телендә аергыч аерылмыштан, ия хәбәрдән алда килә, хәбәр җөмлә ахырында була һ.б. 2. Грамматик мәгънә белдерә торган чараларның бер төре. Мәсәлән, укыган кеше – кеше укыган.

Туры сөйләм – үзгәртелмичә кулланылган чит сөйләм, ягъни автор сөйләменә килеп кергән башка кеше сөйләме. Диалог, монолог һәм цитата дигән төрләргә бүленә.

Уңай омонимнар телдә еш очрый, аларны уңай яктан бәяләргә кирәк, чөнки алар, бер очракта, сөйләмне бизәү өчен киная белән кулланылалар, билгеле бер күләмдә үз үлчәме белән сөйләмгә кертеләләр икән алар стильне матурлыйлар. Икенче яктан, туры мәгънәдә алынганда да, фикерне аңлауга комачаулык итмиләр.

Уртак сөйләм – автор сөйләме белән персонажлар сөйләменең кушылып китүе. Автор персонаж булып уйлый, фикер йөртә.

Чит сөйләм – автор сөйләменә килеп керә торган башка кеше сөйләме. Өч төре була: туры сөйләм, кыек сөйләм, уртак сөйләм.